ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№ 12 (336) – ДЕКАБРЬ 2019

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Владимир Путин КАМАЗ юбилеенда

Пётр I патша галиҗәнапларының Казанга сәяхәте

Яңа Шимбәр: кечкенә авылның олы тарихы

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская,
Алёна Кутыркина, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Ксения Сёмина, Катерина Котова,
Илшат Фәйзрахманов
Фотографлар: Александр Ефремов, Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: Россиянең һәм Татарстанның халык артисты
Айдар Фәйзрахманов. Фото Г. Тукай исемендәге
Татар дәүләт филармониясеннән алынды

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
1150 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү
мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры
килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге
өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № О-3548
Басарга кул куелды: 23.12.2019
Басмадан чыкты: 27.12.2019

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

Коммерция директоры:
Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә
2350 данә тираж белән чыга. Гомуми тираж: 3500 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ИКЕБЕЗГӘ – 200 ЯШЬ!

2019 ел да үз финишына килеп җитте. Акрынлап ул инде хатирәгә әверелеп бара – кем өчендер борчу-сагышлы, кем өчендер – якты-сөенечле, ә кем өчендер – тормышының иң матур мизгелләренә... Ничек кенә булмасын, 2019 ел календаре исәбендәге көннәрне исәпләп чыгарсак, аны, һичшиксез, позитив ел дип атый алабыз. Әйбәт ел узып китеп барганга гына бераз моңсу. Әмма 2020 ел инде безгә кул изи, ул бик күпне вәгъдә итә – юбилейлар, бәйрәмнәр буенча да, күңелле вакыйгалар һәм колачлы планнар җәһәтеннән дә. «Татарстан» журналына һәм сөекле республикабызга 2020 елда икесенә бергә 200 яшь тула! ТАССРның туган көнен июнь аенда билгеләргә җыенабыз, ә журналның 100 еллыгын – декабрьдә!

Бөтен кадерле кешеләр чакырулы! Бер гасырлык юбилей ләбаса – уен эшмени! Әлбәттә, барыбызга да җыелыр өчен искиткеч сәбәп. 100 ел буена республиканы төзү, журналга нигез салу, аларны яшәтү, торгызу – боларны эшләгән затлар арасында арабызда булганнары да, инде хәтеребезгә генә күчеп, истәлекләрдә яшәүчеләре дә җитәрлек. Ә бүген бу олы хезмәтне фидакарь башкаручылар – алары никадәр!

Шуңа да, җыелып, беренче 100 еллыгыбызны тантаналы рәвештә бәйрәм итү зарур. Искә алу – безгә кадәрниләр булган, хәзер ниләр бар һәм нинди өметләр белән карыйбыз без киләчәккә. Шуларның барысын да күздән кичергәч кенә, алдагы 100 еллыкка ышанычлы адымнар белән атларга мөмкин: инкыйлаб-түнтәрелешләрсез, сугыш, кан коюларсыз...

Без барыбыз да – Татарстанның үзе бит!

Яңа ел белән безне! Беренче 100 еллыкны тәгәлләп, яңасына йөз тотуыбыз белән!

СЕЗНЕҢ 99 ЯШЬЛЕК РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **933 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ

Равил Зәһидуллин, «Казан бистәсендә»

ДЕКАБРЬ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

6. Планнар барысы да үтәләчәк!
Рөстәм Миңнеханов Владимир Путинга нәрсәләр турында җиткерде

8. Бизнес-структуралар өчен форсат
«Татарстан – Словакия» эшлекле форумы нәрсәләрне ачты

10. Тигез мөмкинлекләр синергиясе
Беларусь һәм Татарстан көндәшлекне түгел, хезмәттәшлекне өстен күрә

12. Милли проектлар. Киләчәккә ыргылыш
Тормышыбызны ничек яхшыртырга

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

22. 2019 ел каһарманнары
Безне сөендергән вакыйгалар һәм кешеләр турында

48. Авыл икътисады
Теләче сәнәгать паркында нәрсәләр җитештерелә

50. Редакция кухнясы
Яңа ел табынын ничек бизәргә

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

58. Олы Әтнә туган якны өйрәнү музее
Сәүдәгәр Даутов йорты

62. Өяз медицинасы музее
Ашказанын дәваларга – валидол

66. КАМАЗ тарихы музее
Ил язмышын билгеләгән бөек төзелеш

70. Хәтерне торгызу өчен 38 миллион доллар
Чистай дөньяга нинди ядкарьләрен ачачак

74. Тарих сәхифәләре
Петр I Казан түрәләрен ничек өйрәткән

84. Татар авыллары
Яңа Шимбәр – кечкенә авылның олы тарихы

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

13.12



Владимир Путин, Россия Президенты, – «КАМАЗ» ГАҖ двигательләр заводы эшчеләре белән очрашуда:

– Сез башкара торган эш – гаҗәеп. Ил сезнең кебек коллективлар һәм мондый предприятиеләр белән горурлана ала. Сез чынлап торып үз кулларыгыз, сәләтегез белән илне ныгытасыз. Бу – буш сүзләр генә түгел, юк-бар дип кабул ителмәсен. Цехлар буйлап атлаган чакта илебезнең ни дәрәҗәдә көч-егәргә ия булуын һәм киләчәге барын аңлыйсың.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

17.12

Талия Миңнуллина, Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе, – ТР ИҮА каршындагы инвесторлар клубының традицион яңа ел алды утырышында:

– Безнең кадерле инвесторларыбыз… Без сезнең барыгызны да бик яратабыз, бәялибез һәм кадерегезне беләбез. Сезгә уңайлы булсын өчен барысын да эшлибез. Бу матур кичтә шуны әйтергә телим: принцны очратыйм дисәң, бик күп бакаларны үбеп чыгарга кирәк… Татарстанны ничек тә инвестицияләсеннәр өчен, сәүдә белән шөгыльләнүче кешеләр белән шактый аралашу зарур. Нәтиҗәгә ирешер өчен, без ел буена республикада да, чит илләрдә дә меңнәрчә очрашулар үткәрәбез. Һәм бүген бу эш яхшы бара.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

30.11



Михаил Жванецкий, язучы-сатирик, – Казандагы концертында:

– Без бик давыллы заманга эләктек. Кул сәгатенә карап, вакытны түгел, табышны саный торган… Автомобильләр бүген йөрү өчен түгел, ә тизрәк килеп җиту өчен. Ашау – ябыгу өчен. Музыка – ярсу өчен. Курорт – әсәрләнү өчен. Теш – кешене ачыклау өчен. Аракы – үзара аңлашу өчен. Кумир – нәфрәтләнү өчен. Яшәү – хезмәт хакы өчен. Һәм бары тик авыру гына – йокы өчен.

Фото ТР Президенты сайтыннан

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Путин Яр Чаллыга **НИНДИ** юбилейга килде

Татарстан һәм Словакия бизнесы **НИЧЕК** эш итәчәк

Белоруссиядә **КҮПМЕ** татар яши

Быел Татарстан милли проектларга **НИЧӘ** миллиард сум тотты

ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

2020 елның
I яртыеллыгына
«Татарстан»
журналына язылу
дәвам итә

«Татарстан» журналына ТР буенча язылу индекслары:

П 2381 **татар телендә** 933 сум 00 тиен

П 2378 **рус телендә** 933 сум 00 тиен

«Татарстан» журналына РФ буенча язылу индекслары:

П 7077 **татар телендә**

П 7076 **рус телендә**

«Татарстан» журналына ТР буенча еллык язылу индекслары:

ПА 468 **татар телендә** 1866 сум 00 тиен

ПА 471 **рус телендә** 1866 сум 00 тиен

Реклама 16+



ПРЕЗИДЕНТ МАРШРУТЛАРЫ БУЕНЧА

Татарстан Президентының эш графигы никадәр тыгыз булуын аңлар өчен, бернинди махсус хронометраж үткәрү таләп ителми. Аның сәфәрләре маршрутына күз салу да җитә. Республика, ил, дөнья буйлап туктаусыз йөри ул. Еш кына Рөстәм Миңнеханов иртән нинди дә булса Европа илендә потенциаль инвесторлар белән сөйләшүләр үткәрергә, көндез Россия башкаласындагы мөһим киңәшмәдә катнашырга өлгерә, берничә сәгатьтән соң исә Әлмәттә нефть тармагы үсеше перспективаларын тикшерә... Һәм көн саен диярлек шундый хәл күзәтелә.

Юлда үткән сәгатьләр һәм чакрымнар, мөһим очрашулар, җитди чыгышлар һәм җаваплы карарлар. ТР Президентының соңгы арадагы эш сәфәрләреннән «Татарстан» аеруча әһәмиятлеләрен сайлап алырга тырышты.

ТАТАРСТАН.
ҮСЕШ НОКТАЛАРЫ

НӘРСӘ:

Россия Федерациясе Президенты Владимир Путинның Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән эшлекле очрашуы

КАЙДА:

Яр Чаллы

КАЙЧАН:

13 декабрь

Фотолар ТР Президенты сайтыннан алынды

ТУЛЫРАК:

Рөстәм Миңнеханов белән эшлекле очрашуны ил башлыгы, Яр Чаллыга килеп, «КАМАЗ» ГАҖ нең 50 еллыгын бәйрәм итү кысаларында үткәрде. Татарстан Президенты төбәкнең социаль-икътисадый үсеше һәм республика территориясендә кайбер республика программаларының һәм милли проектларның гамәлгә ашырылуы турында кыскача гына сөйләп үтте. Аерым алганда, Рөстәм Миңнеханов 2019 ел йомгаклары буенча тулай төбәк продуктының (ТТП) – 2 трлн 552 млн 600 мең сум тирәсе, төяп-озатылган сәнәгать продукциясенең күләме 2 трлн 900 млн – 3 трлн сум күләмендә күтәрелүенә басым ясады. 2018 елның шул чорындагы күләмнәр белән чагыштырганда үсеш – 1,2–1,5 процент тирәсе.

Тулаем алганда, бюджет үтәлә, төп капиталга инвестицияләр 630–650 млрд сумга якын, без шушы саннар тирәсендә булабыз, дип белдерде алга таба Рөстәм Миңнеханов. 2019 ел йомгаклары буенча төбәктә уртача хезмәт хакы 37 мең сумнан артыкны тәшкил итә. «Хезмәт хакын түләү буенча бурыч – 60–70 миллион сум, ләкин без барысын да контрольдә тотабыз», – дип ачыклык кертте ТР Президенты.

Төбәктә милли проектларны гамәлгә ашыруга килгәндә исә, быел үтәлергә тиешле планнар үтәләчәк, дип хәбәр итте Рөстәм Миңнеханов. Аның сүзләренә караганда, милли проектларның күләме 26 миллиард сумны тәшкил итә, шул исәптән әлеге сангa федераль акчалар да, республика акчалары да кергән.

Быел төбәктә 40 программа тормышка ашырыла, аларның бюджеты 40 миллиард сумны тәшкил итә. Владимир Путин мобиль поликлиникалар эше белән кызыксынды. «Без дүрт поликлиника сатып алдык, ел саен 100 процент авыл халкына диспансерлаштыру үткәрәчәкбез. Әлеге мобиль поликлиника эше күрсәтмәләре буенча 460 кеше хастаханәгә ятты: урыннарга килеп, проблемаларны ачыкладылар, вакытында күреп алдылар. Шуңа күрә бу эш дәвам иттереләчәк», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Торак фондка капиталь төзекләндерүнең барышы турында сөйләгәндә, ТР Президенты болай диде: «Без ел саен якынча 990–1000 күпфатирлы йортны ремонтлыйбыз, алга куелган бурычларны үтәп барабыз. Халык та үз өлешен кертә. Бу бик зур программа, һәм ул нәтиҗәле эшли».

Иң мөһим бурычлар арасында – юл фондын ремонтлау программасын гамәлгә ашыру. Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, куркынычсыз һәм сыйфатлы автоюлларны тәэмин итү өлешендә бу федераль проектлар да, республика программалары да, авыл юллары да. «Монда юнәлешләр күп, – дип төгәллек кертте ул. – Иң мөһиме – без актив эшлибез. Бу шул исәптән ишегалды, квартал эчендәге юлларны салуга да карый. Киләсе елдан без яңа программаны эшләтеп җибәрәчәкбез – өч ел эчендә 700 ишегалдын тәртипкә китерәчәкбез».

Ул шулай ук Россия Президентын «Россия – ислам иле» Стратегик төркем эшчәнлеге белән таныштырды. Владимир Путин эшкә уңай бәя бирде.

Алданган өлешчеләр буенча алып барылган эш кебек кискен тема да кузгатылмыйча калмады. «2016–2018 елларда без 18 объектны тапшырдык, 2019 елда 10 объект тапшырылачак, шуларның бишесе тапшырылды… Проблемалы өлешчеләр буенча без якындагы ике ел эчендә төп өлешне ябарга тиеш», – дип хәбәр итте Татарстан Президенты.

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты:
– Без барлык программалар буенча алга куелган бурычларны үтибез. Моңа барлык объектлар – милли проектлар да, үзебезнең, республиканыкылар да керә.

БРАТИСЛАВА.
БИЗНЕС-СТРУКТУРАЛАР ӨЧЕН ФОРСАТ

НӘРСӘ:

Словакия Республикасына эш сәфәре

КАЙДА:

Братислава

КАЙЧАН:

10–11 декабрь

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты:
– Словакия компанияләренең Россиядә эш башлаган вакытта старт мәйданчыгы буларак Татарстанны сайлавы безнең өчен бик мөһим. Татарстанда бизнесны локальләштерү өчен барлык мөмкинлекләр дә бар: бу махсус икътисадый зона, алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре, технопарклар һәм сәнәгать мәйданчыклары, республиканың һәр муниципаль районында ачылган индустриаль парклар.

Фотолар ТР Президенты сайтыннан алынды

ТУЛЫРАК:

Сәүдә-икътисадый һәм инвестицион хезмәттәшлекне киңәйтү, яңа эшлекле элемтәләр урнаштыру – Татарстан делегациясенең Словакиягә эш сәфәренең максатлары әнә шулар, дип хәбәр итте Рөстәм Миңнеханов Словакия Республикасының икътисад министры Петер Жига белән очрашуы барышында. «Икътисадый һәм фәнни-техник хезмәттәшлек буенча Россия-Словакия дәүләтара комиссиясенең рәистәше буларак ярдәмегезгә өметләнәбез», – дип билгеләп китте Татарстан Президенты. Бурыч – бизнес-структураларның, һәм шулай ук ТР һәм Словакия сәүдә-сәнәгать палаталарының эшен активлаштыру. Рөстәм Миңнеханов үзара файдалы хезмәттәшлек мөмкинлекләре белән җентеклерәк танышу максатында Петер Жиганы Словакия эшлекле даирәләре делегациясе җитәкчелегендә Татарстанга чакырды.

Рөстәм Миңнеханов Братиславада «Словнафт» нефть эшкәртү заводында булды. «Словнафт» һәм MOL компаниясе вәкилләре белән очрашу барышында MOL – ПАВ-полимерлы суга батыру технологиясен (химик матдәләр ярдәмендә нефть табуны арттыру) кулланунын пилот проектын «Татнефть» ГАҖ чыганакларында гамәлгә ашыру, һәм шулай ук ТР юл төзелешендә югары йөкләнешкә һәм температура уйнауларына чыдам резина-модификацияле битум (MOL компаниясе эшкәртмәләре – ред. иск.) куллану мөмкинлекләре сораулары буенча фикер алыштылар.

«Татарстан – Словакия» эшлекле форумы әлеге эшлекле сәфәрнең мөһим өлеше булды. Форум кысаларында Словакия инвестицияләр һәм сәүдәне үстерү буенча агентлыгы (SARIO) презентациясе узды: «Словакия икътисады һәм ике як хезмәттәшлеген киңәйтү мөмкинлекләре». Шунда ук Татарстан Республикасының инвестицион куәтен презентацияләү чарасы да оештырылды. ТР Президенты һәм Словакия Республикасының Чит илләр һәм Европа эшләре министрлыгының генераль секретаре Лукаш Паризек катнашлыгында хезмәттәшлек турында кайбер документлар имзаланды. Алар арасында – Словакия инвестицияләр һәм сәүдәне үстерү агентлыгы (SARIO) һәм Татарстан Республикасы Инвестицияле үсеш агентлыгы арасындагы килешү.

Братиславада Рөстәм Миңнеханов Словакия Республикасы парламенты (Милли Советы) Рәисе Андрей Данко белән очрашты. Яклар Словакия һәм Россиянең сәнәгать юнәлеше буенча иң алга киткән төбәге буларак Татарстан арасындагы мөнәсәбәтләрне алга таба үстерү мәсьәләләрен тикшерделәр. Татарстан Президенты Словакиянең алга китеше, аның сәнәгать потенциалы һәм үсеш перспективалары зур тәэсир калдырды, дип билгеләп үтте. Ул әлеге эш сәфәре кысаларында Татарстан белән Словакия бизнесы арасындагы хезмәттәшлекнең кызыклы формалары табылачагына ышаныч белдерде. Бүген Россия һәм Словакия арасында югары белем турындагы дипломнарны тану турында килешү төзелде, дип искә төшереп үтте Рөстәм Миңнеханов. Аның сүзләре буенча, бу студентлар һәм мөгаллимнәр алмашы, интеграция юнәлешендә мөһим адым.

Шул ук көнне Рөстәм Миңнеханов Бөек Ватан сугышы елларында Братиславаны азат итүдә һәлак булган совет солдатларына ачылган мемориалга чәчәкләр салды.

БЕЛЕШМӘ:

2018 елда Татарстан – Словакия товар әйләнеше 540 миллион АКШ долларын тәшкил итте, аннан алдагы ел белән чагыштырганда әлеге күрсәткеч 23 процентка үсте. Хезмәттәшлек үрнәкләре арасында – «Татнефть» һәм Словакиянең «Словнафты» арасындагы элемтәләр. «Татнефть» ГАҖ белән «Словнафт» компаниясе арасында хезмәттәшлек турындагы килешү Словакия Республикасы парламенты Рәисе Андрей Данконың Татарстанга сәфәре барышында имзаланган иде.

МИНСК.
ПАРТНЁРЛЫК ЮЛЫННАН

НӘРСӘ:

Беларусь Республикасына эш сәфәре

КАЙДА:

Минск

КАЙЧАН:

11–12 декабрь

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты:
– Үзара хезмәттәшлегебезнең нәтиҗәләлеге турында түбәндәге саннар сөйли: товар әйләнеше инде 1,2 млрд доллардан артып китте. Әлеге күрсәткечне 2 млрд долларга кадәр үстерә алабыз, дип уйлыйм.

Фотолар ТР Президенты сайтыннан алынды

ТУЛЫРАК:

Беларусь Республикасы Президенты һәм Премьер-министры, татар җәмгыяте активы белән очрашулар, Минскидагы Җәмигъ мәчетенә һәм БЕЛАЗга бару – Татарстан делегациясенең Минскига ике көнлек эш сәфәренең графигы әнә шундый тыгыз, киеренке булды.

Александр Лукашенко ТР Президенты Рөстәм Миңнехановны үз резиденциясендә кабул иткәндә түбәндәгегә басым ясады: Беларусь белән Татарстанны тыгыз, конструктив мөнәсәбәтләр бәйли. Газ-мотор техникасын җитештерү бик мөһим кооперация проекты булып тора, дип искә төшереп үтте Беларусь Президенты. Әлеге кысаларда МАЗ, МТЗ, «Амкадор», БЕЛАЗ компанияләре Татарстанның «РариТЭК» холдингы белән актив хезмәттәшлек итәләр. Ике ел эчендә газда эшли торган 200 гә якын автобус җыелды, 2020 елда тагын шуның кадәр автобус чыгарылачак. «МТЗ» тракторлары һәм «Амкадор» машиналары өчен газ двигательләрен җитештерү буенча «Минск мотор заводы» белән уртак эш дәвам итә. «Киләчәктә «БЕЛАЗ» узбушаткычларын да әлеге ягулыкка күчерү планлаштырыла. Әлеге мисаллар безнең көндәшлекне түгел, хезмәттәшлек юлын сайлавыбызны раслый. Үзара файдалы эш итү үсә, яңа хезмәт урыннары ачыла, Беларусь һәм Татарстан предприятиеләре өчен тигез мөмкинлекләре тудырыла. Әлеге күркәм үрнәкне Россиянең башка төбәкләрендә дә тарату икътисадый диалогның зур нәтиҗәлелеккә ирешүен тәэмин итәр иде», – диде Александр Лукашенко.

Беларусь Республикасы Президенты илнең нано-һәм биотехнологияләр өлкәсендә җитди мөмкинлекләре булуын, ә Белоруссия югары технологияләр паркының компьютер технологияләрен эшләү өлкәсендә Үзәк һәм Көнчыгыш Европада иң эре кластерларының берсе саналуын билгеләп үтте. «Без әлеге сферада Казан ИТ-паркы һәм Татарстанның башка фәнни-җитештерү үзәкләре белән тыгыз хезмәттәшлек итәргә әзер», – дип өстәде ул.

Беларусь лидеры сүзләренә караганда, үзара товар әйләнешенең яртысын билгән нефть химиясе секторы багланышларның төп юнәлеше булып кала бирә. Экологик куркынычсызлык, атап әйткәндә, калдыкларны һәм икенчел чималны эшкәртү сфераларында хезмәттәшлек итү өчен мөмкинлекләр зур.

Рөстәм Миңнеханов та Беларусь Республикасының Татарстанның стратегик партнёры булуына басым ясады. Бүгенге көндә Татарстанда кулланыла торган авыл хуҗалыгы техникасының 60%ы Белоруссиядә җитештерелгән. ТР Президенты нефть химиясе, ИТ-технологияләр һәм газ-мотор ягулыгы базарын үстерү сфераларында хезмәттәшлек итүнең зур перспективага ия булуын билгеләп китте. ТР Президенты Татарстан һәм Беларусь нефтьчеләренең үзара хезмәттәшлеге сорауларына аерым тукталды.

Рөстәм Миңнеханов Александр Лукашенкога Беларусь территориясендә яшәүче татарларга ярдәм күрсәтелүе, милли традицияләрне һәм мәдәниятне саклау өчен яхшы шартлар тудырылуы өчен рәхмәтен белдерде.

Татарстан Президентының Беларусь Премьер-министры Сергей Румас белән очрашуында сүз алга таба хезмәттәшлекне үстерү юллары турында барды. Әлеге очрашу ахырында Рөстәм Миңнеханов һәм Минск өлкә башкарма комитеты рәисе Александр Турчин Татарстан Республикасы Хөкүмәте белән Минск өлкә башкомитеты арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, социаль-мәдәни һәм гуманитар өлкәләрдә хезмәттәшлек итү турында килешүне имзаладылар.

Татар җәмгыяте активы вәкилләре белән очрашуда Рөстәм Миңнеханов аларга туган телне һәм милли гореф-гадәтләрне саклаганнары өчен рәхмәтен белдерде. Үз чиратларында җирле татар иҗат коллективлары вәкилләре музыка инструментлары сатып алуда ярдәм сорадылар, шулай ук ТАССРның 100 еллыгын бәйрәм итү чараларыда катнашырга теләкләре барлыгын җиткерделәр. Рөстәм Миңнеханов тиешле күрсәтмәләрне бирде.

БЕЛЕШМӘ:

Беларусь Республикасында җиде меңнән артык татар яши (2009 елгы җан исәбен алу мәгълүматлары буенча – 7 мең 319 кеше – ред. иск.), шуларның мең ярымнан артыгы – Минскида. Илдә ике дистә ел дәвамында «Чишмә» татар-башкорт мәдәни берләшмәсе эшли.

Александр Лукашенко, Беларусь Республикасы Президенты:
– Татарстан – Идел буе федераль округында иң мөһим партнёрыбыз. 2018 ел йомгаклары буенча үзара товар әйләнеше 1,3 млрд долларга якынлашты. Әлеге күркәм нәтиҗәне саклау һәм арттыру өчен яңа үсеш нокталарын эзләү зарур. Инновацияле һәм инвестицияле хезмәттәшлек күләмнәрен арттыру әлеге юнәлештә төп хезмәттәшлек векторы булып тора. Сезнең үз эшегездә алдынгы технологияләрне һәм фән казанышларын гамәлгә кертүгә басым ясавыгызны беләм. Без дә шундый ук критерийлар буенча эшлибез.

МИЛЛИ ПРОЕКТЛАР КИЛӘЧӘККӘ ЫРГЫЛЫШ

Яңа юллар, торак, мәктәп, балалар бакчалары, сәламәтләндерү үзәкләре... Кыска гына итеп әйткәндә, безнең тормышны нәрсә уңайлырак һәм яхшырак итә – әнә шулар! Россия күләмендә һәм, аерым алганда, Татарстанда, гамәлгә ашырылып килгән киң колачлы милли проектларның бөтен мәгънәсе шул.

Ниятләрнең гаҗәеп колачлы булуы хакында саннар да сөйли. Татарстанда милли проектларны тормышка ашыру өчен 2019–2020 елларда 55,3 млрд сум тотылачак. 36, 4 млрд сум – монысы федераль бюджет хисабыннан, ә 18,9 млрд сум – Татарстан Республикасы бюджетыннан.

«Милли проектларны тормышка ашыруда без планга кертелгән барлык юнәлешләр буенча да эшлибез», – дип хисап тотты декабрь аенда Россия Президенты Владимир Путинга Рөстәм Миңнеханов. Татарстан Президенты шуны да әйтте: планнар барысы да үтәләчәк. Милли проектларның 2020 елдагы күләме 26 млрд сум акчаны исәптә тота (федераль һәм республика бюджетлары белән бергә). Татарстанда инде 30 балалар бакчасы, 2 мәктәп төзелде.

Фотолар «Милли проектлар: Татарстан – 2019» Республика фотокүргәзмәсен оештыручылардан һәм «Татар-Информ» МАнан алынды

Казан ш.

Национальные проекты
Предпринимательство

Казан ш.

Тәтеш районы
Национальные проекты
Демография

Нурлат районы

Казан ш.
Национальные проекты
Жилье и городская среда

Тәтеш районы

Казан ш.
Национальные проекты
Здравоохранение


Иннополис ш.

Фото: ТР Җәмгать киңлекләрен үстерү программасы мәгълүмат хезмәтеннән алынды

Казан ш.
Национальные проекты
Производительность труда

Лениногорск районы

Казан ш.
Национальные проекты
Цифровая экономика


Казан ш.

Саба районы
Национальные проекты
Безопасные автомобильные дороги

Кама Тамагы районы

ЛИДЕРЛАР **«ЧЕЛТӘРЕ»**

Энергетиклар, бигрәк тә зур тәҗрибәгә ия булганнары, – хезмәт базарында югары бәяләнүче дефицит кадрлар. Җитештерү технологияләрен, беренче чиратта, кадрларга кагылышлыларын камилләштереп, «Челтәр компаниясе» ААҖ предприятиенең һәр хезмәткәре үрнәк дәрәҗәдәге белгечкә әйләнсен өчен барысын да эшли.



Автор:
Ксения Сёмина

«Ворлдскиллс Россия» яшь профессионаллары» союзы ел саен WorldSkills Hi-tech стандартлары буенча сәнәгатьнең югары технологияле өлкәләренә караган төрле тармаклар өчен уртак (гомумтармак) профессияләр чемпионаты үткәрә. Быел анда 1500 конкурсант катнашты, алар 48 номинация буенча көч сынашты. «Челтәр компаниясе» ААҖ белгечләре беренче мәртәбә «Электр энергиясен исәпкә алуның интеллектуаль системалары» номинациясендә катнаштылар. Үзебездә үткәрелгән җитди сайлап алуларда Казан электр челтәрләренең исәпкә алу системалары һәм техник аудит бүлеге инженеры Рөстәм Гыйләҗев һәм Бөгелмә районы электр челтәрләренең техник аудит инженеры Тимур Белов иң яхшы нәтиҗәләрне күрсәттеләр. Нәкъ менә әлеге белгечләр ноябрь аенда Екатеринбургта уздырылган чемпионатта катнашу хокукына ия булдылар.

– Әзерлек бик киеренке барды. Чемпионат башлангач, WorldSkills стандартлары ярышларында беренче тапкыр катнашучы буларак без белмәгән шактый күп нечкәлекләр барлыгы ачыкланды. Шуңа күрә беренче көн нәтиҗәсе уртача булды, – дип сөйләде безгә «Челтәр компаниясе» ААҖ командасы тренеры, электр энергиясен исәпләү системалары хезмәте башлыгы **Роман Осиков**. – Шулай да егетләр тынычланырга, беренче көн тәҗрибәсен истә тотып, ярышларны дәвам итәргә үзләрендә көч таптылар һәм икенче көнне нәтиҗәләрне яхшырттылар.

Өченче көн татарстанлыларга җиңү китерә. Алар, бары тик «Россия челтәрләре» ГАҖ командасыннан гына калышып, «көмеш» яулыйлар.

– Бу бик җитди сынау булды. Ярышларда без көндәлек эшебездә кулланылмый торган җайланмаларда эшләдек. Конкурска әзерлек вакытында, әлбәттә, без аларда эшләп караган идек, әмма күнекмәләрнең җитеп бетмәве ачыкланды. Вакыт чикле, экспертлар биремнәрне катлауландырып торалар. Стрессны җиңә алу сәләтебез дә җитди тоткарлык бирде, – дип сөйләде **Тимур Белов**. – Ләкин хәзер, чемпионат үткәннән соң, мин нәрсәләргә ныклап әзерләнергә кирәген аңлыйм, әлбәттә, әгәр тагын мондый ярышларга катнашырга туры килсә. Моннан тыш, мин үземә нинди күнекмәләр җитеп бетмәвен аңладым, хәзер шуларны камилләштерү өстендә эшләячәкмен. Алган тәҗрибәм белән WorldSkills ярышларында катнашырга омтылган коллегаларым белән уртаклаша алам.

– Электр энергиясен исәпкә алуның интеллектуаль системаларының милли чемпионат программасына кертелү факты «Челтәр компаниясе» ААҖ тарафыннан әлеге үсеш юнәлешенең дөрес сайлануы турында сөйли, – диде Роман Осиков. – Ләкин хәтта бер генә иң заманча технология дә квалификацияле кадрлардан башка тиешле нәтиҗәне бирә алмый. Персоналның компетенцияләрен үстерү – үз тармагында лидерлыкка омтылган теләсә кайсы корпорациянең иң мөһим үсеш факторларының берсе. Һәм чемпионат моның хаклыгын раслый.

УҢЫШЛЫ СТАРТ

– WorldSkills дөнья чемпионаты – осталыкка, яшьлеккә һәм буыннар алмашына мәдхия, әти-әниләргә, укытучыларга, мастерларга, остазларга мәдхия. Ул киләчәкнең яңа һөнәри офыкларга омтылучы яшьләр кулында икәнлеген ачык күрсәтте, – диде чемпионатка җәлеп ителгән барлык объектларны өзеклекләрсез электр энергиясе белән тәэмин иткән «Челтәр компаниясе» ААҖ генераль директоры **Илшат Фәрдиев**.

Яшьләргә ярдәм итү, аларны үстерү – компания традициясе, ул оешма буыннар өзлексезлеген генә тәэмин итеп калмыйча, иң яңа технологияләрне тиз арада үзләштереп, гамәлгә кертергә ярдәм итә.

– Контакт-үзәк операторларының шалтыратуларга ничек җавап бирүләре хөрмәт һәм гаҗәпләнү уята. Үз эшләрен яратулары һәм, иң мөһиме, тулысынча темада булулары күренеп тора! – дип, үз тәэсирләре белән уртаклаша Казан дәүләт энергетика университетының (КДЭУ) 4 курс студенткасы **Алия Нәҗмиева**. Ул курсташлары белән бергә Дирекциянең Казан филиалында оештырылган Ачык ишекләр көненә килгән. Мон-

Фотолар «Челтәр компаниясе» ААҖ матбугат хезмәтеннән алынды

Реклама

дый чара «Челтәр компаниясе» ААҖ тарафыннан ел саен барлык бүлекчәләрдә дә мәктәп укучылары һәм студентларны компаниянең эше белән эчтән таныштыру максатында үткәрелә.

Компания республика уку йортлары белән актив хезмәттәшлек итә. КДЭУ һәм КМТТУ-КАИда (ГРИНТ) максатчан төркемнәр махсус программалар буенча укытыла. Һәр филиалга диярлек берәр урта махсус уку йорты «беркетелгән», аны тәмамлаучылар, реаль тәҗрибә алып, алга таба Татарстанның электр предприятиеләренә эшкә урнаша алалар. Мәсәлән, Бөгелмә машина төзелеше техникумы белән «Бөгелмә электр челтәрләре» филиалы арасындагы хезмәттәшлек нәтиҗәсендә 38 белгеч эш урынына ия булды.

– Безнең уртак максат – энергетиканың киләчәген тәрбияләү, – диде Илшат Фәрдиев Татарстан көллиятләре җитәкчелеге белән очрашуда. – Дөнья бик тиз үсеш кичерә, һәм без әлеге үзгәрешләргә оператив җавап бирергә тиешбез.

Америкадагы партнёрлар белән аралашу. «Челтәр компаниясе» ААҖ генераль директоры Илшат Фәрдиев «Электр челтәрләре» Халыкара форумында. Мәскәү, 2019 елның декабре.

КӨНДӘШЛЕК ИТ ҺӘМ ҖИҢ

Зур энергетикада электромонтёр – төп профессия, аңа инновацион процессларны көчәйтә баручы югары таләпләр куела. «Челтәр компаниясе» ААҖнең персонал белән эшләү идарәсе башлыгы Всеволод Семенюк сүзләренә караганда, оешмада бүлү энергетикасы өчен электр челтәрләре наладчигы һәм цифрлы подстанцияләрдә проектлаучы система белгече кебек киләчәк белгечлекләре пәйда булсын өчен шартлар тудырыла. «Челтәр компаниясе» ААҖ белгечләре илебез энерготармагы өчен яңа булган технологияләрне үзләштерү һәм гамәлгә кертү проектларында катнашалар. Мәсәлән, сентябрь аенда Казанда Республика уку-методик үзәге полигонында «Биеклек. Куркынычсызлык-2019» конкурсы узды. Аны Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы һәм «Төбәк уку-методик үзәге» ӨҺББ АКБО оештырды. Бөгелмә электр челтәрләре белгечләре «Канаты булмаган система белән биеклектә эшләүче иң яхшы команда» номинациясендә җиңде. Бөгелмәлеләр командасы электр энергиясе сферасыннан әлеге номинациядә катнашкан бердәнбер вәкил булды. Шулай ук сентябрь аенда уздырылган Талантлар университеты олимпиадасында (ул «Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасы кысаларында үтте) Түбән Кама электр челтәрләре командасы линиядә эшләү өчен электромонтёрлар әзерләү буенча «Виртуаль электромонтёр» проектын тәкъдим итте. Түбәнкамалылар теоретик өлешне изоляторны алыштыру буенча виртуаль чынбарлыкта тудырылган гамәли эш үрнәге белән тулыландырдылар. Алар уйлап тапкан VR-тренажёр «Иң амбициоз проект» номинациясендәге дипломга һәм конкурсның бронза бүләгенә ия булды. Гамәлгә кертү ягыннан әлегә Россиядә «Челтәр компаниясенә» тиңнәр табылмаган тагын бер технология – көчәнеш астында эшләү (РПН). Оешма белгечләре әлеге методны 10 ел дәвамында үзләштерделәр. «Юбилей» елы берничә «премьера» белән билгеләп үтелде – компания тарафыннан оештырылган РПН буенча халыкара симпозиум, Россия һәм халыкара дәрәҗәдәге (Санкт-Петербургта һәм Кытайда узган) күрсәтмә чыгышлар, шулай ук болар белән бергә 0,4 кВ көчәнеш астында эшләүне интенсив өйрәнү, көчәнешнең тагын да югарырак – 10 кВ классы астында эшләрне активлаштыру. Чистай электр челтәрләре белгечләре тарафыннан беренче тапкыр мачта трансформатор подстанциясе корпусы алыштырылды, ә Буа электр челтәрләре 10 кВ лы электр тапшыручы һава линияләре терәкләрен алыштырдылар.

– Бу вакыйгалар турында без «Россия челтәрләре» ГАҖ һәм РФ Хезмәт министрлыгындагы коллегаларыбызга хәбәр иттек. Алар белән бергә РПН буенча норматив-техник документацияне үзгәртү юнәлешендә эшлибез, – диде «Челтәр компаниясе» ААҖнең электр энергиясе сыйфаты һәм көчәнеш астында эш бүлеге башлыгы **Айнур Абдуллаҗанов**.

ҺӘРКЕМ ИРЕШЕРЛЕК ПРОФЕССИОНАЛИЗМ

Универсальлек, аралаша белү, ышанычлылык, иҗади якын килү кебек күнекмәләр таләп ителәчәк киләчәккә йөз тотып, компания белгечләрне даими укыту-өйрәтүгә зур игътибар бирә һәм, мондый программалардан һәркем файдалана алсын өчен, шартлар тудырырга омтыла. Ноябрь ахырында Мәскәүдә инвалидлар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикле затлар арасында «Абилимпикс» V Милли һөнәри осталык чемпионаты узды. 540 кеше призёр һәм җиңүче дип табылды. Алар арасында – электр счётчикларын эксплуатацияләү буенча 4 разрядлы электромонтёр, «Түбән Кама электр челтәрләре» филиалы вәкиле Андрей Биряльцев та бар. Бу уңыш – үз хезмәткәрләре – чын профессионаллар һәм җиңүчеләр белән бергә бары тик алга атлавын тагын бер мәртәбә раслаган компаниянең дә җиңүе.

МӘҖИТ САЛИХОВ:
«КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫК ҺӘМ ЫШАНЫЧЛЫЛЫК – ТАТАРСТАНДА ТӨЗЕЛЕШНЕҢ ТӨП ШАРТЛАРЫ»

Төзелеш турында сүз чыккач, төзелгән объектларның иң төп сыйфаты буларак, күбебез аларның ышанычлылыгы турында уйлана. Җәмгыять өчен кирәкле булган әлеге сыйфатны катгый тикшерү эшен Мәҗит Салихов җитәкчелегендәге «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе үз җаваплылыгына ала. Нәкъ менә әлеге ведомство хезмәткәрләре 2018 елгы FIFA дөнья чемпионаты, Иннополис, «КАЗАН ЭКСПО», Болгар ислам академиясе, Зур Казан боҗрасы юл чатлары һәм башка бик күп объектларның проектларын тикшерде.

«ТР ДЭБИ» ДАУ бик мөһим һәм җаваплы эш башкара, әлеге хезмәт проектлау, төзү һәм эксплуатацияләү барышында биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгын һәм ышанычлылыгын тәэмин итүдән, шулай ук инвестиция-төзелеш эшчәнлегендә дәүләтнең бердәм бәя сәясәтен тормышка ашырудан гыйбарәт. Шулай итеп, бу оешма иҗтимагый файдалы эш кенә башкарып калмый, дәүләт дәрәҗәсендәге бурычларны да хәл итә.

Учреждение бик күп төрле дәүләт хезмәтләре күрсәтә – проект документларына һәм инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә экспертизадан алып, инвестицияләрне нигезләүгә технологик һәм бәя аудиты үткәрүгә кадәр. Белгечләр капиталь төзелеш объектлары реконструкциясе һәм капиталь ремонтының, шулай ук төзелә торган биналарның сметасын тикшерә. Учреждение төзелештә бәя кую мәсьәләләре буенча республиканың эксперт үзәге булып тора.

Мәҗит Хаҗип улы тырышлыгы, шулай ук турыдан-туры гамәлгә куючы сыйфатындагы ТР Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы ярдәме белән инновацияләр актив рәвештә кертелә. Мәсәлән, электрон экспертиза үткәрү шундый яңалыкларның берсе, ул исә мөрәҗәгать итүчеләр өчен экспертиза процедурасын үтә күренмәле итәргә, шулай ук хезмәт күрсәтү вакытын һәм командировка чыгымнарын киметергә мөмкинлек бирә. Электрон гаризалар кабул итү 2017 елга билгеләнсә дә, учреждение электрон экспертиза ысулын 2016 елда беренчеләрдән булып куллана башлый! Учреждение үз эшендә бик мөһим мәгълүмат системасы – бердәм мәгълүмат базасына юл ача торган Бердәм дәүләт экспертиза бәяләмәләре реестрын (ЕГРЗ) уңышлы файдалана.

– Хәзерге дөньяда икътисадны цифрлаштыру бик кирәк, бу – гражданнар өчен безнең хезмәттән файдалануны кулайлаштыра һәм мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы шартлар тудыра, чөнки дәүләт экспертизасы ниндидер административ киртә түгел ул, ә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган заманча учреждение. 30 елдан артык дәвам иткән уңышлы эшебез дәверендә безгә ышана, хезмәтебезнең мөһимлеген

Реклама Фотолар «ТР ДЭБИ» ДАУ матбугат хезмәтеннән алынды



аңлый башладылар. Шуңа күрә бүген «ТР ДЭБИ» ДАУ тарафыннан тикшерелгән объектларының географиясе Татарстаннан бик читкә – Себердән Санкт-Петербургка кадәр, Сахалиннан алып Самарага кадәр тарала, – дип белдерә учреждение җитәкчесе Мәҗит Салихов. – Татарстан Республикасы Дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе – проектлаштыру этабында булачак объектның сыйфатын һәм куркынычсызлыгын раслау дигән сүз. Чөнки куркынычсызлык һәм ышанычлылык – Татарстанда төзелешнең төп шартлары!

Һәм бу сүзләрнең чын дәлиле бар, чөнки «ТР төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» ДАУ Татарстанның визит карточкасына әверелгән, илебездә төзелеш тармагының дәрәҗәсе һәм үсеш сыйфаты турында бөтен дөньяга сөйләгән һәм һәр татарстанлының тормышында лаеклы урын тапкан иң төп объектларга экспертиза үткәрде. Учреждение белгечләре, аерым алганда, 2018 елгы Футбол буенча FIFA дөнья чемпионатын уздыру өчен тренировка мәйданчыкларын, мәдәни мирас объектларын (Болгар ислам академиясе һәм Свияжскида Тарих музее), «КАЗАН ЭКСПО» Халыкара күргәзмә үзәген, Казанда «Салават күпере» торак комплексын, ИТ-технологияләр каласы – Иннополис төзелешен, күпсанлы паркларны һәм скверларны, яр буйларын, Түбән Камада һәм Чаллыда татар драма театры биналарын реконструкцияләүне, Зур Казан бофрасында транспорт өчен юл чатларын һ. б. тикшерде. Соңгы дүрт елда Татарстанның бюджет акчалары хисабына төзелгән 15 000 тирәсе объект техник регламент таләпләренә туры килүе һәм смета бәясенең дөреслеге мәсьәләсендә уңай экспертиза бәяләмәсен алды.

Коллективның бердәмлеге һәм аның югары квалификациясе «ТР ДЭБИ» ДАУ нең аерым горурлыгы булып тора. Учреждениедә аттестацияләнгән 44 эксперт эшли. Татарстанда төзелгән объектлар республика халкын һәм кунакларын шатландырсын, иң югары таләпләргә туры килсен өчен, барысын да эшли торган учреждениенең уникаль кеше капиталын тәшкил итә ул белгечләр. Оешма җитәкчелеге үз кадрларын югары бәяли һәм коллективның сәламәтлегенә һәм актив ялын оештыруга зур игътибар бирә. Учреждениедә мини-футбол һәм волейбол командалары оештырылган.

«ТР ДЭБИ» дәүләт автоном учреждениесенең нәтиҗәле эшен Мәҗит Салихов шәхесе белән бәйләп карыйлар. Аның хезмәт биографиясе эшче һөнәрләрдән алып республика дәрәҗәсендәге югары җитәкче вазыйфаларга кадәр озын һәм эзлекле юлдан гыйбарәт. Аның юл төзелеше тармагындагы һәм дәүләт хезмәтендәге зур эш тәҗрибәсе учреждение коллективын яңа казанышларга алып барырга ярдәм итә. Татарстанның атказанган төзүчесе Мәҗит Салиховның эше лаеклы бәяләнә һәм иң югары дәрәҗәдә билгеләп үтелә. РФ һәм ТР Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыкларының, ТР Президентының һәм төрле федераль ведомстволарның күпсанлы рәхмәтләре моңа дәлил булып тора.

Авыр тормыш хәлләренә тарыган кешеләргә ярдәм итеп, «ТР төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» ДАУ ел саен актив социаль эш алып бара. Татарстан инвалидлар җәмгыяте, ТКХ өлкәсендә иҗтимагый контроль буенча төбәк үзәге белән берлектә, авыр хәлдәге хасталарга, инвалидларга, пенсионерларга хәйрия ярдәме күрсәтелә. Тарихи мирас объектлары, спорт чаралары, авыллардагы мәдәни-агарту учаклары финанс ярдәме ала. «Уңайлы мохит» проекты кысаларында төзелеш объектларын уңайлы, кулай итеп кору буенча ел саен укулар үткәрелә. Учреждениенең уку үзәгендә ел саен 300 дән артык кеше бушлай әзерлек уза.

2017 елдан Мәҗит Салихов Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов исеменнән республика активы вәкиле булып тора. Ул Балтач районына булышлык күрсәтә. Аның катнашында малайлар өчен пансионат, Халыклар дуслыгы музее төзелде һәм ачылды, шулай ук сабантуй, мәктәпнең чыгарылыш кичәсе, «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит!» хәйрия акциясе һ.б. узды. Шул ук вакытта Мәҗит Салихов һәрвакыт ассызыклый: аның өчен иң мөһиме җәмәгатьчелек тарафыннан танылу түгел, ә кешеләрнең иминлеге.

– Хөрмәтле татарстанлылар! Шәхсән үзем һәм тату коллективыбыз исеменнән сезне якынлашып килгән Яңа ел бәйрәме белән чын күңелдән котлыйм һәм эшләрегездә уңышлар, бәхет, сәламәтлек, уй-ниятләрегезнең чынга ашуын телим! Яңа 2020 елда сезне якты вакыйгалар һәм матур бәйрәм могҗизалары көтсен!

Хөрмәт белән,
«ТР ДЭБИ» ДАУ башлыгы
Мәҗит Салихов

facebook.com/protatarstan

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

twitter.com/protatarstan

instagram.com/protatarstan

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ
РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

Реклама 16+

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Татарстанлылар **НИЧЕК** каһарман булалар

Теләчедә сәнәгать паркы **НӘРСӘ** җитештерә

Яңа ел табынын **НИНДИ** сый белән бизәргә

«2019 КАҺАРМАНЫ» КАЛЕН

Каһарман булыр өчен нишләргә кирәк? Граната тотып дошман танкы астына ташланыргамы? Суга батучыны коткарыргамы? Янган йорттан сабыйны алып чыгаргамы? Ожегов сүзлеге каһарманны батырлык кылган зат дип кенә билгеләми. Каһарман булыр өчен шәхес түбәндәге сыйфатларга да ия булырга тиеш: «үз заманының һәм дәверенең чалымнарын үзендә чагылдырган» һәм «башкаларның игътибарын җәлеп иткән, соклану тудырган, үз артыннан ияртергә сәләтле булган» зат та әле ул.

ЕЛ
ННАРЫ»
ДАРЕ

Безнең каһарманнар календаренда нәкъ менә шундый затлар тупланган да. Алар сокландыра, аларга охшыйсы килә, алар үзләрендә заманыбыз һәм чорыбыз чалымнарын чагылдыра. Бик тә гадәти һәм үзенчәлекле каһарманнар – мәрхәмәтле, кыю, тәвәккәл, креатив, кешелекле. 2019 елны җиңүләре һәм кылган гамәлләре белән бизәүчеләр!

ГЫЙНВАР



ЭДУАРД НИКОЛАЕВ ЭКИПАЖЫ,
«КАМАЗ-МАСТЕР» КОМАНДАСЫ

Бу планетаның төп ярыш марафоны. Перу юллары буйлап җилдергән «Дакар-2019» ралли-рейдын эскпертлар әнә шулай атады. 17 гыйнварда әлеге марафонның финишына беренче булып Эдуард Николаевның КАМАЗы килде.

Командалар һәм моторлар ярышында Чаллының «Зәңгәр армадасы» иң баштан ук фаворитлар иде. Әмма Көньяк Американың комлы һәм таулы серпантины буйлап сузылган коточкыч катлаулы трасса һәм оештыручыларның астыртынлыгы Россия экипажына шактый кыенлыклар китерде. Финишка 6 гыйнварда Лимадан кузгалып киткән КАМАЗның икесе генә килеп җитә алды. Айрат Мәрдиевнең экипажы двигатель сынавын үтә алмаса, Андрей Каргиновны ярыш сафларыннан оештыручыларның шактый четерекле һәм шикле карары чыгарып ташлады. Күрәсең, шул рәвешле йөк машиналары ярышында интрига сакларга тырышулары булгандыр, дип фаразлыйк.

Ярышта калган Эдуард Николаев белән Дмитрий Сотников экипажларына «афәрин» дияргә генә кала. Командадагы иптәшләреннән мәхрүм булуга карамастан, ике экипаж да раллиның калган өлешен искиткеч чиста һәм югары кимәлдә узды. Казыйларның сәер карарлары да, ватылулар да, хәтта янга авып төшү, комга батып калу кебек хәвефләр дә Россия КАМАЗларын сафтан чыгармады. Алар ахыргача башкалар өчен теш үтмәслек көндәш булып кала бирде.

Перу башкаласында, ралли-рейдның финишында, казыйлар да безнең КАМАЗларның күпкә өстенлекле булуын танырга мәҗбүр булды. Эдуард Николаев экипажы – беренче, Дмитрий Сотниковныкы – икенче. Башка көндәшләр алардан сәгать ярымга калышты! Бу бернинди чагыштыруларга урын калдырмаган җиңүнең безнекеләргә нинди бәһа белән бирелгәнен саннар раслый: ярыш башында старт алган 34 йөк машинасының финишка 14 е генә килеп җитте. Ярышта катнашкан 318 автомобиль белән мотоциклның исә нибары180 е килде.

Эдуард Николаев пилот сыйфатында «Дакар»ның 4 нче мәртәбә җиңүчесе булды (2013, 2017, 2018, 2019 еллар). Тагын бер тапкыр – 2010 елда – ул раллида Владимир Чагин экипажындагы механик рәвешендә җиңү яулаган иде. Владимир Чагин бүген – «КАМАЗ-Мастер» командасының җитәкчесе. Ә «КАМАЗ-Мастер» үзе ралли-рейд алтынына тәгәл 16 мәртәбә ия булды!

«Дакар-2019» мәртәбәле халыкара раллиенда чираттагы тиңсез җиңүегез белән чын күңелдән котлыйм һәм ихластан сокланам сезгә». Җиңүчеләргә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов юллаган телеграмма әнә шундый сүзләр белән башланып китә һәм болай дәвам итә: «Тагын бер әһәмиятле һәм катлаулы биеклек алынды. Сезнең бу җиңүегез КАМАЗ яшьләренең үзләренә кадәрге осталар традицияләрен ышанычлы һәм югары кимәлдә дәвам итүенә дәлил булып тора. Һәрвакыттагыча, «КАМАЗ-Мастер»га җиңүне менә дигән, куәтле техника һәм спортчыларның югары профессиональлеге тәэмин итте. Шулай ук – команданың бердәмлеге, кодрәте, рух ныклыгы һәм җиңүгә булган какшамас ышанычы. Эдуард Николаев һәм Дмитрий Сотников экипажларына, гомумән, бу җиңүгә үзеннән өлеш керткән һәркемгә, максатларына тугры булганнары, олы, авыр хезмәтләре өчен рәхмәт белдерәм. Сез җиңүегез белән бизәгән 2019 ел камазлылар өчен дә, республика өчен дә яңа казанышларга һәм ирешүләргә бай булсын. Сезгә бәхет, сәламәтлек һәм уңышлар телим!»

ФЕВРАЛЬ



Фото «Татарстан Республикасында Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» ДБУнән алынды

ЛЕНАРА МОЗАФФАРОВА,

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ДӘҮЛӘТ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТЛӘР КҮРСӘТҮ КҮПФУНКЦИЯЛЕ ҮЗӘГЕ» ДБУ ДИРЕКТОРЫ

Оешманы 2015 елның февраленнән җитәкли башлап, бу көчле характерлы гүзәл хатын-кыз республикадагы инде хәзер үк уңайлылык революциясе дип йөртелгән иң шәп социаль-икътисадый проектларның берсен гамәлгә ашырды.

Ул җитәкләгән коллектив 8–10 елга исәпләнгән юлны дүрт ел эчендә уза алды. Республикадагы автоном һәм таркау КФҮ офислары бердәм челтәргә берләштерелде, аларның эшчәнлеге иң югары нәтиҗә бирерлек итеп стандартлаштырылды. Бүген Татарстанда 57 «Минем документларым» офисы, шулай ук ерактагы авыл җирлекләрендә 281 кабул итү бүлеге бар. 2015 елда федераль, төбәк, муниципаль хакимият органнары 80 төрдәге хезмәт күрсәтсә, хәзер әлеге офисларда күрсәтелә торган хезмәт төрләре 190 га җиткән. Ел азагына күрсәтелгән хезмәтләр саны 5 миллионга җитәр, дип фаразлана.

Мерфи законнарыннан берсендә хатын-кызга уңышлы карьера ясау өчен кирәкле өч бурыч аңлатыла: ирләр кебек уйла,үзеңне хатын-кызларча тот, ат кебек эшлә. Мөгаен, Ленара Мозаффарова очрагы нәкъ менә шул законга туры киләдер. Бер генә төзәтмә белән. Аңа бу гаять зур проектны гамәлгә ашыра башлаганда, ирләргә караганда да куәтлерәк һәм алдынгы фикерлерәк булырга туры килә. Һәм эшләргә, эшләргә, эшләргә...

Якын киләчәктә күпфункцияле үзәкләр дәүләт һәм гражданин йөзгә-йөз карашып хезмәттәшлек итә торган бердәнбер урын булып калырга мөмкин. Ленара Әкмәлетдин кызы исә үз көченә ышана: «Әгәр шундый бурыч куела икән, бу да республикабызның хәленнән киләчәк», – ди ул.

Дәүләт сервислары заманнан артта калмасын өчен, бүген республикадагы барлык КФҮ даими яңару режимында эшли. Яңа хезмәт төрләре күрсәтү арта, комплекслы гариза кабул итү гамәлгә кертелә, офислар саны ишәя, планда – күпфункцияле үзәкләрнең кул сузымында гына урнашкан кече формаларын булдыру. Быел Казанда «Салават күпере» ТК, Юдино бистәсендә, Авиатөзелеш районында, шулай ук Түбән Камада яңа КФҮ офислары ачылган, Чаллыдагысы яңартылган. Мозаффарова командасының максаты – хезмәт күрсәтү өчен гариза тутыруга нибары 10–15 минут вакыт кына китәргә тиеш.

Һәм, ниһаять, иң мөһиме – КФҮ эшеннән халык канәгатьме? Федераль система мәгълүматлары буенча, 2018 елда биргә мөрәҗәгать итүче татарстанлыларның 97 проценты күпфункцияле үзәк эшенә уңай бәя биргән.

Әмма карьера, рейтинглар һәм эштән тыш дөнья да бар бит әле. Һәм энергияле, алдынгы карашлы һәм бик матур директорның тормышы да актив һәм тулыканлы. Үз кул астында эшләүчеләргә карата гадел булу, татарларга хас булганча гаилә турында кайгырту. 7 гыйнварда узачак туган көнен дә, мөгаен, нәкъ менә якыннары белән бергә үткәрер – җылы һәм шапырынуларсыз. Балык тоту, розалар үстерү, тәмле ризыклар әзерләү, бөтенләй таныш түгел кешеләр проблемаларына битараф калмау... Боларның барысы да бер хатын-кызга ничек сыя соң? Җавап, мөгаен, Мерфи законының соңгы ике пунктындадыр...

МАРТ

ВЛАДИМИР ЖАВОРОНКОВ,

РОССИЯ ЛИДЕРЫ

17 мартта «Россия лидерлары» Бөтенроссия идарәчеләр бәйгесенең җиңүчеләре билгеләнде. Ул вакытта әле Республика клиник онкология диспансерының баш табибы урынбасары булып эшләгән Владимир Жаворонков та җиңүчеләр арасында иде...

«Барысы да бик гадәти иде – сайлау мөмкинлегем булмады». Үз тормышын ни өчен медицина белән бәйләве турында сорауга Владимир Жаворонков әнә шулай дип җавап бирә. «Бөтен туганнарың табиблар булып, син көн саен аларның үз-үзләрен корбан итәр дәрәҗәдә эшләвен күзәтсәң, ә теләсә кайсы гаилә табыны һәрчак һөнәри бәхәсләргә әверелә икән – синең тормыш юлың инде билгеле». Тик шулай да сайлау алдында кала ул. Бу гамәл җиңелләрдән булмый, ләкин андый сынауны үтәргә туры килә. Моннан биш ел элек республика онкодиспансеры баш табибы аңа оештыру-методик эш буенча урынбасар вазыйфасын тәкъдим иткәч, Владимир аңлый: үз табиблык практикасын алып бару өчен вакыты калмаячак дигән сүз. Җитәкче урынында килеш күбрәк кешегә файда китерә алырмын, дип, ул ризалык бирә. Владимир Жаворонковтан нәтиҗәле җитәкче чыгуы онкодиспансерның уңышлары һәм масштаблы проектлары белән генә түгел, ә «Россия лидерлары» Бөтенроссия конкурсында җиңүе белән дә раслана.

«Безнең горурланырлык проектларыбыз күп. Аларның һәркайсында дилбегәне кем тотуы – икенчел мәсьәлә, чөнки команда белән ирешелгән тырышлыктан башка шәхси казанышлар булмый», – дип саный Владимир. Шундый проектларның берсе – «Шешләргә каршы белем» дип аталганы – Жаворонковның конкурс эше өчен прототип була.

Проект Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан 2016 елда гамәлгә куела. Төп нигезләмә шуннан гыйбарәт: иң иртә стадиясендә ачыкланган икән, 85 процент очракта яман шешне дәваларга була. Өстәвенә, бу авыруны кисәтергә дә мөмкин! Тормыш рәвешенә бераз гына төзәтмәләр кертеп җибәрү дә яман шеш авырулары килеп чыгу ихтималын киметергә мөмкинлек бирәчәк. Чыннан да, кисәтелгәнсең икән, алдан коралланып куйгансың дигән сүз. Социаль рекламадан тыш, проект онколог-белгечләрнең республикадагы эре сәүдә үзәкләрендә күчмә акцияләр үткәрүен дә күздә тота. Бу вакыт эчендә проектта меңләгән татарстанлы катнаша. Аларның кайберләрендә табиблар яман авыруны иң башлангыч мизгелдә «эләктереп ала». Халыкны агарту эшенә берничә ел җитәкчелек иткән Жаворонков проектны алга таба үстерергә тәкъдим итә. Шулай итеп, проект яңа юнәлеш ала – чын мәгънәсендә белем бирү өлкәсенә килеп керә, чөнки онкологлар укытучылар һәм мәктәп хезмәткәрләре өчен лекцияләр укый һәм аларга тикшерү уздыра. Мондый формат үтемле булып чыга һәм Владимирны җиңүгә якынайта.

«Мин онкология өлкәсендә республика данын яклаган кешеләр традициясен дәвам итүче булырга телим. Үз эшең өчен оят булмаслык итеп. Бу теләк – мине һәрчак зуррак, колачлырак нәрсә турында хыялланырга мәҗбүр итә торган этәргеч ул», – дигән иде «Татарстан» журналына интервьюсында Владимир. Анда искә алынган «зуррак нәрсә» күптән түгел чынга да ашты – Владимир Жаворонков ТР Сәламәтлек саклау министры урынбасары итеп билгеләнде. Безгә исә аның җитәкчелек таланты, изге ниятләр белән кушылып, тулысынча ачыла күрсен, дип хыялланырга гына кала.

Фото Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясеннән алынды

АЙДАР ФӘЙЗРАХМАНОВ,
РОССИЯНЕҢ ҺӘМ ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК АРТИСТЫ

26 апрельдә Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең, Татарстан дәүләт фольклор музыкасы ансамбленең сәнгать җитәкчесе Айдар Фәйзрахманов Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты булды.

Дәүләт премиясен Айдар Фәйзрахмановка Илһам Шакиров исемендәге концертлар залын ачкан һәм Тукайның туган көне, Туган тел бәйрәме билгеләп үтелгән көнне тапшыруның үзенә бер символик мәгънәсе бар. Бөек шигърият, туган тел-туган көйләр, җыр-моң, биюләр кебек үк теләсә кайсы халыкның мәңгелек кыйммәтләре. Фәйзрахманов һәм аның ансамбле – бу кыйммәтләрне саклаучылар гына түгел, алар халык көйләренә яңа сулыш өреп, вакытлар узган саен тоныклана барган асылташларны ачык төсләр белән балкыта алучылар.

– XXI гасырның үз тизлеге, үз өстенлекләре. Шулай да мәңгелек кыйммәтләр бар, – дигән фикердә Фәйзрахманов. Һәрбер халыкның шундый бер кыйммәте – фольклор. Бу – халык байлыгы. Аны сакларга, халыктан алып халыкка кайтарырга, дөньяга танытырга кирәк.

Ансамбльнең барлык номерлары да чын фольклор материалына нигезләнгән. Әмма тамашачы аларны заманча эшкәртелгән хәлдә күрә, шуңа да «халык классика»сы безнең прагматик дәвергә хас туң җаннарны да эретерлек сәләткә ия.

«Татар фольклор мирасын өйрәнүгә, үстерүгә һәм популярлаштыруга керткән өлеше һәм аны дөньяның музыкаль пространствосына интеграцияләгән, «Олы юл» авторлык кичәләре циклы, фольклор әсәрләрен эшкәртеп, ноталардан ике томлык, җырлар һәм романслардан торган авторлык җыентыклары бастырып чыгарган өчен» – Айдар Фәйзрахмановка премия бирү турындагы указ әнә шулай яңгырый.

Рәсми гомумиләштерүләрдән китеп, гадирәк итеп тә әйтергә була. Чын мәгънәсендәге халык артисты һәм ансамбль җитәкчесенең казанышы шунда: планетаның теләсә кайсы почмагында, нинди генә мәдәният вәкиле булмасын, нинди генә телдә сөйләшмәсен, Фәйзрахманов ансамбленең чыгышын күргән кеше татар мәдәниятенә гашыйк булып кала. Без Универсиада-2013, 2018 елгы бөтендөнья футбол чемпионаты, WorldSkills 2019 дөнья чемпионаты көннәрендә моның шаһиты булдык. Фольклор ансамбле чыгышлары һәркайсында мәдәни программаларның бизәге иде...

Бервакыт бөтендөнья челтәрендә ансамбльдән «алып торган» репертуарны күргәч, Айдар Фәйзрахмановтан: «Нишләп үзегезнең авторлык хокукларын якламыйсыз, сезнең материалны файдаланган өчен акча таләп итмисез?» – дип сораганнар. Мәтрнең җавабы мондый булган: «Без халкыбызның традицияләре халыкка барып җитсен өчен эшлибез дә инде!»

Ә ул иске җырларны, биюләрне тормышка кайтару күпме тырышлык, күпме хезмәт таләп итә! Алар яңача яңгыраш алсын өчен, аларны табарга, кайчак югалганны торгызырга кирәк бит әле. Республика һәм Россия төбәкләре буйлап иҗади экспедицияләр вакытында җырлар, көйләрне яздырып алалар, еш кына алар бер гасырдан артыграк элек барлыкка килгән булалар, милли киемнәрне өйрәнәләр. Татарстан Президенты грантына чыгарылган җыентыкта, җырлардан тыш, 15 уен кораллары әсәре, 16 биюнең тасвирламасы кергән. Элек аларны югары сәнгатьчә эшләнештә беркем дә башкармаган. Болар барысы да – экспедицияләр нәтиҗәсе.

Билгеле булганча, Фәйзрахманов һәм аның ансамбле еш кына республика районнарына чыгып, мәктәп укучыларына үзенчәлекле дәресләр үткәрә. Мондый дәресләрдә һәркем уен коралларын тотып карый, хәтта уйный ала. Бик күпләр, татарлар гына түгел, милли киемнәрдәге артистлар белән фотога төшәләр, аннан соң ул фотоларны социаль челтәрләрендәге сәхифәләренә урнаштыралар.

– Сәнгатьнең милләте юк! – ди Айдар Фәзрахманов. – Милли орлык бар, аны сакларга һәм үстерергә кирәк.

МАЙ

РАМИЛ БАҺАВИЕВ,
2019 ЕЛГЫ ЧЫГАРЫЛЫШ УКУЧЫСЫ

БДИ нәтиҗәләре билгеле булганнан соң, Рамил Баһавиев исеме телдән төшмәде. Казанның Мәрҗани исемендәге татар гимназиясе укучысы рус теле, информатика, физикадан – 100 балл, математикадан – 99 балл, җәмгысе 399 балл җыйган икән!

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Рамилне Хөкүмәт йортында узган республика киңәшмәсендә чыгыш ясарга да чакырды. Акыллы егет тыйнак кына:

– Мине татар гимназиясенә укырга бирү әти-әниемдә шикләнү тудырмаган. Алга таба мин әлеге карарның дөреслегенә инандым. Киләчәк тормышымда аның хәлиткеч роль уйнаганын аңладым. Уңышларым өчен әти-әниемә, яраткан гимназиямә рәхмәтлемен, – дип сөйләде.

Рөстәм Миңнеханов исә, басым ясап:

– Күрегез: гап-гади гаиләдә тәрбияләнгән бала. Унбер ел буе татар телендә белем алган, – дип ассызыклады.

Әйе, Рамил барлык фәннәрне дә туган телендә – татарча укыган. Татарча укып, рус телендә имтихан биреп булмый, диючеләрнең борынына чиертте ул. Егет бүген КФУның Лобачевский исемендәге математика һәм механика институтында белем ала. Тагын мәктәп укучылары өчен онлайн-дәресләр үткәрә – БДИга әзерли.

– Киләчәктә мәктәп укучылары белән эшләүне киңрәк җәелдерәсем килә, – диде Рамил.

Сер түгел, югары балл җыючылар Мәскәү, Санкт-Петербург кебек шәһәрләрдә уку җаен карый. Рамилгә дә андый тәкъдимнәр булган. Тик ул туган шәһәрен сайлаган.

– Минемчә, Казанда да яхшы белем алырга, үз потенциалыңны ачарга мөмкинлекләр бар, – диде егет.

Әлбәттә, татарча уку турында сөйләштек. Бу уңайдан Рамилнең үз фәлсәфәсе:

– Иң мөһиме – нинди телдә уку түгел, аның мәгънәсен аңлау, төшенеп уку, – диде ул. – Яшермим, гимназиядә безгә имтиханга әзерләнгәндә рус телендәге терминнарны да кулланып укыттылар. Ләкин фәнне белсәң, терминның кайсы телдә булуы мөһим түгел, барыбер аңлыйсың. Тагын шуны әйтим: ике телне камил белсәң, өченчесен тизрәк өйрәнәсең, аннан дүртенчесен дә…

ИЮНЬ

Фото: Алёна Кутыркина

АЛИЯ НАСЫЙБУЛЛИНА,
ТАБИБ-ТОКСИКОЛОГ

Алия Насыйбуллина һәм аның хезмәттәшләре «булмас» дип әйтерлек нәрсәне эшләгән – яшел мамба еланы чаккан кешене коткарып калганнар. 14 июньдә Казанда табиблар командасын хөрмәтләделәр. Алия Насыйбуллина һәм Казанның 7 нче клиник хастаханәсе табиблары төркеме «Ел табибы – Ак чәчәкләр» республика конкурсының «Уникаль очрак» номинациясендә премиягә лаек булды.

7 нче шәһәр хастаханәсе табиблары өчен ул вакыйга «ашыгыч ярдәм»гә шылтыратудан башлана. Безнең төбәк өчен гадәти очрак – кара елан тешләвеннән зыян күргән пациент килә дип уйлыйлар, чынлыкта аларны «экзотика» көткән булып чыга.

– Әлбәттә, без шок хәлендә идек, чөнки яшел мамба дөньяда иң куркыныч еланнарның берсе санала, – дип сөйли Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының баш штаттан тыш токсикологы, 7 нче клиник хастаханәнең токсикология бүлеге мөдире Алия Насыйбуллина. – Аның агуы бик көчле нейротоксик тәэсиргә ия, барлык мускулларның тонусы бетүгә, йөрәк тибеше, сулыш тukталуга китерә... Кеше сәгать ярым, ике сәгать эчендә үлеп китәргә мөмкин. Пациент безгә килгәндә инде авыр хәлдә иде...

Иң дөресе, аны дәвалауны махсус антидот сүл кадаудан башларга кирәк иде. Куркынычсызлык техникасы буенча, андый агудан дәва зоопаркта сакланырга тиеш. Тик Казан зообdanика бакчасында мондый еланнар асралмый, димәк, анда кирәкле сүл дә юк. Бу хәлдә ни кылырга? Россиядә мондый куркыныч елан тешләү очраклары өчен әзерләнгән дәвалау стандартлары каралмаган, чөнки безнең якларда мондый хәшәрәтләр юк.

Казан табиблары АКШ токсикология үзәгендәге хезмәттәшләре белән элемтәгә керә – алар өчен мондый хәлләр сирәк күренеш түгел. Тик янә барысы да антидотка килеп терәлә: зыян күргән кешегә сүлне санитар авиация белән егерме минут эчендә китереп җиткерү – Америка табибларының эш алгоритмы әнә шундый. Санкт-Петербург табибларының моңа охшаган очракка тарыганы, дөрес, яшел түгел, кара мамба еланы чаккан пациент белән эш иткәне булганын белеп алгач, казанлылар шунда шылтырата. Тик, кызганычка каршы, төньяк башкала табибларының тәҗрибәсе аяныч булып чыга – алар пациентны саклап кала алмаган.

– Безгә беркемнең дә ярдәм итә алмаячагын аңладык, шуңа күрә вазгыятькә төшенеп, тизрәк нидер кылырга һәм үз дәвалау стратегиябезне булдырырга туры килде. Сүз антидотсыз гына дәвалау турында бара, – дип сөйли Алия Насыйбуллина. – Беренчедән, без пациентка елан тешләгән урыннан өстәрәк жгут салдык. Бу агуның тәнгә таралуын күпмедер вакытка туктатты. Әмма жгутны салдырган саен, авыруның хәле начарлана барды.

Табибларның стратегиясе вакытны, агуның таралу тизлеген узып, алардан алга чыгуга нигезләнә. Агуның зарарлы тәэсирен һәм мишень органнарны ачыклап, агу зыян салганчы, табиблар аларны саклау операциясен үткәрә. Мәсәлән, йөрәк җитkelексезлегe килеп чыгарга мөмкин икәнен белеп, йөрәкне саклау чарасын күрәләр. Баш мие үлү вакытын хисаплап, аны саклау тактикасын коралар... Пациентның гомерен саклап калу өчен, янынnan бер минутка да китмичә, табиблар ун көн буе көрәшә. Бары шулкадәр вакыт узгач кына, авыруның исән калачагы ачыклана. Өстәвенә, тулы канлы, сәламәт тормыш белән яши алачагына ирешәләр. Бу бик катлаулы, бик нечкә, команда белән башкарылган эш була. Һәм әлеге җиңүне медицинада дөнья рекорды дип атарга мөмкин.

ИЮЛЬ

ЧУЛПАН ХАМАТОВА,
АКТРИСА

Июль аенда мәскәүлеләр өчен «Зөләйха күзләрен ача» сериалы күрсәтелде. Тамашачыларны тема белән якыннан таныштыру өчен Хаматова китаптан иң дулкынландыргыч бер өзек укыды. Максатына иреште ул: актрисаны бер сәгатькә якын тын да алмыйча тыңладылар.

Зөләйха роле һәм аны башкаручы гүя берсен-берсе эзләгәннәр диярсең. Чулпан Хаматова Казанда туа, театр училищесында укый, аннан соң Мәскәүгә ГИТИСка китә. Башта кинематографиядә, аннан соң театрда бер-бер артлы төрле проектларда катнаша. Кызлары туа. «Подари жизнь» хәйрия фонды барлыкка килә. Хаматова үткән тормышына сирәк кайта, ләкин Гүзәл Яхина романы барысын да үзгәртә.

– Мин озак кына әле бу китапны укымый тордым, бөтен кеше дә укыган китапны укырга яратмыйм, яраттылар да «үзләштерделәр» кебек тоела. Шулай бервакыт, балаларга дәфтәрләр алырга дип, китап кибетенә кердем, чыкканда гына «Зөләйха»ны күреп, сатып алдым. Кич белән укый башладым да аерыла алмадым, – ди Хаматова чыгышларының берсендә.

Татар тамырлары, традицияләр, атабабалар хәтере, аяк киеме артеле хуҗасы булганга репрессияләнгән бабасының тарихы – романны укыгач, актриса боларның әһәмиятенә яңадан төшенә. Үзен Зөләйха ролендә күрми әле, роман героинясы күпкә яшьрәк кебек тоела. Ә менә «Зөләйха»ны баштарак киносценарий итеп күзаллаган, соңыннан гына роман итеп язган Гүзәл Яхина Хаматованы шунда ук әлеге рольне башкаручы актрисаларның берсе итеп, исемлеккә теркәп куя.

– Бу – аның роле, Чулпан татар кызы булганы, яше буенча туры килгәне өчен генә түгел. Анда чисталык, тирәнлек һәм берничек тә җуелмый торган нечкәлек бар. Зөләйханың да асылы шундый, – дип сөйли Яхина «хыял кастингы» турында.

Романның экранизациясе чынбарлыкка әйләнгәч, Чулпан Хаматованы төп рольгә раслыйлар. Проект командасы алдына куелган бурыч җиңелләрдән түгел: романның бөтен тирәнлеген ритмны һәм колоритны саклаган хәлдә телеэкранга күчерү. Хаматовага тагын да катлаулырак бурыч куела: Зөләйханың холкындагы метаморфозаларны ышандырырлык итеп уйнарга кирәк була – башта кыз бала гына диярлек, ахырда инде күңел хөрлегенә, үтерсәң дә, сындырып булмый торган рухи көчкә ирешкән хатын.

– Миндә үз-үземә ышану да юк әле, күңелдә – курку, шул ук вакытта, бәлки, нәрсә дә булса килеп чыгар дигән кыюсыз гына өмет тә бар, – фильмны төшергәндә, үзенең хис-кичерешләрен шулай тасвирлый актриса. Яхина да, продюсерлар да ялгышмаган: экранга карап (фильмның берничә трейлеры чыкты инде) башка Зөләйханы күз алдына китерү дә мөмкин түгел.

– Күңелдә кайтавазы булмаганда, уйнавы кыен. Ә үзең өчен мөһим булган әйберләрне уйнаганда, аны җырлап бирәсе, сөйлисе килгәндә – зур бәхет. Минем өчен «Зөләйха» – әнә шундый проект. Анда характер бар, анда шәхсән үзем өчен авыр тема бар – Сталин репрессияләре. Мин бу рольне уйнавыма шатланам, – дип сөйләде Хаматова журналистларга.

Россиянең «Читка» фестиваленең жюри әгъзалары Гүзәл Яхина романы буенча төшерелгән сериалны 2019 елның иң көтеп алынган экранизациясе дип атадылар.

АВГУСТ

ДАМИР ЙОСЫПОВ,
РОССИЯ ГЕРОЕ

15 августта «Урал авиалинияләре» ширкәтенең Airbus A321 экипажы командиры Дамир Йосыпов салонында 226 пассажир булган самолетны, һәлакәттән саклап калып, кукуруз кырына утырта алды. Шассиларын чыгармыйча, эшләмәгән двигательләр һәм ягулык тулы баклар белән. Бар кеше дә исән калды. Шул ук кичне матбугат очрашуы вакытында пилот пассажирлардан гафу сорады: «Барыгызны да кирәкле урынга вакытында алып барып җиткерә алмавыма мин бераз гаепле...» – диде.

...Кыр уртасында ике метрлы сабаклар арасындагы аэробусны һәм «кукуруз рәтләре буйлап уң яктан кояшка таба...» баручы пассажирларны дөньяның барлык эре телеканаллары күрсәтте һәм моны могҗизага тиңләде. Әлеге могҗизаны исә Дамир Йосыпов һәм икенче пилот Георгий Мурзин тормышка ашырды. Пассажир һәм тамашачылар фаҗиганең никадәр якын булуын шунда ук аңлап та өлгерә алмый калгандыр...

Барысы да кара әрҗәләрне карагач кына ачыклана. Менә һавага күтәрелүгә үк, пилотлар диспетчерларга авария турында сигнал бирә: «ПАН-ПАН» – ике двигательнең берсе эшләми. Менә икенчесе дә эшләүдән туктый, һәм командир инде аэропортка кире кайта алмаячакларын аңлый. Алда – кыр һәм, бик аз булса да, котылу ихтималы. «Ашыгыч ярдәм һәм коткару хезмәте җибәрүегезне үтенәбез,» – дип хәбәр итәргә өлгерә пилот. Диспетчерның: «Сез нинди биеклектә һәм бортыгызда ничә пассажир?» – дигән соравына инде җиргә төшеп утыргач кына җавап бирә: «Биеклек. Без төшеп утырдык. 226 пассажир һәм 7 экипаж әгъзасы». Барысы да эвакуацияләнгән. Корбаннар юк.

...Ә өч айдан соң, 21 ноябрьдә, Россия Президенты Кремльдә Дамир Йосыповка Россия Герое Йолдызын тапшырачак. «Быел җәй Мәскәү янында булган Жуковский – Симферополь рейсы пассажирларын коткару вакыйгасын без барыбыз да хәтерли. Катлаулы авария вакытында һава судносы экипажы профессиональ, төгәл, бердәм эшләде, батырлык күрсәтте», – дип, дәүләт җитәкчесе һәм лайнер командиры белән икенче пилотның роленә югары бәя бирә. «Алар самолетны кыр уртасында утырта алды һәм йөзләрчә гомерне саклап калды. Югары классны очучылар хаклы рәвештә Россия Герое исеменә лаек», – диде.

Бүген югары класслы очучы булган Дамир Йосыпов, табышлы юрист һөнәрен ташлап, очучылар әзерли торган училищега 32 яшендә генә укырга кергән. Поляр түгәрәк арьягында вертолетта очкан Касыйм Йосыпов улы үзен белә башлаганнан бирле күк турында хыялланган. «Беренче тапкыр мөстәкыйль очкан көнем минем өчен иң бәхетле көндер, мөгаен», – диде Дамир «Мәскәү – Татарстан күпере» яшьләр форумында чыгыш ясаганда. Һәм яшьләргә киңәш бирде: «Белүегезчә, самолет җилгә каршы һавага күтәрелә һәм җилгә каршы төшеп утыра да. Шунлыктан сез тормыш кыенлыкларыннан бер дә курыкмагыз, йөрәгегезне тыңлагыз, бирешмичә, гел алга барыгыз».

Сентябрь азагында «Урал авиалинияләре»нең Airbus A321 экипажы командиры кабат үз эшенә кайтты. Аның очышларында бернинди үзгәрешләр дә юк. Тик очып китәр алдыннан динамиклардан күнегелгән: «Корабль командиры пилот Дамир Йосыпов...» – сүзләре генә яңгырамый. Салонда артык эмоцияләр кирәкми, пассажирларны дулкынландыру ярамас. Ул шулай карар кылган.

СЕНТЯБРЬ

Фото: Алёна Кутыркина

АЙДАР МИНЕЕВ,

WORLDSKILLS KAZAN 2019 ҖИҢҮЧЕСЕ

19 яшьлек Чаллы егете Айдар Минеев профессиональ осталык буенча WorldSkills Kazan 2019 дөнья чемпионатында алтын яулаган бердәнбер татарстанлы булды. Сентябрь аенда аны һәм чемпионат призёрлары булган башка иптәшләрен ТР Дәүләт Советында алкышладылар – аларны Татарстан Президенты Дәүләт Советына еллык юллама белән чыгыш ясаячак утырышка чакырганнар иде.

«Прототиплар әзерләү» компетенциясендә Поташов исемендәге техник колледж студенты Айдарның көндәшләре – төрле илләрдән җыелган 11 конкурсант иде. Бирем: 22 сәгать эчендә су астында төшерүче камераның эшли торган прототибын әзерләргә. Жюрида – 12 халыкара эксперт.

WorldSkills чемпионаты тамашачылары мәйданчыкларда барган вакыйгаларны менә ничек кабул итә: тып-тыныч яшь егетләр ашыкмыйча гына манипуляцияләр ясый. Чынлыкта ярыш кызулыгы олимпия уенындагыдан һич ким түгел. Бер генә артык хәрәкәт, бер генә төгәлсезлек булсын – һәм конкурсант, меңнәрчә сәгать әзерлеген сызып ташлап, җиңүгә өметен югалтырга мөмкин. Айдар дөнья чемпионатына дүрт ел буе килгән, 2015 елда тренеры Алим Алмаев җитәкчелегендә WorldSkills стандартлары буенча үткән төбәк чемпионатында юниор категориясендә алтын призёр булганнан бирле. Милли җыелма командага үткәч, ул берничә ел Бразилиядә һәм Кытайда шөгыльләнгән. Кайчакта күнегүләр төннәрен дә дәвам иткән. 2018 елда WorldSrills Европа чемпионатында «CAD инженерлык дизайны» номинациясендә җиңеп чыккан абыйсының үрнәге дә дәртләндереп торган аны. Кыскасы, җиңәргә генә кирәк.

– Мәйданчыкта фон булып яңгыраган татар музыкасы игътибарны тупларга булышты. Һәм тагын үземнең, остазларымның һәм безнең команданың күпме юл үтүен, безнең катнашуыбыз өчен республикабызның һәм аның башкаласының никадәр эш эшләвен аңлау, – дип искә төшерә егет. Нәтиҗәдә татарстанлылылар – иң яхшылар, алар арасында да иң яхшысы – Айдар булып чыга.

«Казан Арена» стадионында чемпионатта җиңүчеләрне бүләкләү тантанасында Минеевларның бөтен гаиләсе, шул исәптән, Айдарның әбисе белән бабасы да катнаша. Сүз уңаеннан, алар КАМАЗның беренче хезмәткәрләреннән була. Һәм Айдар хәзер нәкъ менә КАМАЗның фәнни-техник үзәгендә аддитив технологияләр өлкәсендә инженер-технолог вазифасында хезмәт итә, 3D-бастыру белән шөгыльләнә. Егет вузга керергә, 4.0 индустриясенең булачак белгечләре өчен зарури күнекмәләрне үзләштерергә хыяллана. Россия Президенты Владимир Путин КАМАЗның юбилей тантаналарына килгәч, Айдар Минеев аңа Яр Чаллыда лаеклы технологик вуз булдыруны сорап мөрәҗәгать итте. Мондый инициативага Президент беркадәр гаҗәпләнде, шулай да әлеге мәсьәләне өйрәнергә вәгъдә итте.

– Мин үз шәһәремне, якыннарымны бик яратам һәм алар белән горурланам. Бу кешеләр профессиональ тормышларын Яр Чаллы предприятиеләрендә эшләүгә багышлаган. Мин алар эзеннән барырга теләр идем, шуңа күрә КАМАЗны сайладым, – ди Айдар. – Әмма минем күп дусларым һәм танышларым эре шәһәрләрнең дәрәҗәле вузларына укырга китә һәм, ул вузларны тәмамлагач, җирле предприятиеләргә урнашырга тели. Башкала белеме белән Яр Чаллыга әйләнеп кайтырга теләмиләр. Бездә яшьләрнең киләчәгенә йөз тотсалар, ничек яхшы булыр иде. Мин җиңдем һәм минем яшьтәшләремнең дә җиңүен телим.

ОКТЯБРЬ

Фото Хановларның гаилә архивыннан

ХАНОВЛАР,
ФЕРМЕРЛАР ДИНАСТИЯСЕ

Рөстәм Миңнеханов Татарстан Дәүләт Советына еллык Юлламасында республиканың алдынгы фермер династияләрен атап китте. Алар арасында Тукай районыннан Хановлар да бар иде. Әлеге гаилә агымдагы елда 1 миллион 200 мең баш бәбкә, чеби үстергән.

Казанда Салих Сәйдәшев исемендәге Зур Концертлар залында узган бу чарада үзебезнекеләрне күрү сөенеч булды. Ни өчен үзебезнекеләрме? Хановлар белән агымдагы ел башында танышкан идек. Ул чакта үзләренә генә түгел, балаларына, оныкларына да эш булдырган, бизнес ясаган әти-әни, дәү әти-дәү әни – Гөлнур белән Ренат Хановларга чын күңелдән сокланып кайттык.

Эшнең башы 1990 нчы елларга барып тоташа. Ирле-хатынлы Гөлнур һәм Ренат Хановлар, берничә дистә чеби алып үстереп карый. Икенче елга тагын да күбрәкне алалар. Шуннан, үзләренең ихатасына гына сыймыйча, туган авыллары Калининодагы иске ферма бинасын арендалыйлар. Эшкә балалар да кушыла, чөнки ферма зурайган саен эшче куллар да күбрәк кирәк бит.

Бүген Хановларның фермалары Тукай районының Калинино, Биклән, Яңа Мусабай авылларында да бар. Әле күрше Зәй районында да ачканнар. Һәр ферманың үз хуҗасы дигәндәй. Барлыгы 18 корылма. Алар үстергән чеби, үрдәк бәбкәләре Үзәк регионга, Себер, Урал төбәкләренә кадәр китә.

Бүген инде Хановларның бөтен гаиләсе – кызлар, кияүләр, оныклар – шушы эштә. Утыз ел эчендә чеби, бәбкә үстерүнең бар нечкәлекләрен өйрәнеп бетергәннәр. Ә иң кызыгы – бу гаилә «ура, суга, җилгәрә, үзе төяп җибәрә», ник дигәндә, мал табибы да, икътисадчылар да – барысы да үзләрендә.

– Без – өч бала, – дип сөйләде Хановларның олы кызлары Айгөл ханым. – Белгечлекләребез төрле булса да, бүген барыбыз да шушы эштә. Әти-әнинең 9 оныгы бар. Аларга һөнәр сайлаганда җиңелрәк булды: кем булырга икән дигән сорауга җавап әзер иде. Барыбыз бергә чеби, биби үстерәбез. Үстерү генә түгел, аны урнаштырырга да кирәк. Заман алга барган саен бизнеска да яңалыклар кирә. Без дә ел саен яңа токымнарны өйрәнәбез, халыкка нәрсә кирәк икәнен барлыйбыз, белешәбез. Кыскасы, камиллекнең чиге юк. Утыз ел бу өлкәдә эшләсәк тә, һаман да – өйрәнүдә, эзләнүдә…

…Авыл җирендә эш юк, дип зарланабыз. Әнә бит, Хановлар тапкан. Алар республика икътисадын да күтәрә, гаилә икътисадын да ныгыта…

НОЯБРЬ

ДМИТРИЙ МЕДВЕДЕВ, РФ ХӨКҮМӘТЕ РӘИСЕ

Ноябрьдә Россия Премьер-министры Дмитрий Медведев Европа – Көнбатыш Кытай халыкара транспорт коридорының бер өлеше булачак – түләүле «Мәскәү – Казан» зур тизлекле автоюлын төзүне хуплауга нокта куйды.

Илебез юл челтәренең үсеше өчен гаять әһәмиятле проект тирәсендә интрига берничә ай дәвам итте. Җәмәгатьчелеккә әлеге юлның барлык уңай яклары җиткерелгәннән соң, РФ икътисадый үсеш министры Максим Орешкинга Мәскәүдән Тольяттига «Волга» М-7 юлы буйлап барырга туры килде. Күрәсең, әлеге сәфәр нәтиҗәләре буенча һәм үз тәэсирләренә таянып министр беренче чиратта М-7 юлын реконструкцияләргә кирәк, дигән карарга килә. Үз чиратында РФ Транспорт министрлыгында булганны модернизацияләүгә караганда, түләүле «Мәскәү – Казан» юлын төзү максатка ярашлырак, дип раслауларын дәвам итәләр.

РФ Премьер-министрының карары бу мәсьәләгә ачыклык кертүгә һәм аек акылның җиңүенә үрнәк булып тора ала. Яңа «Мәскәү – Казан» зур тизлекле трассасы төзелеше берничә этапка бүленәчәк һәм ике төп участоктан башланачак. Бу Владимирны, шулай ук Казанны көньяктан урап узарга тиешле Мәскәүдән Владивостокка кадәр сузылган маршрут. «Бу (этапларга бүлү – ред. иск.) безнең икенче бер мөһим бурычны – гамәлдәге «Волга» М-7 трассасын норматив халәткә китерү, яисә аның ике полосалы урыннарын, ким дигәндә, өч полосага кадәр киңәйтүне хәл итү өчен ресурслар табарга тиешлегебезгә бәйле», – дип хәбәр итте РФ вице-премьеры Максим Акимов.

Күргәнебезчә, хөкүмәттә бер проектны гамәлгә ашыру бәрабәренә икенче проектка зыян салу юлыннан китмәделәр. Һәм яңа зур тизлекле магистраль, искесен реконструкцияләү – илнең алга таба үсеше өчен таләп ителгән, якын киләчәктә хәл ителергә тиешле бурычлар.

Түләүле «Мәскәү –Казан» трассасы төзелеше 2020 елда башланырга тиеш. Трассаның 145 километрга сузылган, башкаладан Владимирга илтүче һәм көньяктан Казанны (Канаштан Татарстанга, Шәле – Саескан Тавы трассасы киселешенә кадәр) урап узарга тиешле зур тизлекле өлешен 2024 елга төгәлләргә планлаштыралар. «Өченче этапка 2021 елда старт биреләчәк, ул Владимирдан Арзамаска кадәрге араны били, без эшне 2025 елга тәмамларга уйлыйбыз. 2022 елда без әлеге участокларны – Арзамастан Канашка кадәр – бергә тоташтырачакбыз», – дип аңлатты Максим Акимов. Юлны тулысынча 2027 елга төзеп бетерергә тиешләр.

«Мәскәү – Казан» магистрален салу турында вакытлы һәм уйлап кабул ителгән карар – яхшы гамәл. Бигрәк тә икенче бер – киләчәге томанлы булган, бу юлы инде тимер юлга кагылышлы «Казан – Мәскәү» югары тизлекле магистраль мега проекты белән чагыштырганда. Әлегә бу проект буенча эшләр куандырмый – төрле тәкъдимнәрдән һәм барысын да яхшылап санарга кирәк дигән яңгыравык белдерүләрдән ары киткән юк. Бу бөтен дөньяда зур тизлекле магистральләр челтәре бик зур үсеш ала барган мәлдә. Ә чит илләрдә саный беләләр.



ДЕКАБРЬ

ИНЕССА КЛЮКИНА,
ЕЛ ВОЛОНТЁРЫ

5 декабрьдә Сочида үткән Халыкара ирекле волонтёрлар форумында Инесса «Э-моция» иҗади инклюзив студиясе» проектын тормышка ашырган өчен «Ел волонтёры» номинациясендә Бөтенроссия «Доброволец России» конкурсы бүләген алды. Җиңүчегә премияне илебез Президенты Владимир Путин тапшырды.

Ул кечкенәдән үк аркасына зыян килү сәбәпле йөри алмаган, ләкин беркайчан да яшьтәшләре белән аралаша алмау проблемасын тоймаган. Берничә операциядән соң аңа аягына басу насыйп булган. 2014 елның көзендә, аппаратны салып берничә ай узуга ук, ул инде Татарстанда инвалид хатын-кызлар арасында үтә торган «Татарстан энҗесе» республика гүзәллек конкурсында катнаша. Һәм «Мисс максатчанлык» дәрәҗәсенә лаек табыла:

– Бу титулның миңа тапшырылуыннан канәгатьлек кичермәдем. Күпләр киресенчә уйлагандыр, тик ул чакта миндә шактый күп шәхси сораулар туды. Әлбәттә, минем «Мисс нәзакәтлелек» яки башка шундыйрак исем аласым килгән иде. Әмма мин хәзер аңлыйм: кешеләрне алдап булмый, алар барысын да тоя. Нәзакәтлелек юклыкны түгел, бәлки максатчанлыкның күп булуын, – дип көлә Инесса.

Максатчанлык – нәкъ менә шул сыйфаты аңа җиңәргә ярдәм итә дә. «Татарстан энҗесе» конкурсында катнашканнан соң, балигълык яшендәге инвалидлар өчен иҗади студияләр булмавын белеп ала һәм театр оештырсаң яхшы булыр иде, дип уйлый. Шулай итеп «Э-моция» иҗади инклюзив студиясе» проекты барлыкка килә:

– Бу – ирекле проект. Безгә кушылырга теләүчеләр өчен ике генә кагыйдә бар: 18 яшьтән өлкәнрәк булу һәм яхшы эшли торган интеллект. Синең инвалидлыгың бармы-юкмы – анысы артык мөһим түгел, – ди Инесса. – Без командабызга волонтёрлар сыйфатында керәчәк кешеләр белән дә аралашырга, хезмәттәшлек итәргә әзер… Минем өчен театр – үземне танып белү һәм дөньяга ачылу. Спектакльләрдә уйнаганда, без үз хисләребезне ваемлыйбыз, аларны күрсәтергә, төрле булырга өйрәнәбез, үзебезне һәрьяклап ачабыз. Дусларыбыз, фикердәшләребез һәм ярдәмчеләребез күп булуына шатланам. Әмма иң мөһиме – коллективтагы һәр кешенең шәхси күтәрелеше һәм «Э-моция»нең гаҗәеп үсеше. «Яшәргә һәм шатланырга» ирешү өчен нибары ике нәрсә кирәк: беренчедән, яшәргә, икенчедән, шатланырга.

Максанс Фермин романы буенча куелган күз камаштырырлык «Кар» («Снег») тамашасында инвалидлыгы булган һәм булмаган актёрлар уйный, әмма тамашачы сәхнәдә инвалид арбаларын да, култык таякларын да күрми. Иҗат – хыял киңлеге, анда мөмкин булмаган берни дә юк. Камералы атмосферада куелган спектакль-медитация «актёр-тамашачы» чиген юа. Япониянең тылсымлы дөньясын, музыка, декорацияләр һәм актерларның хәрәкәтләрен күзәтеп ләззәтләнү. Яшь герой Юко Акитаның табигать һәм үз-үзе белән салмак әңгәмәсе. Актёрларның үз тән-җәсәдләре белән әңгәмәсе… Дүрт ел дәвамында «Кар»ны һәм студиянең башка спектакльләрен Россия шәһәрләрендә 6 меңнән артык тамашачы караган.

Быел «Доброволец России» конкурсына 28 меңнән артык гариза бирелгән булган. Үзенең анда җиңүе турында Инесса тыйнак кына: «Бу – студиянең җиңүе, аннан башка мин үземне күз алдыма да китерә алмыйм», – ди. Хәзер аның планнарында – инклюзив студияне тагын да үстерү, ул аны халыкара дәрәҗәгә чыгарырга, спектакльләрне чит илләрдә дә күрсәтергә хыяллана. Т

«ТЕЛӘЧЕ» СӘНӘГАТЬ ПАРКЫ – БЕРЕНЧЕ КАРЛЫГАЧ

– Клиентлар табу, эшне җайлап җибәрү берәүгә дә рәхәт түгел, тик тәвәккәлләсәң, була икән, – диде Альберт Кәримов.

Кече һәм урта эшмәкәрлек өчен шактый программалар бар. Шундыйларның берсе – сәнәгать мәйданчыкларын төзү. Россия территориясендә ул 2012 елда старт алды. Әлеге программадан Татарстан да читтә калмады. Теләче – республикада үрнәк күрсәткән беренче район.

Автор:
Руфия Фазылова

«ҮЗЕБЕЗ ДӘ ЫШАНМАДЫК!»

Татарстанда сәнәгать мәйданнары шактый. Бу «Алабуга» махсус икътисадый зонасы, алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре, технопарклар, «Химград» технополисы, «Мастер» Кама индустриаль паркы һ.б. Беренчедән, «Теләче» сәнәгать паркы гап-гади авыл хуҗалыгы районында эшли башлады. Икенчедән, алда санап киткән оешмалар – зур, көчле инвесторлар өчен, ә «Теләче» сәнәгать паркы яңа эш башлаучыларны күздә тота. Әлегә анда җиде эшмәкәр үз эшен башлаган. Араларында шактый эре оешмалар да бар.

Паркның оешу тарихына килгәндә, юл башы 2012 елга барып тоташа. Ул вакытта район башлыгы булып эшләүче Илдус Зарипов яңа чыккан программага кушылып, Теләчедә сәнәгать паркын булдырырга кирәк, дигән фикергә килә. Бу тәкъдимне республика җитәкчелеге дә хуплый. Чыннан да яхшы форсат: Теләче Казанга якын, яшь, үсеп килүче район. Тиз арада 34 гектар чәчүлек җирен «сәнәгать билгеләнешендәге» категориягә әйләндереп, сәнәгать паркы төзиләр. Шул ук елны биредә Марат Вәлиәхмәтов эш башларга теләк белдерә. Тәвәккәл эшмәкәр, ике ай дигәндә ябык гараж салып, махсус техника кайтарта. Һәм кулланылган резин шиннарны ваклап, спорт мәйданчыклары ясау өчен чимал ясау эшенә керешә.

– Беренче елларны җиңел булмады, әлбәттә, – дип сөйләде Марат Вәлиәхмәтовның уң кулы Альберт Кәримов. – Клиентлар табу, эшне җайлап җибәрү берәүгә дә рәхәт түгел, тик тәвәккәлләсәң, була икән. 2012 елның җәендә бирегә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин килгән иде. «Станокларны кайчан җибәрергә уйлыйсыз?» – дип сорады җитәкче. Кемдер шулвакыт: «1 сентябрьгә», – диде. Мин ул чагында елмаеп та куйган идем, янәсе, ике ай эчендә ничек өлгерәсең, ди? Ә бит вәгъдә үтәлде – 1 сентябрьдә эшне башладык.

Биредә эш тәртибен аңлау өчен, махсус белем кирәкми: бер станок зур шиннарны кисәкләргә бүлә, икенчесе шул кисәкләрне ваклап, кап-кара гранулалар ясый. (Без аны иснәп тә, тотып та карадык: вак резина кисәкчәләре сыман). Аннан шул гранулаларны капчыкларга тутырып, спорт мәйданчыкларына җәю өчен кулланалар. Резина вакларын җилем, махсус сыеклык белән кушып болгатылар да җәяләр, спорт мәйданчыгы өчен әслек әзер!

– Эшсез тормыйбыз, – диде Альберт Кәримов. – Дәүләт заказлары да була, чөнки күп кенә районнарда, шәһәрләребез ишегалларында спорт мәйданчыклары төзелә,шулай ук аерым оешмалар да мөрәҗәгать итә. Миңа калса, алга таба да шулай булачак.

Ә кулланылган шиннарны сәнәгать паркына ук китереп бирәләр икән. Кемнәрме? Техникасы булган зур оешмалар, шиномонтаж тотучылар. Яңа закон буенча, кулланылган шиннарны утилләштерү турында документ булырга тиеш. Марат Вәлиәхмәтов оешмасы нәкъ шундый документны бирә. Мәгълүм әйтемдәге кебек: «Бүре дә тук, сарык та исән».

– Без гаиләбез белән Казаннан күченеп килдек. Теләче кешеләренә әйләндек инде, – ди үзәкнең җитәкчесе Госман Кәбиров.

«ТЫЛСЫМ»

Пластмассадан төрле савытлар, көнкүреш кирәк-яраклары ясаучы оешмасы да эшли биредә. Берничә кисмәккә тутырылган гранулаларга химик сыеклык кушалар һәм формаларга агызалар, алга таба бизәкле, төсле савытлар барлыкка килә. Алар бер-бер артлы конвейердан төшеп тора. Бу бит гади бер авыл районында!

Пластмассадан көнкүреш кирәк-яраклары ясаучы бу үзәк «Теләче» сәнәгать паркының иң эре оешмасы. Биш ел эчендә үзләрен республикада гына түгел, Россия төбәкләрендә дә күрсәтә алганнар. Зур-зур сәүдә челтәрләре белән килешү төзегәннәр. Алар җитештергән савытларны күп җирдә күрергә була. (Сәүдә үзәкләренә кергәч, махсус карадым: киштәләрдә Теләчедә җитештерелгән савыт-сабалар күп икән бит!)

– Безнең оешманың инвесторлары – төрекләр, – диде үзәкнең җитәкчесе Госман Кәбиров. – Төрек вәкилләре үзләре дә монда яши, эшне оештыруда да катнаша. Паркта эшләүчеләр өчен махсус йортлар төзеделәр, аны аренда килешүе нигезендә бирәләр. Без дә гаиләбез белән Казаннан күченеп килдек, шундый йортларның берсендә яшибез. Безнең кебек кешеләр, гаиләләр

Азат Мортазин теплицасына кердек. Монда бөтенләй икенче дөнья – тавыш та, ис тә юк. Хуш исле гөлләр күзне иркәли…

шактый монда. Теләче кешеләренә әйләндек инде.

Әлеге оешма елына якынча 900 тонна пластмасса көнкүреш кирәк-ярагы җитештерә. Узган елда 1 миллиард 200 мең сумлык товар төяп-озатканнар. Быел сәүдә әйләнеше күрсәткечләре тагын да зуррак булыр, дип көтелә..

– 2014 елда, ягъни эшли башлаганда, җиде станок бар иде, – диде Госман Кәбиров. – Егерме кеше эшләде. Хәзер безнең 43 станогыбыз бар, 240 кеше хезмәт куя. Биш ел эчендә менә шундый нәтиҗәләргә ирештек. Алга таба шушы тизлекне киметмәскә исәп.

Эшчеләр Теләченең үзеннән, якын-тирә авыллардан килеп эшли. Мигрантлар да бар – җитмешләп таҗик милләте вәкилен дә эшкә алып килгәннәр. «Барысын да рәсми рәвештә эшкә алдык», – диде җитәкче.

Биредә ир-атлар да, хатын-кызлар да хезмәт куя. Зур-зур станокларны ирләргә кыюлыклары җиткән. Нигездә, хатын-кызлар физик көч таләп ителмәгән җирдә эшли. Мисал өчен, савытларга тоткычлар киертәләр, махсус кәгазьләр ябыштыралар…

– Биредә өч ел эшлим инде, – диде Әлфия Сөнгатова. – Бәби ялына да моннан киттем. Югары белемем бар минем, КХТИ тәмамладым. Әмма белгечлегем буенча эш таба алмадым. Шуңа да бирегә эшкә килдем.

– Хатын-кызлар өчен ниндидер өстенлекләр юкмы соң? – дим.

– Өстенлек дип… Йөкле хатын-кызлар төнге сменага чыкмый. Бездә эш өч сменада бара, станоклар туктап тормый бит.

Хезмәт хаклары белән дә кызыксындым – егерме мең тирәсе икән.

ГҮЗӘЛЛЕК ИЛЕНДӘ

Пластмассадан көнкүреш кирәк-яраклары ясаучы ангардан чыккан соң, Азат Мортазин теплицасына кердек. Монда бөтенләй икенче дөнья – тавыш та, ис тә юк. Хуш исле гөлләр күзне иркәли… Үзем дә сизмәстән:

– Бу парктагы иң рәхәт, иң җанлы урын ахры, – дидем.

Азат Мортазин канәгать кенә елмаеп куйды:

– Килгән бөтен кеше шулай ди. Бигрәк тә хатын-кызлар…

– Матурлык үстерү белән күптәннән шөгыльләнәсезме? – дим.

– Бу сәнәгать паркында 2016 елда эшне башладык. Ә аңа кадәр Казанда шундый зур булмаган эшем бар иде. Мин күбрәк бүлмә гөлләре үстерү белән шөгыльләнәм. Чәчәкләргә караганда аларны сату, урнаштыру җайлырак. Бүлмә гөлләре сатылмаса айлар буе тора, ә чәчәкләр атна-ун көндә шиңә…

– Ә нишләп Казанда гына теплица тотмыйсыз? Тәҗрибәгез дә бар икән бит, – дип төпченәм.

– Биредә эшләү күпкә җиңелрәк, – диде эшмәкәр. – Әзер инфраструктурадан тыш, биредә эшкуарларга бизнес алып бару өчен отышлы шартлар тәкъдим итәләр. Мисал өчен инженерлык коммуникацияләренә тоташу бушлай. Резидентлар җиде елга җир салымыннан һәм аренда түләвеннән азат ителә. Электр энергиясе дә ташламалы тариф буенча бирелә…

Азат Мортазин дәүләт программаларында катнашмаган, ягъни эш башлар өчен грант алмаган. Шәхси эшкуар булып теркәлгән. Хәзер инде барысы да җайланган дисәк тә була. Зур сәүдә үзәкләре белән элемтә булдырылган, күпләп сатып алучы тагын берничә оешма белән килешүе бар.

Азат гаиләсе белән Казанда яши, эш урынына көн саен диярлек килеп йөри икән. Кул астында эшләүчеләр берничә генә. Нигездә бөтен нәрсәне үзе контрольдә тота – гөлләргә ашлама сибүдән башлап, әзер чүлмәкләрне сатуга кадәр…

– Бу эш миңа бик ошый, – диде ул. – Махсус белемем булмаса да, яратсаң, чүлмәк гөлләрен күпләп үстереп була икән. Интернет бар бит хәзер. Буш вакытым булган саен эзләнәм. Шуңа күрә үзем бакчачы да, кибетче дә, хисапчы да…

«Теләче» сәнәгать паркында бүген менә шулай эшләп яталар. Планнар зурдан – башка эшмәкәрләрне дә бирегә җәлеп итү. Инде киләсе елга ук тагын ике эшмәкәр үз эшен башларга йөри икән. Быел гына паркның инфраструктурасын яхшырту өчен 53 млн сум тотканнар. (43 млн сум – РФ бюджетыннан, 10 млн сум – республика казнасыннан.) Газы, уты, суы, юлы кергән заманча шундый комплекс ул. Башка районнарга үрнәк булырлык, дип тә өстәргә кирәктер. ▪

Журнал
ТАТАРСТАН
Редакционная Кухня
ТАТАРСТАН

ЯҢА ЕЛ ТАБЫНЫНА – «БЕЗ» САЛАТЫ

Яңа ел җитәргә санаулы сәгатьләр генә калып бара. Инде бүләкләр хәстәрләп өлгергәнсездер, шәт. Хәзер иң мөһиме – Яңа ел табынын әзерләү. Без, хатын-кызлар, моңа аеруча җитди якын килəбез: ризыкны үзенчәлекле дә, җиңел дә итәсебез килә. Яңа ел алдыннан «Татарстан» редакциясе телевидениесе алып баручысы, мөхәррир Айгөл Нәбиуллинада кунакта булдык. Шигъри җанлы ханым белән «Без» салаты ясадык.

«ҮЗГӘРТЕРГӘ КИРӘК...»

Айгөл тормыш иптәше Илдар, улы Альфред, кызы Әминә белән Казанның Самосырово бистәсендә үз йортлары белән яши. Ә, тагын бер гаилә әгъзасын онытып торам икән – «Шустрик» кушаматлы песи. Ризык әзерләгәндә ул безне шулкадәр игътибар белән күзәтте ки, әйтерсең, сөйләшкәннәрнең барысын да ишетеп кенә түгел, ә аңлап та торды.

Хуҗабикә белән сүзне балачак турында сөйләшүдән башладык. Ни өчен дигәндә, Яңа ел диюгә, иң беренче балачак белән бәйле хатирәләр күз алдына килеп баса.

– Без гаиләдә дүрт бала үстек, – диде Айгөл. – Апам, игезәк энеләрем бар. Балачакта Яңа ел иң матур, иң әкияти бәйрәм бит ул. Башта чыршы бизәүне көтә башлыйсың, аннан – бүләкләр... Бүләк дигәч тә, ул әллә нинди затлы уенчыклар да түгел инде. Безнең заманның Яңа ел бүләге тәм-томнар иде. Конфет, пакетка бер-ике мандарин салынган булыр. Ул заманда алар көн дә ашала торган ризык түгел бит. Һәм берничә көнгә сузылган чыршы бәйрәмнәре... Эй, ничек күңелле була торган иде! Башта аны мәктәптә, укучылар өчен спортзалда оештыралар. 31 декабрь көнне авыл клубында бал-маскарад була. Әле концерттан соң лотерея уйнала. Клуб тулы кеше! Шуннан өйгә төшеп тәмле әйберләр ашыйбыз да йокларга ятабыз. Тик нишләптер уникегә кадәр калганны бик хәтерләмим.

Ул арада хуҗабикә салатка кирәк булган әйберләрне юып, корытты. Аннан яшел яфракларны тәлинкәгә җәйде.

– Үзегезне уңган хуҗабикә дип саныйсызмы? – дип сорап куйдым.

– Уңган, дип. Чисталыкны яратам. Өемдә гел тәртип. Ә менә ризык пешерүгә килгәндә... Без бүген бик тиз режимда яшибез, һич кенә дә вакыт юк. Шуңа күрә тиз әзерләнә торган ризыкларга өстенлек бирәм. Сатып кына алган чаклар да була. Вакытка карап инде. Әлбәттә, хәзер гаиләбез зур, ризык әзерләми калып булмый.

Хуҗабикәнең «гаилә зур» диюе кайбер укучыларыбызга аңлашылып та бетмәскә мөмкин. Шуңа

Автор:
Руфия Фазылова

АЙГӨЛ НӘБИУЛЛИНАДАН САЛАТ РЕЦЕПТЫ:

Кирәк булачак:
1. Йомырка – 2 данә
2. Тавык ите – 400 г
3. Бер бәйләм салат
4. Виноград – 200 г
5. Сыр – 300 г
6. Әстерхан чикләвеге – 200 г
7. Тәменчә тоз

Фото: Лилиана Вәлитова

Редакция кухнясы

1. Тезәбез!

2. Салабыз!

3. Уабыз!

4. Таратабыз!

5. Сылыйбыз!

6. Уабыз!

7. Салабыз!

8. Ваклыйбыз!

9. Сибәбез!

10. Бүләбез!

11. Тигезлибез!

12. Тезәбез!

13. Бизибез!

14. Табынга чыгарабыз!

күрә Айгөл Нәбиуллинаның кайбер серләрен ачыйк.

– Кияүгә иртә чыктым мин, – дип сөйләп китте Айгөл. – Казан дәүләт мәдәният институтының театр факультеты, актерлык осталыгы бүлегендә ике ел укыгач, кияүгә чыктым. Әмма тормыш сынаулардан тора бит, ике ел да яшәмәдек, ирем гүр иясе булды. Кечкенә улым Альфред белән акчасыз, торaксыз, икәү генә торып калдык… Авылга кайтып, сыер да саудым. Тик тормышымда нәрсәнедер үзгәртергә кирәк дигән уй мине туган авылымнан янә читкә алып китте. Башта Арча мәдәният йортында эшләдем. Аннары «Казан» милли-мәдәният үзәгенә чакырдылар. Менә шулай итеп сәнгать, җырлар, җырчылар дөньясына кереп киттем. Соңгы елларда Казан шәһәр филармониясендә директор вазыйфасын башкардым.

«СӘЛАМӘТ ЯШӘҮ РЕЖИМЫН САКЛЫЙМ»

Сүздән аерылмый гына салат ясауны дәвам иттек. Хуҗабикә пешкән тавык итен салат яфраклары өстенә бүлгәләп салды. (Кисәсе түгел, нәкъ менә җепселләр буенча аерырга.) Аннан сыр уарга керешге.

– Тавык итенең ак өлеше кирәк, – диде Айгөл. – Мин аны тозлы шулпада пешереп алдым. Бу салат җиңел була, шуңа күрә тавыкны кыздырырга яки ысланганын алырга киңәш итмим.

Шуннан хуҗабикә тавык ите өстенә уылган сыр җәйде.

– Арасына майонез салып тормыйм, алай итсәң, майлы була, – диде. – Ә менә сырдан соң аз гына майонез сылана. Катлы салат ясаганда белеп эшләргә кирәк: ризыкларны, берсе өстенә берсен салганда, кашык белән тигезлисе түгел. Кул белән таратып чыгу да җитә.

Айгөл сәламәт яшәү рәвеше яклы, үзе дә бу кагыйдәләрне сакларга тырыша. Даими рәвештә спортзалга йөри, бассейнда йөзә. Ашауны да контрольдә тота – майлы, камыр ризыклары ашамый. Шул исәптән – майонезны да.

– Авырлыгымны гел контрольдә тотам, – диде ул. – Элек үземне алай карамый идем, берничә ел инде шулай яшим. Организмда бер җиңеллек, рәхәтлек тоям.

Айгөл сыр өстенә уылган йомыркаларны таратты. Аннан соң әстерхан чикләвеген ваклап сипте. Шуннан ике-өч кашык майонез салып, салатның өстен тигезләде.

– Төп эш бетте дә, – диде ул. – Хәзер виноградларны урталайга кисеп, салат өстенә куеп чыгабыз да, салатыбыз әзер була. Менә монысы иң озак вакытны алачак.

«Бу салатны балалар белән бергә әзерләү күңелле икән. Виноградны рәхәтләнеп тезсеннәр», – диештек үзара.

Хуҗабикә виноградларны кисә торган арада, әңгәмәбезне дәвам иттек.

– Яңа ел бәйрәме сезнең гаиләдә ничек уза? – дип сорыймАйгөлдән.

– Күбрәк өйдә, йә булмаса дусларга барабыз. Яңа ел каршыларга башка шәһәрләргә, чит илләргә чыгып киткәнебез юк. Һәм кирәк дип тә санамыйм. Өйдә, чыршы янында, иң якыннарың белән бергә, менә шулай үзең әзерләгән ризыклар белән сыйланудан да рәхәте юк, минемчә.

Хуҗабикәнең «озак» дигәне әллә ни күп булмады. Биш минут дигәндә, виноградларны яртыга бүлеп, тезеп тә чыкты. Ризык әзерләргә барлыгы егерме минут тирәсе вакыт киткәндер.

– Хәзер тәмле чәй эчәрбез. Ирем Илдар командировкадан төрле-төрле чәйләр җыеп кайткан иде. Ә салатыбыз азрак суыткычта торып торсын, алай тәмлерәк була, – диде хуҗабикә.

«МӘЙДАН»НАН КИТҮ…

Айгөл Нәбиуллина исеме җырчылар даирәсенә яхшы таныш. Үзе әйткәнчә, дистә елга якын Казан шәһәр филармониясе директоры вазыйфасын башкарды бит ул. Ә гади халыкка күбрәк «Мәйдан» каналы аша танылды. Алып баручы үзе бу турыда болай сөйләде:

– Филармониядә эшләп бик арыган идем. Ялсыз эшләгән чаклар да күп булды. Бүтән эш булса, ике дә уйламыйча, күчәр идем дип йөргән көннәрем… Шул чорда Казан дәүләт мәдәният институтында бергә укыган сабакташларым – Дамир Дәүләтшин белән Эдуард Үтәгәнов шалтыратты. «Татар музыкаль каналы ачарга ниятлибез. Безнең командага кушыласыңмы?» – диләр. Ике дә уйламыйча ризалаштым. Әле нәрсә булып бетәр, планнар чынга ашармы, белгән юк. Ә мин ризалаштым. Күрәсең, эчке бер тоемлау белән барысы да әйбәт буласын аңлаганмындыр. Беренче тапкыр 2011 елның 17 августында эфирга чыктык.

Башта без бары тик цифрлы каналда гына эшләдек. Берничә айдан ныгыдык һәм кабель челтәренә күчтек. Башлангыч чорда исемебез «ТМТ», ягъни Татар музыкаль телеканалы дип кенә йөртелде. Аннан соң утырып уйлаштык та, «Мәйдан» дигән исемгә тукталдык. Бөтен халыкларга да аңлаешлы бер генә тел бар, ул – музыка, сәнгать теле. Сәнгать яратучы, Сабан туйларында җыелып аралашучы, гөрләтеп бәйрәм итүче татарның үз мәйданы булырга тиеш, дип исәпләп, беренче татар музыкаль телеканалын «Мәйдан» дип атадык. Музыкаль канал дип аталса да, анда мультфильм, кинофильмнар да күрсәтелде, юмористик тапшырулар да барлыкка килде. Иң авыры – архив туплау булды. Сез яңа канал дип, безгә берәү дә ярдәм кулы сузмады. Рәхмәт «Оскар-Рекордс» компаниясенә, үзләренең бөтен булган видеоязмаларын безгә бирделәр. Җыя торгач, барлыгы 500ләп видеоязмабыз тупланды.

– Ә ни өчен «Мәйдан» каналыннан киттегез?

– Хуҗалар алышынды, дөресрәге каналның акцияләрен икенче кешеләр сатып алды. «Мәйдан» каналы хәзер – «Татарстан – Яңа гасыр»ның бер тармагы.

– Яңа җитәкчелек сезгә башкача эшләргә куштымы?

– Кушарга өлгермәде, мин китеп өлгердем. «Мәйдан» каналының баш мөхәррире буларак, күп тапшыруларны үзем эшли идем. Башта бик борчылган идем. Хәзер исә тынычланып киләм, чөнки яңа «балабыз» – «Без» каналы туды. Тормышымның бер сәхифәсен ябып, икенчесен – яңасын ачтым.

«БУШКА ЭШЛИБЕЗ»

Бәлки әле күпләр белмидер дә, агымдагы елның ноябрь аеннан «Без» каналы эшли башлады. Нигездә ул музыкаль канал, «Мәйдан», «TMTV» форматында. Ләкин яңа каналга үзенчәлекләр дә керткәннәр. Беренчедән, «Без» рус телендә дә сөйли торган канал булачак. Дөрес, күп түгел, әмма булачак.

– «Без» каналында җырлар, клиплардан тыш спортка, әдәбиятка зур урын биреләчәк, – диде Айгөл. – Белгәнебезчә, спорт матчлары рус телендә бара, аны тәрҗемә итеп күрсәтергә безнең мөмкинлекләр юк. Ничек бар, шулай бирәбез. Шулай ук безнең Татарстанда яшәп, рус телендә җырлаучы күпме матур җырчыларыбыз бар. Ара-тирә аларның клипларын да кертәчәкбез. Рус кына түгел, төрки телләргә караган җырлар да булачак. Без бер-беребезне белергә, хөрмәт итәргә тиешбез.

– Әлбәттә, башта җиңел булмаячак, – диде Айгөл. – «Мәйдан»да да беренче ике елны җырчыларның җырларын бушка әйләндердек. Яшерен-батырын түгел, төп керем каналга шул җырлар аша килә. Реклама белән әллә ни акча эшләп булмый. Телеканал аякка бассын, халык арасында таралсын өчен, кимендә, биш ел таләп ителә. Ә без әле бушка эшлибез.

«Без» каналын бүген «Таттелеком» чыбыклы телевидениесе аша һәм интернет челтәреннән карап була.

– Дәүләт ярдәменнән башка телевизион канал ачуы авырмы? – дим Айгөлгә.

– Җиңел түгел. «Мәйдан» каналына лицензияне тиз алган идек, бу юлы бик озакка – берничә айга сузылды. Аяк чалучы юк болай үзе, шунысына рәхмәт. Хәер, республика җитәкчелеге яңа каналны хуплады. Бөтендөнья татар конгрессы белән дә элемтәдә торабыз. Без бит милләт өчен эшлибез. Әллә нинди зур акчаларга өметләнә дип уйлаучылар ялгышалар. Финанс ягыннан музыкаль телевидениене яшәтү бер дә җиңел түгел. Татар артистлары белән Россия шоу-бизнесы әһелләре арасындагы аерма җир белән күк арасы. Рус эстрадасы белән чагыштырганда, безнекеләрнең кереме йөзләрчә тапкыр кимрәк, шуңа күрә без алардан күп акчалар таләп итә алмыйбыз. Әнә, «МузТВ»да бер җырны әйләндерү дистәләрчә мең доллар белән исәпләнә. Татар шоу-бизнесында мондый акчалар юк, билгеле.

Иҗат турында сүз чыккач, Айгөл белән социаль челтәрләр турында да сөйләштек. Бүген бик күп эстрада вәкилләре блогерлык эше белән мавыга. Айгөл дә Инстаграм челтәрендә шактый актив эшли. Ундүрт меңнән артык язылучысы бар аның. Әлбәттә, блогерлар өчен бу әллә ни зур сан түгел, шулай да...

– Мин үземне чын блогер дип санамыйм, – диде Айгөл. – Инстаграм челтәрендә әле мин күптән түгел – бер еллап кына яшим. Күп итеп язылучыларым булсын дигән максатым бөтенләй булмады. «Мәйдан»нан киткәндә халык белән элемтәм югалмасын дип, социаль челтәрләрдә активлаштым. Хәзер үземә дә ошап китте. Тамашачы белән турыдан-туры элемтәдә тору өчен бу кирәк икән ул. Шундый нәтиҗәгә килдем әле.

...Айгөл чәй табыны әзерләде. Салатны матур итеп бүлеп алдыбызга куйды. Салат, чынлап та, туклыклы һәм җиңел. Миңа калса, Яңа ел табынына бер дигән булачак. Тагын бер серне чишим инде: салатка «Без» дигән исемне махсус уйлап таптык. Ни өчен дигәндә, беренчедән, аны бергә ясадык. Икенчедән, яңа каналның исеме дә шундый.

Саубуллашканда хуҗабикә журнал укучыларына Яңа ел теләкләрен җиткерде:

– Иң мөһиме – саулык. Алга максат куеп, бернигә дә карамыйча, шуңа барырга кирәк. Тормышта әллә нинди вакытлар була, уза ул. Үз мисалымнан чыгып әйтәм. Күгебез аяз, якыннарыбыз исән-сау булсын. Калганы булыр!

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

Реклама 16+

Безнең Инстаграмда – «Татарстан»ның йөрәге!

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Сәүдәгәр Даутов йорты **КАЙДА** урнашкан

Өяз табиблары **НИНДИ** булган

КАМАЗ тарихы **НИ ӨЧЕН** ил тарихына әверелде

Чистайны **КАЙЧАН** яңарыш көтә

Петр I Казанга **КАЙЧАН** килгән

Яшәлгән һәр көн тарихка әйләнә. Ул фотосурәтләрдә, хатларда, әйберләрдә, җырларда, китапларда, мәктәп көндәлекләрендә, документларда кала… Соңрак, үткәннәрдәге әйберләргә карап, без кайчандыр, әле агачлар бик биек булган чакта, кичергән хисләрне, тәсләрне, авазларны искә төшерәбез…

Татарстан Республикасы һәм аның адашы «Татарстан» журналының 100 ел яшәү дәверендә җөмһүриятебез халкында истәлекле әйберләр шактый тупланган. Гаилә тарихлары гаилә архивларында саклана, зур тарихны исә музейлар күз карасыдай саклый. Алар хәзер һаман саен күбрәк популярлаша һәм төрләнә, чөнки тамырларыбыз, бабаларыбыз, гореф-гадәтләребез белән кызыксыну сүнми, бәхеткә, арта бара.

Республикабыз кебек үк 1920 елда туган «Татарстан» журналы үзенең 100 яшьлек юбилеена музейлар марафоны үткәрергә – җөмһүриятебезнең гадәти булмаган 100 музеенда булырга карар кылды.

Бүген сезнең игътибарыгызга берничә музей тәкъдим итәбез.

1

иң
ЧЫН.
ОЛЫ ӘТНӘДӘГЕ СӘҮДӘГӘР ДАУТОВ ЙОРТЫ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА



2

иң
ШӘФКАТЬЛЕ.
БЕХТЕРЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ӨЯЗ МЕДИЦИНАСЫ МУЗЕЕ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА

3

иң
ГАЯРЬ.
КАМАЗ МУЗЕЕ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА

4

иң
ӨМЕТЛЕ.
ЧИСТАЙ МУЗЕЙ-ШӘҺӘРЕ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА

ИҢ ЧЫН.
ОЛЫ ӘТНӘДӘГЕ СӘҮДӘГӘР ДАУТОВ ЙОРТЫ

Олы Әтнәдәге Туган якны өйрәнү музее бик тарихи урында – сәүдәгәр Даутов йортында урнашкан. Килүчеләр өчен әлегә ябык булгангамы, музей бик чын булып тоела – аның һәр почмагыннан борынгылык рухы аңкый, үткәннәрне сагыну хисе бәгырьгә үтеп керә, тарих белән очрашу шатлыгы сөендерә... Бернинди интерактив суперяңалыклар, пластик витриналар, пыяла япкычлар, бернинди заманчалык һәм бизәү юк бирeдә – барысы да чын, барысы да кайчандыр әлеге әйберләр арасында яшәгән-эшләгән-иҗат иткән кешеләрнең кул җылысын саклый... һәм сәүдәгәр Даутов утарында урын алган әлеге әйберләрнең тарихы онытыла язган Әтнә вакыйгаларын хәтердә яңарту өчен хезмәт итә.

I НЧЕ ТАРИХ.
ХӘКИМ КИБЕТЕ

– Без йортның арткы яктагы ишегеннән керәбез, – дип башлый сәүдәгәр Гатаулла Даутов биләмәләре буйлап экскурсияне музей директоры Эльмира Гыйләҗева. – Беренче катта – «кара өй». Элек бирeдә келәт, чолан урнашкан булган, хәзер исә – базар. Атаклы Әтнә базары.

Киштәләргә товарлар тезелгән: матур бизәкле читекләр, балчык чүлмәкләр, керосин лампалары, чуар тукыма төргәкләре, бауга кигертелгән түгәрәк клиндерләр...

– Бирегә Казаннан, башка шәһәрләрдән сәүдәгәрләр килгән, – дип сөйләвен дәвам итә Эльмира Мәхмүт кызы. – Базар һәр шимбә саен гөрләгән һәм узган гасырның 70 нче елларына кадәр эшләгән. Үзенең Кырлайда Сәгъди абзыйда яшәгән чагын сурәтләгәндә, Габдулла Тукай да «Исемдә калганнар» әсәрендә: «Кайва-

Фото: Александр Гайнетдинов



кыт җәй көне әти белән Әтнә базарына бара идек. Ул үзенең хезмәтләре илә базар арасында йөргәндә, мин атны тотып тора идем», – дип язган. Бәләкәй Апуш базарга Комыргуҗа авылыннан килеп үзе пешергән икмәкне сатучы Хәкимнән бик тәмле ак күмәч сатып алып сыйлана торган булган.

Атаклы якташлары хакында әтнәләр сәгатьләр буе сөйли ала. Менә хәзер дә Эльмира Мәхмүт кызы Тукайның балачагы гына түгел, үсмер чагы да Әтнә белән бәйле булуын искә алды.

– Ул 1907 елда хәрби хезмәткә чакырылыр алдыннан медкомиссия үтәргә дә бирегә килгән. Волость идарәсе бинасы Олы Әтнәдә булган – хәрби хезмәткә чакырылучылар шунда тикшеренү узган. Шунлыктан бездә күп оешмалар Габдулла Тукай исемен йөртә. Ул чакта Әтнә районы булмаган әле, Кушлавыч авылы Олуы Мәңгәр волостена кергән, тик ул безнең территориядә урнашкан булган. Хәзер Кушлавыч Арча районына керә һәм арчалар да Тукайны үзләренеке саный. Әмма ул безнеке!

2 НЧЕ ТАРИХ.
ӘТНӘ МАМЫК ШӘЛЕ

«Икмәк пешерүче Хәкимгә» «Татарстан» журналының яңа санын бүләккә калдырып, «безнең төбәкнең һөнәрләре» хакында сөйли торган башка «залларга» күчәбез. Бер кечкенә генә чоланда әтнәләрнең әби-бабаларының ни белән шөгыльләнүе белән танышабыз. Ир-атлар чыпта суккан, чабата үргән, эшләпә ясаган, киез итек баскан...

– Кече Әтнә авылында итекләрне хәзер дә кулдан басалар, – дип аңлата экскурсовод. Аннары без «хатын-кызлар» ягына борылабыз. Туку, чигү, бәйләү... Күңелле бизәкләр күзне иркәли.

– Бездә хәзергә кадәр шәл бәйләү белән шөгыльләнүче оста куллар күп. Оренбургның мамык шәле турында ишеткәнегез бармы? Менә бездә дә шундый «оренбур» шәлләре инде! Хәтта алардан яхшырак та әле!

Келәтләрдән берсе базарны дәвам итә – анда элек һәр йортта булган күмерле үтүкләр, савытсаба, самавыр, сәгатьләр (алар монда тулы бер коллекция тәшкил итә), май атлагыч – гөбеләр куелган. Һәм Әтнәдәге һәр йорттан диярлек музейга әби-бабаларының нинди дә булса бер әйбере китерелгән.

3 НЧЕ ТАРИХ.
ТАТАР ЙОРТЫ СЕРЛӘРЕ

Киләсе «зал» бусагасында безне әтәч каршы ала. Чынга охшаган гайрәтле кошны сак кына урап узып, татар өенең эченә үтәбез. Каршыбыздагы сәке үзенә чакыра, ял итәргә ымсындыра.

– Һәр татар өендә сәке булган, – дип сөйли Эльмира Мәхмүт кызы. – Сәкедә утырганнар да, йоклаганнар да, чиккән-тепкәнбәйләгәннәр дә, чәй дә эчкәннәр, ашаганнар да... Йоклаганда, сәкене чаршау белән каплаганнар. Бик уңайлы урын булган ул. Өйдә өстәл булган очракта да, аның өстендә савыт-саба гына саклаганнар, табынны исә сәкедә корганнар. Мич исә өйдә үзәк урын биләгән. Татар мичендә һичшиксез казан булган – анда су да җылытканнар, ашарга да пешергәннәр. Мич янында – самавыр, күмер, табагач... Сөтне балчык чүлмәктә саклаганнар, ә шикәрне махсус шикәр ваткыч белән ваклаганнар.

Болары исә – балалар әйберләре: бишек һәм чыгыр.

4 НЧЕ ТАРИХ.
ИШЕГАЛДЫНДАГЫ БАЙЛЫК

Эльмира Мәхмүт кызы безне «ишегалды территориясенә» алып чыга һәм бик күп төрле кызыклы предметлар күрсәтә. Чаналар, арбалар, көянтәләр, кирпеч сугу җайланмасы...

– Сез моны нәрсә дип уйлыйсыз? – дип хәйләкәр елмаеп сорый ул, безгә урта гасырлардагы җәза бирү коралына охшаган әйберне күрсәтеп...

– Гильотина! – дип сөенеп бертавыштан җавап бирәбез без.

– Юк шул! – дип көлә экскурсия үткәрүчебез. – Бу – кул пычкысы тоткасы. Әлеге җайланма белән бүрәнәне такталарга ярганнар.

Без дә башта күз алдыбызга да китерә алмадык – ни рәвешле эшли соң бу пычкы? Җайланманы музейга бүләк итүче кеше аның ничек эшләвен аңлатты. Менә нинди баһадир булган Әтнә ирләре! Бүрәнәне буйга кул белән кисканнәр! Тигез итеп! Бернинди электр җиһазы да булмаган бит ул чакта, барысын да кулдан эшләргә туры килгән...

Әтнә крестьяннарының куәтенә һәм зирәклегенә таң калып, сәүдәгәр гаиләсе яшәгән икенче катка менәбез.

5 НЧЕ ТАРИХ.
СӘҮДӘГӘР ЯЗМЫШЫ

– Бу кат ирләр һәм хатын-кызлар ягына бүленгән, – дип ике юнәлешне күрсәтә экскурсия үткәрүчебез. – Ягылмый торган урта өлеше – өйалды.

Гатаулла Даутов ике тапкыр өйләнә. Беренче хатынынннан баласы булмый, шунлыктан икенчегә өйләнергә ниятли. Мәңгәрнең яшь гүзәле өчен сәүдәгәр 5 мең сум күләмендә калым түли. Ул заман өчен бу гаять зур сумма була, гади кешеләр калымга нибары 100–200 сум акча бүлә ала. Әмма Даутов Әтнәдәге дүрт миллионерның берсе була һәм шулкадәр калым бирү аның хәленнән килә. Утары ишегалдында ук аның үз кибете дә була (бина бик яхшы сакланган), анда ул бакалея һәм мануфактура белән сәүдә итә. Товар төягән ат олаулары хәтта күрше Шәкәнәс авылына кадәр сузыла...

Әмма, миллионнарына һәм зур калымына карамастан, икенче хатыны да сәүдәгәргә варис тудыра алмый.

Бу мәгълүмат уйланырга мәҗбүр итә. Бик бай һәм халык мәхәббәтен яулаган сәүдәгәрләрнең (Даутов исә нәкъ шундый – юмарт меценат һәм хәйрияче була. Кеременең бер өлешен һәрвакыт ярлыларга тарата. Аның ике коесы була, берсе ишегалдында, икенчесе – урамда, йорт каршында, һәм җирле халык шуннан су ташый) варисы булмау турында бу беренче генә хикәят түгел. Романтик мәхәббәт тарихын саклаган музей-йортлары Тәтеш районы Долгая Поляна авылында урнашкан морза Молоствовлар гаиләсендә дә бала тумый. Шәһәргә бушлай суүткәргеч, хастаханә корпусы, кызлар гимназиясе бүләк иткән Чистай сәүдәгәре Василий Львович Челышевның да варислары булмый... Ихтимал, тарих бу гаиләләрне булачак революциядән нәкъ менә шул рәвешле саклап калгандыр – әти-әниләренең игелекле эшләре күп булуга карамастан, «кызыл террор» сәүдәгәр һәм морза балаларын бер дә аямас иде...

– Аны кулакка чыгаралар. Атмакчы булалар, – дип дәвам итә Эльмира Мәхмүт кызы. – Әмма җирле халык моңа ирек куймый. Даутовны төрмәгә алып киткән булалар, әмма, мөгаен, юлда барганда ук атканнардыр. Аннары, юлда йөрәк өянәгеннән җан тәслим кылды, дип хәбәр итәләр... Аңа 64 яшь була. Крестьяннар Даутовның икенче хатынын, ирләр киеменә киендереп, төнлә атка утыртып алып китәләр, атылудан коткару өчен яшерәләр. Менә шундый рәхимсез язмыш. Хәзер без Гатаулла Даутовның шәҗәрәсен язабыз. Аның бит кыз туганы була, ул 16 бала таба. Без шулардан дүртесенең исемен һәм язмышын ачыкладык инде...

6 НЧЫ ТАРИХ.
КАЛА ТАВЫ

– Музейның икенче каты проектлаштыру стадиясендә, – дип, моңсу хатирәләрдән бүгенгә көнгә күчә Эльмира Мәхмүт кызы. – Бу – Кала тавы залы (төрки теленнән тәрҗемәдә «Ныгытма-тау», «Кала-тау»). Әтнә районындагы иң борынгы һәм изге урын – Әйшияз шәһәрлеге. Тауда ныгытма булган, галимнәр аның калдыкларын тапкан. Анда ханнар төрбәсе бар – сакланып калган өч кабер ташы X гасырга карый.

Хәзергә кадәр анда июньнең беренче җомгасында «Әләшә бәйрәме» үткәрелә. Халык Кала тавы итәгендә җыела һәм мәрхүмнәр рухына дога кыла. Бу – уникаль, борынгы бәйрәм, аны бары тик биредә генә уздыралар.

7 НЧЕ ТАРИХ.
ЛЕГЕНДАР МӘЧЕТЛӘР

Ислам дине залы Әтнә районы мәчетләренең катлаулы язмышы хакында сөйли. Түбән Бәрәскә авылында 1769 елгы беренче таш җәмигъ мәчете сакланып калган, хәзер анда реставрация эшләре бара. Ул Әби патша фәрманы буенча салына. Патшабикә Казанга килгәндә, Әтнә сәүдәгәре Ибраһим Борнаев та тантанада катнаша һәм мәчет салырга рөхсәт бирүен үтенә. Әлеге тантанада Мәңгәр һәм Казан сәүдәгәрләре дә була. Екатерина II таш мәчетләр салу турында указны имзалый. Шуннан соң Казанда 1771 елда Мәрҗани мәчете пәйда була. Әмма Ибраһим Борнаев мәчетне моннан да иртәрәк, 1769 елда ук төзергә өлгерә! Мәрҗанинең әтисе һәм бабасы әлеге мәчет каршындагы мәдрәсәдә укый.

– Шиһабетдин Мәрҗани дә тумышы белән Әтнә районыннан. Ул Япанчы авылында туган – былтыр аның тууына 200 ел тулуны билгеләп үттек. Барлык бөек шәхесләр дә – безнекеләр, әтнәләр! – дип һаман кабатлаудан туймый Эльмира Мәхмүт кызы һәм дәвам итә. – Түбән Көек авылында тагын бер уникаль мәчет бар – ул ике манаралы. Көек – «янган» дип тәрҗемә ителә. Шундый риваять бар – янәсе, бу авылда гел янгын чыккан. Авыл халкы, Аллаһ Тәгаләгә мөрәҗәгать итеп, янгын чыкмасын өчен үзләре нишләргә тиешлекне аңлатуын үтенгән. «Әгәр ике манаралы мәчет төзесәгез, янгыннар туктаячак», – дигән җавап ишеткәннәр. Әйткән сүз – аткан ук. Мәчет салына, янгын чыгу туктала. Әлеге мәчет хәзер дә эшли. Мокшы авылындагы гыйбадәтханә исә – 1930 нчы елларда манарасы киселми калган бердәнбер мәчет. Менә нинди легендар мәчетләр бар безнең Әтнә районында!

8 НЧЕ ТАРИХ.
АК ЯК АКСӨЯКЛӘРЕ

Ислам дине залыннан әкренләп башка залга – сәнгать хакында сөйли торганына күчәбез. Район күренекле язучылар, музыкантлар, артистларга бай. 2018 елда Әтнә театры йөз еллык юбилеен билгеләп үтте. Театр елын да нәкъ менә биредә ачтылар.

– Әтнә районын ак як дип йөртәләр, – ди Эльмира Мәхмүт кызы. – Бу төбәктә сәнгать һәм мәгърифәтчелекнең бик күп вәкиле туган. Камал театрында Бәрәскә авылында туган артистлар күп. Биредә Мәрҗани дөньяга килгән... Бу күп нәрсә турында сөйли. «Ак як» русчада «голубая кровь» мәгънәсен аңлата.

Музейда Дан залы да ачарга җыеналар, анда Гражданнар, Ватан, Чечен, Әфган сугышларында катнашучылар турында мәгълүмат тупланачак. Әмма әлегә аның урынында... гөлләр үсә, чөнки...

– Чөнки бинага кагылышлы проблемалар бар. Өрлек-матчалар, баскычларның барысын да ныгытырга һәм яңартырга кирәк. Бирегә туристларның зур төркемнәрен алып керү әлегә куркыныч, ишелү ихтималы бар... Совет чорында йорт коммуналь торак итеп файдаланылган. Берара биредә военкомат, соңрак тулай торак булган. Бу йортта ул чакта бик пөхтә һәм сакчыл кешеләр яшәмәгәнен үзегез дә аңлыйсыздыр. 1994 елда бинаны реставрацияләү башлыйлар, 2010 елда утар территориясен Әтнә туган якны өйрәнү музее фондларына тапшыралар.

9 НЧЫ ТАРИХ.
ЧЫН ТАРИХ

Шыгырдавык басмаларга сак кына басып, өченче катка менәбез.

– Бу – кызлар бүлмәсе. Гатаулла Даутов туганының кызын тәрбиягә алган. Ул биредә – иң якты һәм иң җылы бүлмәдә яшәгән, – дип экскурсияне дәвам итә музей директоры. – ТР Диния нәзарәте исә биредә «Мәрҗани» фильмын төшерде. Чөнки монда барысы да чын. Йорт үзе – һәйкәл. Нининдер экспонатлар куеп та тормыйча, йорт буйлап экскурсияләр үткәрергә була. тәфсилләп сөйләрлек хикәятләр хәттин ашкан. Татарстан территориясендә мондый агач йортлар бүтән юк. Биредә борынгылык рухы сизелә, коммуналка, военкомат, тулай торак дәверен кичерсә дә, әлеге рух барыбер сакланып калган... Казан арты территориясендә мондый архитектура традицион була, мондый йортлар күп салына. Әмма 1931 елда зур янгын чыгып, ярты Әтнә янып бетә. Сәүдәгәр Бакировның 1838 елда салынган йорты сакланган, ул Даутовныкыннан күпкә зуррак, әмма күпкә тузганрак та. XIX гасыр һәйкәле булган Вәли бай йортының агачтан салынган өске каты 2013 елда янгында харап булды, аскы таш өлеше генә сакланып калды. Тагын бер ядкарь – Әтнә үзәгендәге даруханә бинасының 1886 елда төзелгән бинасы – заманча сайдинг белән тышланган, аны хәзер тарихи һәйкәл дип әйтеп булмый инде.

Халык безнең музей ачылышын түземсезләнеп көтә. Һәм безгә халыкны җәлеп итү өчен бернинди интерактив уеннар да кирәкми. Минемчә, музейлардагы заманча әйберләрнең бер дә кызыгы юк. Безнең проектны эшли башлауга, мин шундук кисәттем: берүк пластик витриналар куя күрмәгез! Мондый йортка ничек итеп пластик витрина куясың инде?! Бу бит тарихны үтерү була. Бу инде тарих түгел, бәлки гаджетлар гына булачак, ә алар хәзер һәркемнең кулында, алар белән берәүне дә таң калдырып булмый. Әйе, мөгаен, интерактив табло ул җайлыдыр. Бармак белән генә төртәсең дә, якынайтып та, ерагайтып та карыйсың. Тик моның өчен музейга бару мәҗбүри түгел бит – өендә тик карап утыр. Әмма инде борынгылык белән гаҗәпләндерә, сихәтләндерә торган элемтә урнашмаячак. Без бу йортта чын Үткәннәргә чумабыз. Бу урынны һәм бу тойгыларны саклап каласы һәм киләчәк буыннарга да җиткерәсе килә.



Фото: Ната Смирнова, Әскәр Сабиров

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА

ИҢ ШӘФКАТЬЛЕ.

БЕХТЕРЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ӨЯЗ МЕДИЦИНАСЫ МУЗЕЕ

Фанер чемодан, зур киндер сумка, галошлар, кул таягы. Керосин фонаре, киез итек өчен каеш тагылган бик киң агач чаңгы... Ә хәзер күпбеләмнәр өчен сорау: XIX гасыр ахырында менә шундый джентльмен тупланмасына ия кеше нинди абруйлы һөнәр иясе булган?

Тимер юлларны күзәтеп торучымы? Хат ташучымы? Бәлки, урманчыдыр? Күңелегез төшмәсен, җаваплар дөрес түгел. Югарыда аталган нәрсәләр – земство табибыныкы. Алабуга өяз медицинасы музеендагы әлеге раритетларны карыйм. Аларны кайчандыр, китаплардан укып, күз алдыма китергән зат белән янәшә куярга тырышам. Зыялы йөз-кыяфәт, пенсне, итагатьле манералар һәм лаеклы хезмәт хакы – ул заман табибларын мин әнә шундый итеп күз алдына китерә идем. Ә монда – чаңгы, фонарь, сумка – хәтта сумка да түгел, ә ниндидер капчык кебек нәрсә...

Музейда хыял-фантазияләргә урын юк. Монда, әлбәттә, чын ядкарьләр җыелган. XIX гасыр ахырында (1881 ел) җирле сәүдәгәр Баранов акчасына төзелгән земство хастаханәсенең исән калган агач бинасы да чып-чын. Ә карболка исен мәңгегә сеңдереп калгандай тоелган диварлардагы күргәзмә – ата-бабаларыбызның әллә ни ерак булмаган заманнарда ничек һәм нәрсә белән дәвалавын белү өчен менә дигән форсат. Һәм бу форсаттан ничек файдаланмаска, ди?

Автор:
Әскәр Сабиров

ӨЧ АТ ҖИГЕЛГӘН ШӨЛДЕРЛЕ «АШЫГЫЧ ЯРДӘМ»

Мине шулай гаҗәпкә калдырган әйберләр – менә шушында, земство табибы кабинетында, хан заманындагы кулъюгыч янәшәсендә. Өяз картасы, дежур халат һәм яңгырга да, карга чыдам плащ-балахон янында. Ул вакыт өчен үзенә күрә ашыгыч медицина ярдәме җыелмасы. Чөнки табиб Алабуганың караңгы авылына, ашыгыч чакыру килсә, теләсә кайсы минутта чыгып китә алган.

– XX гасыр башына Алабуга өязендә 559 авыл булган, аларда 250 меңгә якын кеше яшәгән. Алабугалылар гына да тугыз меңгә якын, – дип сөйли экскурсовод. – Ә шәһәр хастаханәсе штатында нибары өч табиб һәм сигез урта медицина хезмәткәре исәпләнгән.

Экскурсовод кыз шул чордагы шәфкать туташы киемендә булганга күрә, бәлки, аның сөйләгәннәре шулай тәэсирледер дә. Димәк, земство табибы көннәрен һәм төннәрен йә хастаханәдә, йә юлда уздырган булып чыга. Почта ташу өчен бут ташы җәелгән Әби патша юлы булса яхшы да, ул юл буйлап авыру янына өч атлы, шөлдер тагылган җигемдә дә җилдереп барырга мөмкин. Ә караңгы төндә, кышын, кар салган сукмактан шайтан олаккан авылга ничек барып җитәргә?

Статистик мәгълүматлар сакланып калган. Үз участогы (земство медицинасының төп структур берәмлек) өчен җавап биргән табиб чакырулар буенча елына 200 тапкырдан артык юлга чыккан, сәфәре кайчагында берәр тәүлеккә сузылган.

Михаил Булгаковның «Яшь табиб язмалары»н хәтерлисезме? «Әгәр кешенең ат белән караңгы, балчык юллардан йөргәне юк икән, миңа бу хакта сөйләп торасы түгел, барыбер аңламаячак ул. Ә йөргән кешенең исенә дә төшерергә теләмим.

Кыскача гына әйтеп китәм: өяз шәһәре Грачевканы Мурьев-

ская хастаханәсеннән аерып торган кырык чакрым араны нәкъ бер тәүлек бара идек...»

Бу сүзләр Алабуга земство табибларына да туры килә.

ВАЛИДОЛ? ӘЛБӘТТӘ, АШКАЗАНЫ ӨЧЕН

Химикларның реторталарына охшаган киң йомры төпле шешәләр, дарулар әзерләү өчен фарфор саплы килеләр, әзер дарулар. Аларның берсендә «VALIDOL» дип язылган. Астарак исә бүгенге белем күзлегеннән карагандa сәер тоелачак аңлатма: «Ашказаны авыртуларына каршы». Соң бит рецепты да бүген генә бирелмәгән: «Земство даруханәсеннән, 1/10/1883 ел» диелгән...

Музей эчендә торгызылган земство даруханәсе, әлбәттә, бүгенге даруханәләрдән аерылып тора. Тарихта беренче автомобиль хәзерге «Формула-1» болидына охшамаган кебек. Хәер, борынгы бабаларыбыздан кайбер нәрсәләрне үзебезгә күчереп алсак та, начар булмас иде. Земство даруханәсендә (беренчесе шәһәрдә XIX гасырның 60 нчы елларында ук ачылган икән), мәсәлән, Алабуга өязе крестьяннары, земство хезмәткәрләре һәм каланың ярлы халкы даруларны бушлай алган. Үрнәк алыр өчен бер нигез түгелме?

Хастаханә бинасында земство даруханәсе 1896 елга кадәр эшли. Соңрак ул Шәһәр идарәсендә урын таба. Барысы да шактый иркен, саллы була: дүрт бүлмә, келәт, лаборатория, үләннәр бүлмәсе... Бар эшне биш ярдәмчесе һәм ике шәкерте булган провизор алып бара. Ә узган гасыр башында земство даруханәсенең көндәше барлыкка килә. Үзәк урам – Казан урамындагы ике катлы бинада Ватеркамф шәхси даруханәсе өр-яңа дарулар сата башлый. Тик анда, әлбәттә, берәү дә бушлай рецепт белән дарулар биреп җибәрми.

ҺӘР ЭШКӘ МАҺИР ДОКТОР

«Җаен бик авыр яшәдем, тик хәзер миңа бер җайне дә шулкадәр шәп уздырмаганмын кебек тоела. Көзгә кадәр аягымны бәйләп торткан акчасызлыкка, холера ыгы-зыгысына карамастан, миңа бик ошый һәм яшисе килә иде». Бу юллар – XIX гасырның, мөгаен, иң атаклы земство табибларыннан берсе булган Антон Чехов хатыннан.

Мәскәү янындагы Воскресенск яки Мелехов шәһәрендә хезмәт куйган доктор-әдипкә карагандa, Алабугада эшләгән земство табибларына күпкә кыенгарак туры килгән. Эпидемияләр белән көрәш, чәчәккә каршы укол кадаучыларны укыту, фельдшерлар укуларына җитәкчелек итү һәм аларның эшен күзәтү, хәтта ветеринария хезмәтенә булышлык күрсәтү – болар да земство табибларының турыдан-туры бурычлары исемлегенә кергән. Һәм әле бит көн саен авырулар кабул итү, операцияләр, хасталарның хәлен белешү, ашыгыч чакыруларга йөрүләр бар...

Табибларның Чехов кебек үз акчаларына дәвалау пунктларын ачу мөмкинлеге булмаган, шулай да иганәчеләр кулдан килгәнчә ярдәм иткән. Алабугадагы беренче чын мәгънәсендәге хастаханә дә (ярты гасыр элегрәк ачылганының исеме генә хастаханә булган:

инвалидлар һәм гражданлык ведомствосы затлары өчен ике палата һәм тоткыннар өчен вакытлы бүлмә генә) 1863 елда шәһәр «голова»сы – 1 нче гильдия сәүдәгәре Никита Ушков акчасына төзелә.

Ишегалдында табиб өчен флигельне дә ул шәхсән үзе куярга куша: «...бер ишегалдында яшәгәндә, һәр табиб үз авырулары янына тәүлегенә бер яки ике тапкыр түгел, ә биш яки ун тапкыр киләчәк». Бер дә начар фикер түгел, шулай бит? Бәлки, моны да үзебезгә үрнәк итеп алырга кирәктер?

Ә медицина кадрларын үзендә тотып калу өчен земствоның кайгыртучанлыгы турында ни диярсез? Земство табибының елына 1300 сум тәшкил иткән башлангыч хезмәт хакына ике ел саен 200 әр сум өстәгәннәр. Квалификация күтәрергә теләгән табибларның һәм фельдшерларның, пособие алып, фәнни командировкага чыгып китү мөмкинлеге дә булган. Алабуга сәүдәгәрләре иганә ярдәмнәре аша медицина инструментларын сатып алырга, дәвалауның яңа ысулларын кертергә, хәтта штат исемлегеннән тыш табиблар ялларга булышкан.

Шунысы кызык: боларның барысы да Чехов бервакыт үзенең куен дәфтәренә: «Бай булмаган табиблар һәм фельдшерларны үзләренең идея өчен хезмәт итүләре дә юата алмый, чөнки һәрвакыт эш хакы, икмәк кисәге турында уйлыйлар», – дип язып калдырган сүзләр белән ничек бәйләнгән икән?

САРАЛЫДАН БАШ МИЕ СЕРЛӘРЕНӘ КАДӘР ЮЛ

Табибның «Чишенегез!» дигән кырыс әмереннән соң, авырулар кереп яшеренә торган пәрдә... Хастаханә өчен гүя төрмә камерасыннан прокатка алынган тимер карават... Холыксызларны тынычландырырга булыша торган гильотинага охшаш җайланма (психик авырулар палатасында кулланылган)...

Әлеге экспонатлар фонында музей залларының берсе тынычлык утравы булып күренә. Бу инде гади табибның кабул итү урыны да, ярлы-ябага өчен палата да түгел – дөнья масштабындагы медицина галиме Владимир Бехтеревнең эш бүлмәсе.

Җиһазлар да килешле һәм тиешле. Вакытны белдереп сугып куя торган кыйммәтле

сәгатьләр, мәһабәт имән өстәл, уңайлы урындыклар, нәфис фарфор чәй сервизы куелган кечкенә өстәл... Биредә үк академикның үзе исән чагында басылган фәнни хезмәтләре урын алган.

Дөрес, «Баш мие функцияләрен өйрәнү нигезләре» хезмәте авторы һәм Санкт-Петербург психоневрология институтына нигез салучы галим Алабуга земство хастаханәсендә беркайчан да эшләмәгән. Әмма бу бүлмә бөек якташыбызга карата үзенә күрә хөрмәтле хәтер билгесе. Владимир Бехтерев моннан берничә чакрым ераклыктагы Саралы (хәзерге Бехтерево) авылында туган, берара Казан университеты профессоры һәм Казан шәһәре округ дәваханәсенең психиатрия клиникасы мөдире булган...

Кабинетның пөхтә җиһазлануын бәяләп, революциядән соң Бехтеревнең Санкт-Петербургтагы Мәрмәр сарайны ничек карап йөргәнен искә алырга вакыт. Ул аны яңа хакимияттән үз институты өчен сорап ала. «Вазалар, картиналар һәм башкалар безгә кирәкми! – дип белдергән Бехтерев, погонсыз генерал пәлтәсе кигән килеш, чал сакалын җилфердәтеп бина буйлап йөргәндә. – Җиһазларыбыз да үзебезнеке – гадирәк, бронзасыз...»

ЧОРЛАРНЫ БӘЙЛӘГӘН ЧИРАТЛАР

«Баланы ничек карарга кирәклеген белсен өчен, хатынның аркасына һәм түбәнрәк җиренә көндез һәм кичен өч тапкыр камчы белән сугарга». Әти-әнисенең игътибарсызлыгы белән артык кайнар суга коендырылган күкрәк баласын караганнан соң, хирург Николай Швалев бервакыт шәфкать туташына әнә шундый «рецепт» биргән. Табиб сабыйга мазь сөртергә кушкан, ә ата-анага әнә шундый шелтә биргән, мөгаен, гомергә истә калдырырлык булгандыр.

Николай Швалев – медицина өлкәсенә алтмыш ел гомерен биргән легендар фронтовик хирург. Төрле елларда алабугаларны дәвалаган, аларның тормышларын саклап калган табиблар, шул исәптән Николай Швалев белән бәйле ядкарьләр дә музей экспозициясен баета. Биредә бик кадерле экспонатлар: табибларның шәхси әйберләре, фоторәсемнәр, эш кораллары...

Ә инде идәнендә 1881 елгы уникаль плитка (ул Алабуга сәнәгатьчесе Петр Ушков заводында чыгарылган) сакланган элеккеге операция бүлмәсендә үзегезне табиб ролендә сынап карау мөмкинлеген кулдан ычкындырмагыз. Монда буйны, авырлыкны, кан басымын үлчәргә, күрү сәләтен тикшерергә, тестларга җавап бирергә, сәламәтлек анкетасын тутырырга була. Һәм шунда ук, фитобарда, дару үләннәреннән ясалган хуш исле, шифалы төнәтмәләрне авыз итми калмагыз.

Һәм тагын бер киңәш. Өяз медицинасы музееннан киткәндә, истәлеккә фотога төшәргә онытмагыз. Иң шәп вариант – үзләрен кабул итүне сабыр гына көтеп утыручы XIX гасыр кунаклары белән бергә эскәмиягә утырып. Борын-борын замандагы медицина белән бүгенге көнне табиб кабинетына чираттан да ныграк якынайткан һичнәрсә юктыр, мөгаен.

НӘРСӘ:
В. М. Бехтерев исемендәге өяз медицинасы музее

КАЙДА:
Алабуга, Нефтьчеләр проспекты, 111а йорт

КАЙЧАН:
9:00 сәгатьтән 18:00 сәгатькә кадәр эшли. Ял көне – дүшәмбе

ИҢ ГАЯРЬ.
КАМАЗ МУЗЕЕ

«Татарстан» журналы версиясе буенча

КАМАЗга ярты гасыр! Автогигантны юбилее белән котларга Россия Президенты Владимир Путин килде. Ә «Татарстан» әлеге вакыйганы гаярь төзелеш һәм җитештерү батырлыклары тарихын саклаучы җыйнак һәм җылы завод музеен карап билгеләп үтәргә тәкъдим итә. Бу гади тарих кына түгел, кеше язмышлары тарихы.



Йөк машинасын җыюны мәктәп укучысына ышанып тапшырып буламы? Бүген моны күз алдына китерү дә кыен, ләкин 1970 нче елларда мөмкин хәл. Көннәрдән бер көнне КАМАЗның җыю цехына 12 сигезенче сыйныф укучысы экскурсиягә килә.

– Бригадирыгыз бик кырысмы? – дип пышылдап кына сорыйлар яшь оператордан.

– Кырыстан бигрәк, йомшактыр, – дип елмая тегесе.

– Алайса без дә валлар җыеп карыйк әле, – дип сорыйлар укучылар, кыюланып китеп.

Ә нигә юк әле? Куркынычсызлык техникасын аңлатып, нәрсәне ничек эшләргә кирәклеген күрсәтеп бирәләр. Һәм менә төшке аш вакытында бригада активына планнан тыш унике вал языла. Әйтергә кирәк, яхшы сыйфатлы.

Әлеге тарихны Николай Мальнев – кардан валлары цехы наладчикларының теге «йомшак» бригадиры сөйләде. КАМАЗдагы иң яхшы остаз ул. Аклы-каралы фотоларда сакланып, экспонатка әверелгән чын хәлләр музейда аеруча күп.

Катерина Котова
әзерләде

КЕМНӘР ТӨЗИ – ШУЛАРГА

Бу брошюраны кулга алуга тарих битләрен актаргандай буласың. 1974 елда аны тугызынчы бишьеллыкның иң зур төзелешенә эшкә килгән һәркемгә өләшкәннәр. Төсе уңа башлаган битләрдә ачык һәм эзлекле, ә иң мөһиме – илһамланырлык итеп төзелеш, яңа автогигант, яңа каланың нинди булырга тиешлеге турында язылган. Һәм, әлбәттә инде, КАМАЗ төзүчеләренең төп шигаре дә язылган: «Ике кеше өч кешелек эшли». Бу грандиоз планнарга тормышка ашарга насыйп була. Нәкъ менә әлеге шигарьнең тәэсире нәтиҗәсендә дә.

КАМАЗ тарихы – ил тарихы ул. 1970 нче елларда Чулман ярына урнашкан, ул вакытта әле зур булмаган шәһәргә Советлар Союзының бөтен почмакларыннан романтик рухлы комсомолларны җыялар. Гигант автозавод рекордлы кыска вакыт эчендә төзелеп, эшли башлый. Янәшәдә шулай ук яшен тизлегендә яңа шәһәр

Фото: КАМАЗ музее директоры Александр Чухонцев блогыннан

калкып чыга. Мондый удар төзелеш Советлар Союзында гына түгел, дөньяда да беренче була.

Төзелеш базасында беренче чүмеч җирне 1969 елның 13 декабрендә күтәрәләр. Моны башкару мәртәбәле экскаваторчы Михаил Носковка насыйп була. Ул Камгэсэнергостройның иң алдынгы машинисты була, ә ул вакытта, сөйләүләренә караганда, Михаил Носков кебек оста экскаваторчылар авыр чүмеч белән җирдән шырпы кабын да элэктереп ала алганнар. Музейда әлеге тарихи вакыйганың фотосурәтләре саклана. Шулай ук Михаил Носков хатирәләре.

«1969 елның декабре иде. 12 сендә кичкә калып кына ярдәмчем белән бергәләп, экскаваторны трайлерга төядек тә төзелеш булачак мәйданга таба кузгалдык. Караңгы, кар бураны, аяктан егарлык җил. Егерме чакрымлап узгач, Минзәлә трактына борылып туктадык. Анда безне бульдозерчылар Данилов, Бухаров, Миңнегәрәев, скреперист Насыйров көтә иде. Таң беленә башлады. 13 декабрьгә кердек. Клин-бабаны тактым, туңган җирне йомшарттым. КрАЗлар килеп җитте. Бульдозерлар өемнәр буласы җиргә юлларны чистартып куйды.

– Ну, Михаил Тимофеевич, башла! – дип, команда бирделәр миңа.

Дизельнең әйләнешләрен көчәйттем. Чүмечне забойга керттем. Балчык тутырып алып, аны самосвалга салдым. Алкышлар яңгырады, фотоаппарат төймәләренә бастылар...»

Төзелеш темплары, заводныкы гына түгел, шәһәрнеке дә – шаккатарлык. «Иртә белән эшкә бер сукмактан китәсең, кайтканда шул урынны урап узарга кирәк – анда яңа объект төзелгән яки нигез чокыры казылган», – дип искә алган берничә ел Бөтенсоюз удар комсомол төзелеше штабын җитәкләгән Рим Халитов. 1975–1976 елларга туры килгән иң кызу чорда бер төзелеш мәйданында 95 меңгә якын кеше эшләгән!

Тарихтагы аерым бер сәхифә – Чаллының данлыклы... пычрагы. Музейда никадәр хатирәләр саклanган да резин итекләргә никадәр мәдхия җырланган! Менә алар – удар төзелеш каһарманнары – тездән пычракка батканнар. 1972 елгы фотода КАМАЗ Төзелеш-монтажлау идарәсе эшчеләре: берсе егылган да икесе аны күлләвектән сөйрәп торгызып маташа. Газетада чыккан язма елмаю уята: «Хәзер «Батыр» кинотеатры урнашкан җирдә нигез чокыры гына иде әле, – дип искә ала Мәдәният һәм ял үзәге директоры Александр Никитин. – Аның аша без басма салдык. Басма буйлап кулына бала күтәргән ана килә. Каршына туйга баручы егетләр – кияү егете һәм аның дуслары. Барысы да бәйрәмчә матур киемнән. Әлеге шау-шулы компания басманы шундый итеп селкетә, теге хатынның баласы кулыннан ычкынып, туптуры чокырдагы пычракка барып төшә! Шул мизгелдә ике дә уйлап тормыйча бала артыннан тагын әллә ничә егет сикерә. Баланы әнисенә алып бирәләр дә үзләре яңадан тулай торакка кием алыштырырга йөгерәләр. Бүлмәләр буйлап йөреп, костюмнар эзлиләр. Табалар, киенәләр дә – туйга!»

ЙӨК МАШИНАСЫНЫҢ ХАКЫ

Автогигантның проект егәрлеге шаккатырырлык – елына 150 мең автомобиль һәм 195 мең көч агрегаты һәм двигатель! Яңа заводка дигән станоклар һәм җиһазлар бөтен дөньядан кайта. Музейда саклана торган документларга карап, аларның географиясен өйрәнеп була. Салкын штамплау пресслары Чаллыга ГДРдан килә, электр төягечләр – Болгариядән. Шулай ук, Чехословакия, Польша, Венгрия заводны җиһазлауга өлеш кертә... Музей директоры Александр Чухонцев сүзләренә караганда, Түгәрәк Алан, Сидоровка районнары тирәсендә тимер юлда меңнәрчә вагон җыелган көннәр дә була! Чыннан да, КАМАЗны ил белән төзиләр.

Автогигант музеенда кызыклы бер фото бар. Әллә нәрсә җәлеп итәрлеге дә юк кебек: агач, йорт, үтеп баручылар кадрга карамый да. Нәрсәсе белән кызыклы соң? «Энергетик» мәдәният йорты каршындагы җәяүлеләр өчен җир асты кичүенең түбәсенә урнаштырылган шигарьнең текстына игътибар итегез: «Егетләр һәм кызлар! ВЛКСМның XX съездында Ленин комсомолы рапортына кул кую хокукы өчен көрәшегез». Димәк ки, рапортка кул кую хокукы кебек мактаулы эш өчен шактый тир түгәргә туры килгән! Ә менә удар хезмәт рапорты үзе дә монда! Аннан «ВЛКСМның XX съезды исемендәге коллектив» исемен йөртү хокукы өчен көрәштә 320 комсомол-яшьләр коллективы катнашуын беләбез. Ә «Үз һөнәре буенча иң яхшы яшь эшче» исеменә ярышта берләшмәнең 60 мең яшь эшчесе катнашып, һөнәри осталыгын камилләштерә, һөнәри осталык буенча 225 бәйгедә 3 меңнән артыграк яшь эшче катнаша, 8 меңнән артык яшь эшче чиктәш һөнәрләргә ия була. Кай ягы белән WorldSkills-тан ким?

Ә менә бу артефактны – завод халкы өчен белешмәлекне – хәзерге предприятиеләр үзләре өчен үрнәк итеп алырга мөмкин. КАМАЗның кадрлар бүлеге хезмәткәрләре махсус эшли аны. Эшләми ни, автогигантка көн саен дистәләгән, кайчак йөзәрләгән кеше эшкә килә. Белешмәлектән яңа килгән эшчеләр хезмәт шартлары, социаль ташламалар, квалификация күтәрү һәм башка күп нәрсә турында укып белгәннәр.

Кызыклы фактлардан: 1979 елда заводта биш көнлек эш атнасы кабул ителә – элек шимбә эш көне була, ярты ел эчендә «малосемейка» бирелә, ә социалистик ярышлар арасында «Җитештерүдә югары мәдәниятле һәм эстетикалы цех» дигәне дә булган, анда җиңүчеләр мактау кәгазеннән кала, акчалата да бүләкләнә.

1979 елның 10 июлендә җыю конвейерыннан 100 000 нче йөк машинасы төшә. Аны җыю хокукына ия булыр өчен ярышта 83 меңнән артыграк кеше катнаша! Бу турыда музей фондында сакланган «КАМАЗ яшене»ннән беләбез. Аңа кадәр ирешелгән биеклек – 50 меңенче КАМАЗ. Аның ачкычы Социалистик Хезмәт Герое, шофер Рәис Заһидуллинга бирелә. Автомобильне җитештерүдә 80нән артык хезмәт алдынгысы катнаша.

Сүз уңаеннан, юбилей автомобиле ачкычы кемгә тапшырылса, шуңа мәңгелеккә кулланырга дип бирелә. 1980 елга кадәр андый бәхеткә данлыклы шоферлар гына ия була. Аннан соң машина «КАМАЗның олы бүләге» бәйгесендә катнашып җиңгән кешегә бирелә башлый. Җиңүчеләр автомобиль генә алып калмый, символик ачкычлы да була. Алай да шуларның берсе – миллионынчы КАМАЗныкы музейда калган.

Ничек уйлыйсыз, ерак 70 нче елларда мондый йөк машинасы ничә сум торды икән? Музейда бу сорауга да җавап табарга була. Документка күз салыйк: 1976 елда 5320 модельле йөк машинасының үзкыйммәте 29,2 мең сум торган, күпләп сату бәясе нибары 15,4 мең сумны тәшкил иткән. Ун еллап вакыт узгач, бу аерма азмы-күпме тигезлеккә якынайган: 12,5 мең сум дип фаразланган үзкыйммәте вакытында күпләп сату бәясе 13,7 мең сумны тәшкил

1972 елгы сирәк фото. Сүтелми торган, авырлыгы 500 тоннага кадәр булган җиһазны кабул итү причалы. Йөк Яр Чаллыга Чулман буйлап килә.

1979 елның 8 июле. Яр Чаллыда йөк машиналарының беренче автокроссы. Татарстанда комсомол оешмасы барлыкка килүнең 60 еллыгына багышлана.

иткән. Билгеле булганча, КАМАЗны сатып алучылар даирәсе колач җитмәслек СССРның предприятиеләре һәм оешмалары белән чикләнгән. Шәхси сатып алучыларга тере акчага 1988 елдан гына сата башлыйлар.

«Конвейердан төшкән генә өр-яңа авыр йөк машиналары автокибет мәйданында тора. Сатып алучы үзенә ачык кызыл кабиналы һәм тент белән каплаулы кузов булган КАМАЗ сайлап алды, двигателен тыңлап карады һәм: «Алам!» – диде. «Акчаны кассага түләгез», – дип җавап бирде сатучы, һәм сатып алучы акча түләргә китте...» 1988 елның 21 августында чыккан «Известия» газетасындагы язма шундый җөмләләр белән башланып китә. Газета музей фондында саклана. Шунда ук беренче сатып алучыларның Казан кооператорлары булуы да язылган. Машинага килешү бәясе 70 мең сум булса да, ул сатып алучыларның кесәсенә сукмый.

1993 елның 14 апреле – КАМАЗ тарихындагы фаҗигале көн. Санаулы минутлар эчендә ялкын двигательләр заводын ялмап ала. Җитештерү корпусы һәм технология җиһазлары юкка чыга.

БУЛГАН ХӘЛ ҺӘМ КӨНКҮРЕШ

Бервакыт ремонт-эш кораллары заводының партком секретаре Рудольф Шуранов өстәленә шикаять ята. Янәсе, шундый алга киткән заманда тешләрне ничек итеп иске бормашина белән борауларга була... Шикаятьне активлардан булган бер яшь хатын яза. Шуннан соң ул эшчеләрне ашханә ишеге төбендә сагалап тора: «Теш кабинетында искергән бормашина торуы белән килешәсеңме? Килешмәсәң, кулыңны куй!» Өч йөз кеше кул куя. «Хәзер кире бора алмаячаксыз!» – дип белдерә ул Шурановка. Тегесе исә бормашиналарның кайда эшләнүен белешә дә хатынны: «Яңа бормашинасыз кайтма!» дип, командировкага озата. Күпмедер вакыттан соң ул РИЗга теш кабинеты өчен өр-яңа аппаратура белән кайтып төшә. Стоматология кабинетында елмаеп утырган йөзләрне тарихи кадрлардан күреп була.

Сүз уңаеннан, КАМАЗда көнкүреш мәсьәләләренә җитди карыйлар. «Мондый киң колачлы төзелеш һәм мондый кыска вакыт эчендә төзелгән шәһәр дөнья практикасында юк иде әле» – бу сүзләр күренекле совет архитекторы, шәһәрнең Генпланы проекты авторы Борис Рубаненконыкы. Төзелеш темплары халык саны артуга бәйле булган – кайвакыт КАМАЗга бер көн эчендә биш йөзләп кеше килгән. Төзүчеләрнең әлеге – тагын бер батырлыгы – турында символик агач ачкыч хәтерләтеп тора. Аңа 1 000 000 саны төшерелгән – 1976 елның 7 августына Яр Чаллыда нәкъ шулкадәр квадрат метр торак мәйданы кулланылышка тапшырылган.

Тәэминат белән ничек? 1976 елдан башлап, 4 ел эчендә шәһәрдә ике универсамны да кертеп, утызга якын кибет ачыла. Музей фондларында авыр 1991 елда үткәрелгән «УРС товарларына сатып алучылар ихтыяҗы» маркетинг тикшеренүенең нәтиҗәләре саклана. Нәтиҗәләр бик кызык. Бу факт сезгә ничек: ихтыяҗ аз булган товарлар исемлегенә зиннәтле әйберләр генә түгел, ә көнкүреш техникасы да кертелә. Тикшеренүчеләр язганча, техникага кызыксыну булмау, беренче чиратта, халыкта аңа ихтыяҗның түбәнлеге белән аңлатыла, бәянең кыйммәт булуы аннан соң гына килә. Тагын бер кызыклы тикшеренү: «нәкъ менә Чаллы халкына гына хас мәдәни сыйфатлар»ны билгеләү. Беренче пункт: «Безнең хатын-кызлар мода артыннан кумый. Матур киемгә булган ихтыяҗлары ирләрнекеннән артык түгел». Икенчесе: «Престижлы әйберләргә омтылыш, бигрәк тә яшьләрдә. Индивидуальлек тә түгел, зәвыклы булуы да түгел, ә нәкъ менә модалы һәм престижлы булсын».

КАМАЗ музее архивны хәтерләтә – биредә документларда казынырга, фактларны «казып чыгарырга», гаҗәпләнергә, сораулар туса, аңа җавап табарга була. Әйе, Чулман ярындагы әлеге батырлык тарихы – чын мәгънәсендә илебез тарихы ул. Һәм ул сакланган – шунысы сөенеч.

Музейда гадәти булмаган кепка саклана – КАМАЗның үзенә бер талисманы. Предприятиенең беренче гендиректоры Лев Васильевны күп фотоларда нәкъ шул кепкадан күрергә була.

Материалларны әзерләгәндә КАМАЗ музее директоры Александр Чухонцев блогы мәгълүматлары да файдаланылды.



ИҢ ӨМЕТЛЕ.
ЧИСТАЙ МУЗЕЙ-ШӘҺӘРЕ

Якындагы берничә ел эчендә Чистай шәһәренең яңарышы көтелә. Бу юлы – шәһәр-музей кыяфәтендә. Вакыйгаларны ашыктырып, «Татарстан» Чистай тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен дөньяга күрсәтәчәк маршрут буенча йөреп чыкты.

«Татарстан» журналы версиясе буенча

«...Без туризмны үстерүдән тыш, Чистай үсешенең башка «таяныч ноктaларын» да күрәбез. Мондый комплекслы гамәлгә ашыру синергия нәтиҗәлелеген тәэмин итәчәк. Бу, бер яктан Россиядән туристлар агымын көчәйтер, икенче яктан, халыкның табышын арттырыр, дип көтелә, соңгысы үз чиратында шәһәр инфраструктурасын үстерүгә күбрәк чыгымнар тотачак», – диде Россия буенча Яңа үсеш банкының баш белгече Тянь Хе 2018 елда шәһәргә килгән вакытында. Ул чакта банк «Кече тарихи җирлек территорияләрен һәм инфраструктураларын комплекслы үстерү» программасында катнашу өчен Чистай тарафыннан бирелгән гаризаның ни дәрәҗәдә нигезле булуына бәя бирде.

Кунакларның күргәннәргә исләре китте. Банк Россиянең 9 кече тарихи җирлегенә биргән 220 млн долларның 38 млн доллары Чулман ярындагы шәһәргә бүленде. Әлеге акчаларга Чистай дәүләт музей-тыюлыгының 10 объектын (15 бинасы) һәм тарихи мохиткә кергән 21 объектны (24 бинаны) реконструкцияләү күздә тотыла. Проект эшләре – 2022 елга, реконструкция 2025 елга төгәлләнергә тиеш. Ләкин киләчәктә пәйда булачак туристлык нокталарының 10сына без бүген үк сәяхәт кыла алабыз.

Автор:
Ксения Сёмина

№1 ЯКЫНДАГЫ МУЗЕЙ

Җыйнак, сәүдәгәрлек рухы сеңгән шәһәрдә беренче карашка ук төрмәне дә, ату җәзасы башкарыла торган ишегалдын да күреп булмый кебек. Ләкин эчке ягы шундый. Без башлангыч училищеның тыйнак кына торган ике катлы бинасы янында басып торабыз **(К. Маркс урамы, 1).** Биредә сәяси репрессия корбаннары һәм диссидентлар музее ачылачак.

Чистай төрмәсе XIX гасыр уртасында төзелгән. Аның «кирәклегенең» иң югары ноктасы XX гасырның 40 нчы елларына туры килә. Бөек Ватан сугышы башында шәһәргә заводларны һәм иҗади элитаны гына түгел, 1,5 мең тоткынны да күчерәләр, шул исәптән 58 нче маддә буенча (контрреволюцион эшчәнлек өчен – ред. иск.) хөкем ителгән күренекле җәмәгать эшлеклеләрен, хәрбиләрне һәм галимнәрне дә. 1941 елда яңа килгәннәр арасыннан меңгә якын тоткын үлә. Чистай тарихчылары фикеренчә, ГПУ хастаханәсенең репрессияләнгән хирургы Сергей Осипович Пальк та биредә корбан була.

Сугыштан соң төрмә махсус билгеләнештәге психиатрия хастаханәсе итеп үзгәртелә. Аннан соң – тагын төрмә. 70 нче еллар ахырында бирегә дәүләт җинаятьләре өчен хөкем ителгәннәрне китерә башлыйлар. Алар арасында Израиль ЭЭМның булачак җитәкчесе Натан Шаранский һәм Мәскәү Хельсинки төркемендә катнашучы Анатолий Марченко да була. Беренчесе төрле төрмәләрдә 9 ел утыра, һәм 1986 елда аны совет разведчиклары белән алмаштырып Израильгә чыгаралар. Икенчесе шул ук 1986 елда чираттагы ачлык тору зыяны нәтиҗәсендә Чистайда үлә.

Заманча мәдәният кабул итү һәм аңлау өчен җиңел булмаган мондый материалга аудиторияне «чумдыру» буенча зур тәҗрибәгә ия. Мәскәүдә, Россия Театр әһелләре берлегенең Үзәк фәнни китапханәсендә, «Время, которое» дип аталган аудиоспектакль зур уңыш белән бара, анда бер кыз 1930 нчы еллардагы гаилә тарихын өйрәнә. Казанда «Угол» театраль пространствосында «Свидетели» спектаклен карарга килгән һәркем үзен ГУЛАГ тоткыннарының туганы-якыны итеп тоя ала.

Автор фотолары

№2 СӘҮДӘГӘРЛӘР ЮККА ЧЫКСА ДА, КӨНКҮРЕШ КАЛА

XX гасырның 30 нчы еллары салкыны һәм караңгылыгыннан XIX гасырның яктырак 30 нчы елларына күчү өчен бер урам чыгарга һәм сәүдәгәр Алексей Подуруев утарына **(К. Маркс урамы, 8)** әләгергә генә кирәк. Реконструкция планы буенча утар тулысынча сәүдәгәр көнкүреше музеена биреләчәк. 100 ел дәвамында диярлек – XIX гасырдан XX гасыр башына кадәр – нәкъ менә сәүдәгәр итү шәһәрнең язмышын билгеләгән. «Монополия» уенының сәүдәгәр версиясе өчен әзер нигез.

Ул заман Чистае – Казан губернасының икмәк сату башкаласы, сәүдә әйләнеше елына 144 мең тонна ашлык белән исәпләнә. Икмәк сату белән идарә итүче Челышевлар һәм Шашиннар, башка җирле сәүдәгәр династияләре кебек үк (Чукашевларны санамаганда), – староверлар. Сәүдәгәрләр акчаларын актив рәвештә шәһәр инфраструктурасына салалар. Затлы таш биналар, хастаханәләр һәм гимназияләр шул рәвешле пәйда була. Әлеге биналар һәм шәһәр базары уртасындагы су башнясы бүген дә шул чорның тере дәлилләре. Ул вакыт турындагы легендалар әле дә яши: Василий Челышевның миллионлык мирасын бер варисның икенчесеннән яшерү тарихына нигезләнеп кызыклы квест оештырырга мөмкин. Ә җиңүчене – сәүдәгәрләрчә әзерләнгән чәй табынында сыйларга.

№3 БАРЛЫК ЧОРЛАР АША

Урамның каршы ягына, Никита һәм Гаврила Чукашевлар утарына **(К. Маркс урамы, 15)** чыгыйк. Бүген биредә Бөек Ватан сугышына багышланган күргәзмә бара. Ә Чистай тарихы музее итеп ясау планлаштырыла, чөнки аңа Подуруевлар утарында кысанрак.

Чукашевларның ярдәмче биналар комплексы да булган иркен утарында Чистайга кадәр биш йөзләп ел элек биредә урнашкан болгарларның Җүкәтау шәһәрен җентекләп реконструкцияләү өчен дә, күренекле Чистай татарлары, йөзьеллык Нур мәчете, уникаль композитор София Гобәйдуллина гаиләсе турындагы тарихлар өчен дә, бүгенге индустриаль шәһәр инсталляцияләре өчен дә урын җитәчәк. Атаклы «Командир» сәгатьләренең ничек ясалганын күрү дә, легендар, үткәнендә оборонага караган «Вектор» компаниясе җитештергән дрон белән идарә итү пультын кулыңа тотып карау да кызык булачак. Һәм инде шуннан олы әдәбият эзләре буйлап сәяхәткә китәргә дә…

№4 һәм №5 «ЯБЫРЫЛУ»ГА КАДӘР ҺӘМ АННАН СОҢ

«…Россия – ул, туган, шундый пирог, күбрәк ашаган саен, күбрәк кала!» – ди сәхнәдән «Ябырылу» («Нашествие») пьесасының антигерое Фаюнин. Урамда – 1942 ел… Чистайда, Укытучылар йортында, пьесаның беренче куелышы. Эвакуациядәге 200 әдәбиятчының күпчелеге, алар арасында пьесаның авторы Леонид Леонов та, тамашачылар залында утыра. Берничә айдан соң «Ябырылу» Сталин премиясенә лаек булачак. Автор премия акчасын фронтка бирәчәк, ул акчаларга танк төзеләчәк.

Пьесаны Леонов берничә ай эчендә үз гаиләсе һәм шагыйрь-фронтовик Илья Сельвинский гаиләсе белән бәләкәй, таушалган куас кайнату бинасында яшәгән вакытында яза. Язучы әлеге флигельне, кеше яшәрлек итеп, үз куллары белән ремонтлый. Авыр вакыт булуына һәм режиссёр Сергей Эйзенштейнга язган хатында Леонов Чистайны «тыныч һәм шыксыз шәһәрчек» дип атавына да карамастан, нәкъ менә биредә автор үзенең иң төп әсәрләренең берсе булачак «Ябырылу»ның сюжетын күрә, геройларының прототипларын таба. Уңай персонажларда биредә табиб булып эшләгән ике кеше – Дмитрий Авдеев һәм Самуил Самойлов шәйләнә, язучы алар белән бик дус була.

XXI гасыр туристлары иҗади эзләнү атмосферасына чума алачак. Леоновлар һәм Сельвинскийлар яшәгән флигель **(К. Маркс урамы, 22)** музейга әвереләчәк. Ә Константин Федин, Александр Фадеев, Александр Твардовский, Василий Гроссман, Михаил Исаковский, Алексей Сурков, Лев Ошанин. Виктор Боков һәм башкалар үз әсәрләрен укыган һәм тикшергән Укытучылар йортында **(революциягә кадәр – Ковалевский даруханәсе, К. Маркс урамы, 28)** әдәби мирас экспозициясе урын алачак.

№6 БЕЛЕМ ЯЛКЫНЫНДА

Чистайда физика, дөресрәге химия, һәм лирика – бер медальнең ике ягы. **К. Маркс урамы, 40** адресы буенча бөек галим Александр Бутлеровның музее урнашачак. Чистайлылар органик матдәләрнең химик төзелеше теориясен уйлап тапкан галимнең нәкъ менә аларның шәһәрләрендә тууын ачыклаганнар.

– Барысын да тәҗрибәдә сынап карау – мөгаллим Бутлеровны аерып торган сыйфат әнә шул булган. Студентлар профессорның нәрсә һәм ничек эшләвен карап тора алганнар. Шуңа күрә музей да интерактив булачак. Теләге булган һәркем экспериментларда катнаша алачак, ихтимал, әле виртуаль чынбарлык ярдәмендә үткәннәргә кереп, бөек галимнең аммиак һәм формальдегидтан коры ягулык ясавын күзәтеп торырга да мөмкинлек тудырылыр.

№7 БИЛГЕСЕЗ ЗУРЛЫК

Маршрутыбызның тукталышы һәм шәһәрнең визит карточкасы – шпиль белән бизәлгән йорт, сәүдәгәр Мельников утары **(К. Маркс урамы, 31).** Биредә туристлар өчен мәгълүмат үзәге урнашкан. Аны формасы ягыннан да, эчтәлеге ягыннан да бердәй мөһим булган реконструкция көтә.

Ноябрь аенда Казанда үткән һәм туристлык маршрутларын үстерүгә багышланган форумда Туристлыкны үстерү үзәге директоры Эльмира Туканова объектларга туроператорлар һәм туристлар тарафыннан куелган таләпләр белән таныштырды. Беренчеләрен яхшы инфраструктура, объектларның эш сәгатьләренең кулайлыгы, төрле төркемнәр өчен махсус тарифларның булуы, шулай ук музейның вакыйгаи активлыгы кызыксындыра. Берүзләре генә килүчеләргә музей турында мәгълүмат, уңайлы мохит, аудиогидлар, навигаторлар һәм сувенирлар кирәк. Боларның барысын да яңартылган Чистай туристлык-мәгълүмат үзәгендә тормышка ашырырга мөмкин булачак. Һәм үзәк аша туристларга, россиялеләргә һәм чит илләрдән килгәннәргә, шәһәр, аның хәзергесе һәм киләчәге турында сөйләргә мөмкин булачак.

Шул ук форумда Милли мәгълүмати-туристлык оешмалары ассоциациясе директоры Михаил Ушаков болай диде: «Сез иң кыйммәтле экспонатка ия булырга мөмкинсез, әмма аны күрсәтә белергә кирәк. Социаль челтәрләрдә музеегызда, әйтик, дөньяда иң борынгы эрләгеч, каба барлыгын язygыз, кешеләр сезгә нәрсәне күрергә килүләрен аңларга тиеш».

Әлегә бернинди дә милли маршрутка кермәгән Чистай өчен үзен шул рәвешле таныта белү бик мөһим. Нинди генә мәдәни-тарихи тыгызлыкка, байлыкка ия булмасын, шәһәр «тар даирәләргә генә яхшы билгеле» бит. Һәм без, татарстанлылар өчен, күптән таныш нәрсәләр башка төбәкләрдән киләчәк кунаклар өчен – ачыш. Мәсәлән, «Коммерсантъ» газетасы хәбәрчесе декабрь санында болай дип яза: «Доктор Живагоның прототибы нәкъ менә Чистайда яшәгән икән бит».

№8 һәм №9 БӨЕКЛӘРГӘ КУНАККА

Бирегә килгәч кенә бөтен Чистайны бер көндә карап чыгу мөмкин түгеллеген аңлыйсың, хәер, бу шундый әдәпле, тыныч ритмлы шәһәргә карата гадел дә булмас иде. Шуны аңлаган туристлар өчен биредә, сәүдәгәр Петр Шашин утарында **(Театр урамы, 5),** кунакханә ачылачак, шулай ук конференц-зал һәм күргәзмә залы да.

Ихтимал, биредә шулай ук бала чакларының берничә ае яисә елы Чистайда, эвакуациядә үткән илкүләм һәм дөньякүләм билгеле кешеләрнең портретлары галереясы да пәйда булыр. Бу Георгий Эфрон, Тимур Гайдар, Алексей Баталов, Кир Булычёв, Леонид Рошаль һәм башка бик күпләр. Булачак кунакханәдән ике метрлап киткәч, сайдинг белән тышланган гаять зур куб тора. Бу – сәүдәгәр Фёдор Зайцев утары **(Ленин урамы, 68).** Бинага борынгы затлы кыяфәте кайтарылачак, монда фондларны саклау урыны булачак, реставрация остаханәләре дә урнашачак.

1990–2000 нче елларда Чистайдан үзәк республика музейларына сәүдәгәрләрнең антиквар китаплары, картиналар коллекцияләре (шул исәптән Николай Фешин картиналары), башка борынгы предметлар тупланмалары күчерелә. Реконструкция вакытлыча саклауга бирү шарты белән әлеге ядкарьләрне экспозицияләргә урнаштырырга шартлар тудырачак.


Пристань бинасы (архивтан)

Грантның мәҗбүри шарты – төбәк ягыннан да реконструкциягә финанслар бүлеп бирү. Татарстан шәһәрнең тарихи үзәгендә коммуникацияләрне алыштыру максатына акчалар бирә, шулай ук пассажирлар пристанен һәм причал урынын төзүне үз өстенә ала. Иллюстрациядә: Чистайда Пассажир пристане проектының эскиз варианты. Эскизның авторы – рәссам-архитектор Александр Лопаткин.

Кече шәһәрләрне үстерү фонды акчаларына һәм «Парклар һәм скверлар» республика программасы буенча үзәк бульвар яңартылган. Эшләр тәмамланган диярлек, бары тик металл конструкцияләрне, аларга тәгәлләнгән кыяфәт бирү өчен, эскизда күрсәтелгәнчә агач рейкалар белән тышлыйсы гына калган.

№10 АЧЫШЛАР БҮЛМӘСЕ

Программабызның соңгы пункты (инде үзеңне Чистай буенча белгеч итеп сизә башламасаң да, аңа гашыйк икәнеңне тойган вакыт!) – Борис Пастернакның Мемориаль музее **(Ленин урамы, 81).** 2014 елда Чистайга килгәндә Россия мәдәният министры Владимир Мединский иң көчле тәэсирләрне нәкъ менә монда, Пастернак ике ел дәвамында диярлек йөргән бүлмәләр һәм баскычлар буйлап атлаганда алган, дип сөйлиләр.

Язучы «Ромео һәм Джульетта» тәрҗемәсенең текстын җыйган һәм доктор Дмитрий Авдеевны доктор Живагога әверелдергән язу машинкасы куелган эш өстәле торган бүлмә сакланачак. Ә инде үз ихтыяры белән Нобель премиясеннән баш тарткан язучыга багышланган калган экспозиция яңартылачак һәм киңәйтеләчәк.

«Чистай тарихын саклаучыларга рәхмәт! Шәһәргә – иминлек, муллык, шәһәрлеләргә кече Ватаннары белән горурлануларын телим!» – дип язган Владимир Мединский музейның теләкләр китабына. Әмма министрның теләкләрен тормышка ашырырга музейчыларның гына көче җитеп бетмәскә мөмкин.

ИҢ МӨҺИМ №

«Чистайда куркыныч хәлләр бара», – дип язды 25 ноябрьдә ТР Президенты ярдәмчесе Олеся Балтусова үзенең «Фейсбугындагы» битендә. Ул бу сүзләрен XIX–XX гасырларларда шәһәр мохитен тудырган, авария хәлендә дип кешеләре күчерелгән йортларның контрольсез рәвештә җимерелүен күз алдында тотып әйткән иде. Реконструкцияләү проектына әлеге йортлар (барлыгы 162) кермәгән, чөнки БРИКСка гариза тутыру вакытында аларны бушату бара, статуслары әлегә булмый. Моннан тыш, шәһәрдә 144 мәдәни мирас объекты (ММО) санала. Аларның бер өлеше ташламалы шартларда бизнеска арендага биреләчәк, әмма бу озак процесс. Тагын берничә дистәсе буенча экспертиза бара.

– Әгәр экспертлар, бу биналарны алга таба сүтү өчен, ММОнан сызып ташласалар, бу Казанда 2000 нче еллардагы югалтуларга тиң масштабларда булачак, ә ул чакта башкала үзәге тарихи мохиттән колак какты, тузган торактан гына түгел, ә иң матур тарихи йортлардан да, – диде Олеся Балтусова. – Ләкин программага кергән һәйкәлләр дә БРИКСны көтеп җиткерә алмаска мөмкиннәр. Аларны беркем дә сакламый. Мародёрлар ишекләрне, тәрәзәләрне салдыралар, паркетларны, мичләрне сүтәләр. Бу варварлыкны туктатырга кирәк. Бүген Бөтенроссия тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне саклау җәмгыятенең Татарстан төбәк бүлеге, шәһәр администрациясе, Чистай дәүләт музей-тыюлыгы һәм волотёрларның уртак көченә таянып, йортларны консервациягә кую буенча акцияләр үткәрәбез. Коймалар тотабыз, элмә такталар урнаштырабыз, кизү торабыз. Музей дирекциясенә мөрәҗәгать итеп, һәркем теләсә кайсы формада ярдәм күрсәтә ала.

P.S. Быел Халыкара музейлар советы «музей» төшенчәсенә яңа билгеләмә тәкъдим итте. Аның бер өлеше болай яңгырый: «Музейлар – үткәннәр һәм киләчәк турында тәнкыйди уйланыр һәм тикшерер өчен булдырылган демократик, инклюзив һәм полифоник пространстволар». Мондый уйланулар өчен идеаль мәйданчык – чын тарихи биналар, әһәмиятле вакыйга урыннары. Тарихи мохитне торгызу җирле икътисад өчен дә файдалы. Чистайга охшаш шәһәрләргә туристлар беренче чиратта борынгылык атмосферасын эзләп килә, заманча экспозицияләр югалган аутентик биналарны алыштыра алмыйлар. Бәхеткә, Чулман ярындагы шәһәрдә аларны саклап калу мөмкинлеге бар әле.

Нынешнего году ... выходцев Мусаи Битове

А

азанами кроме того дадено данные ино потребно

деньги нигде не работы порабаны казов

оправлять стало нечем,

Чтобы указом вашего величества повелено было

сие мое челобитье в канцелярии взять по рабочем

жалованье записать в книгу.

Всемилостивейшая государыня императрица прошу

вашего величества о сем моем челобитье

решение учинить. Июня ... дня 1725 го

[illegible]

[illegible]

[illegible]

Адмиралтействога беркетелүчеләрнең гарызнамәләреннән. 1725 ел.

«ТАТАРСТАН» МАХСУС журналы өчен

ПЁТР I ПАТША
ГАЛИҖӘНАПЛАРЫ – КАЗАНДА

Краснова В. «Патша Петр I Казанда»

Хәзерге көндә дәүләт җитәкчеләренең төбәкләр буенча даими йөрүләре беркемне дә гаҗәпләндерми. Тарихка күз салсак, XVII гасыр ахырына кадәр Россия патшалары, каядыр еракка барып йөрмичә, Мәскәүдән генә ил белән идарә иткәннәр дигән күзаллау туа. Һәм менә хакимияткә яшь, көче ташып торган Петр патша килүгә, ил күләмендә гаять зур үзгәрешләр башлана. 1722 елда Петр I нең Персия походы барышында Казанда тукталуын бирәдә иң югары дәрәҗәдәге очрашулар уздыру традициясенә нигез салу, дип карарга мөмкин.

ПЕРСИЯ ПОХОДЫ

Петр I нең көньяк юнәлештәге ниятләре, башкалары кебек үк, зурдан була. Ул вакытта Һиндстанга Идел елгасы – Каспий диңгезе – Сырдәрья елгасы аша су юлы белән барып җитеп, җиңел генә сәүдә итеп булыр, дип уйлаганнар. Әмма тикшерә торгач, барысы да алай җиңел генә түгел икәнлеге ачыклана – күчмә-утрак тормыш алып баручы халыклар яшәгән меңәрләгән чакрым коры җирләрне үтәсе бар, Каспий диңгезен дә гади елга көймәләре белән генә йөзеп чыга алмыйсың, диңгез яр буйлары тулысынча диярлек Персия кулында. Шулай да адәм баласы, байлыкка, хакимлеген киңәйтергә омтылып, кайларга гына бармый. Төньяк сугышын уңышлы гына тәмамлагач, хәрби көчләрне Каспий диңгезенә җибәрү өчен мөмкинлекләр ачыла. Коры җир гаскәрләре, походка дип, алданрак кузгала. Ә 1722 елның 15 маенда Петр I гвардия полклары белән Коломнадан су юлы буенча сәфәргә чыга. Император үзе «Москвитянин» стругында йөзә.

ПАТШАНЫ КАРШЫ АЛУ

Ниһаять, 27 майда Петр I Казанга килеп җитә. Аны монда шәһәр һәм губерна хуҗалары, халыкны җыеп, туплардан атып, чаңнар кагып, бик зурлап каршы ала. Каршы алучылар арасында Казан губернасы губернаторы Алексей Салтыков, вице-губернатор Никита Кудрявцев, митрополит Тихон III һәм башкалар була. Казан губернасы оешканнан соңгы беренче еллар тарихы өчен бу очрашу гаять истәлекле килеп чыга.

КАЗАН ГУБЕРНАСЫ ОЕШУ ТАРИХЫННАН

Петр I нең административ реформалары нәтиҗәсендә 1708 елда Рус дәүләте 8 губернага бүленә, шул исәптән Казан губернасы да төзелә. Баштагы чорда ул Түбән Новгородтан алып Әстерханга кадәрге бик зур мәйданны били, әмма инде бик тиздән аңардан Түбән Новгород (1714 ел), Әстерхан (1718 ел) губерналары аерылып чыга. Губерна белән идарә итүдә губернатор һәм вице-губернатор төп вазыйфалар-



Автор:
Илшат Фәйзрахманов



1. Петр I Казанда. Виктор Федоров рәсеме.

ны башкара. Никита Алферович Кудрявцев 1697 елда ук Казанга җибәрелеп, воевода (1697–1706), комендант (1706–1710), обер-комендант (1710–1714), вице-губернатор (1712–1727) булып тора – бу вакытта Казанның иң атаклы кешесенә әйләнә. Алексей Петрович Салтыков – 1719–1724 елларда Казан губернасы губернаторы. Ул идарә иткән чорда гаять мөһим эшләр башланып китә. Әйтик, салым түләүче халыкны исәпкә алу буенча беренче ревизияне үткәрү (1719–1722) һәм җан башыннан салым салуны кертү (1724).

ИМПЕРАТОРНЫҢ КАЗАН БУЙЛАП СӘЯХӘТЕ

Петр I, беренче чиратта, Кремльдәге Благовещение соборын карый, Богородица монастырена бара, митрополит Тихон III нең, Казан губернасы губернаторының, вице-губернаторның хезмәт урыннарында була, Татар бистәсенә барып, бистә татарларыннан сайланылган кешеләр белән һәм башка «гражданнар» белән аралашкан дигән имеш-мимешләр дә сакланып калган. Патшаның 30 майда Казанда үзенең 50 яшьлек юбилеен билгеләп үткәнлеге дә билгеле. Аның шәһәрдә озакка тукталуы да шушы вакыйга белән бәйле булса кирәк. Әмма башка сәбәпләре дә бар әле.

Россиядә югарыдан төшкән боерык-әмерләргә күз йомып карау, чиновникларның башбаштаклыгы һәм идарә итүдә башка шундый күпсанлы авырлыклар һәрчак булган. Җирле дәүләт органнарында тикшерүләр, ревизияләр үткәрү дә Петр I дән башланып китә. Император Казанга килгәч, үзен ревизор буларак та күрсәтә. Ул иң башта губерна канцеляриясендәге указлар теркәлеп барыла торган китапны китерүләрен таләп итә, китапны табып китерә алучы булмагач, кабынып китеп, бөтен җирле канцелярияләрдә дә шул хәлдер әле дип, тоталь тикшерүләр үткәрә башлый.

СӘҮДӘГӘР ИВАН МИХЛЯЕВ

Петр I заманында беренче мануфактуралар – кул көче кулланыла торган эре предприятиеләр төзелә башлый. Аларның күбесе дәүләт предприятиеләре – шәхси эшмәкәрләрнең завод, фабрика ачарга мөмкинлекләре булмый диярлек. Казанда 1714 елдан дәүләтнеке булган сукно мануфактурасы эшли башлый. Петр I әлеге мануфактурага ревизия үткәрә – барлык остаханәләрне, товар саклана торган урыннарны, материалларны карап чыга. Аннары Казанның иң бай сәүдәгәре Иван Афанасьевич Михляевның шәхси сукно предприятиесендә була. Ике фабриканы да чагыштырып караганнан соң, соңгысының хәлләре күпкә яхшырак дигән фикергә килә, ике предприятие җитештерүе арасында шулкадәрле зур аермага гаҗәпләнүен белдерә. Петр соңрак та Казанда оештырылган тикшерүләрне онытмый: Казан губернаторына язган хатында Казанда вакытта табып китерә алмаган канцелярия китабын һичшиксез таптыруын таләп итә, 1724 елда Иван Михляевка җирләре, биналары, эшчеләре белән бергә дәүләт сукно фабрикасын бер тиенсез тапшыру турында указ чыгара. Билгеле, императорның җаена тормаса, фабрика кадәр фабрика бирер идемени инде ул – Иван Михляев императорның шәһәргә килүе истәлеге итеп үз хисабына изге апостоллар Петр һәм Павел соборын төзергә сүз бирә, һәм йорты янәшәсендә 1726 елга яңа собор үсеп чыга. Аннан соңрак чорга караган документларда да дәүләт акчаларын әлеге фабрика хуҗалары Дрябловларга нәрсәгә кирәклеген сорап та тормыйча меңәр сумлап кына биргәнлекләре, шул ук вакытта башка статьялар буенча чыгымнарны тиенен тиенгә кадәр исәпләүләре күренә.



Готовность			
на 66 пушечной корабль			
дерев	1673	1535	337
досок	1298	1246	52
в том числе			
8 дюймовых	119	67	52
7 дюйм	121	121	
6 дюйм	124	124	
5 дюйм	86	86	
4 дюйм	534	534	
3 дюйм	314	314	
Итого	2971	2781	389
на 54 пушечной			
дерев	1382	1378	243
досок	1306	1306	
в том числе			
7 дюймовых	120	120	
6 дюйм	120	120	
5 дюйм	84	84	
4 дюйм	558	558	
3 дюйм	314	314	
2 дюймовых	110	110	
Итого	2688	2684	243

2

2. Ике кораб төзү өчен кирәкле агачлар һәм такталар әзерләүгә табель. 1727–1728 еллар.

КАЗАН АДМИРАЛТЕЙСТВОСЫ

Петр I Казан адмиралтействосы эшчәнлегенә аеруча зур игътибар бирә. Ник дигәндә, верфьтә Персия походына дип кораблар төзиләр, аннары Казан губернасы Петербургтагы төп верфьләргә кораб төзү өчен кирәкле булган агач материалларын әзерләп җибәрүче үзәк булып тора. Суднолар төзү үзәге Казансуның Иделгә кушылган турысында XVII гасырда да булган. Шундагы Бишбалта бистәсе янәшәсендәге буш яткан җирләргә 1718 елда рәсми указ нигезендә балта осталары, такта яручылар, мичкә ясаучылар һәм башка верфьтә эшләүче һөнәр осталары мәҗбүри күчереп утыртыла. Предприятиене зурайтып, яңа биналар салына, эшчеләрнең Адмиралтейство бистәсе төзелә. Персия походына дигән корабларны монда ясап, Идел буенча Әстерханга төшерүне кулай күрәләр.

Петр I Адмиралтейство конторасында Казаннан Петербургка җибәрелүче агач материалларның ведомостен тикшерә, әлеге документ буенча җибәрелгәннәр белән Петербургта кабул итеп алынган материаллар ведомостен чагыштырып карарга дип, Адмиралтейств-коллегиягә указ җибәрә. Персия походына суднолар төзү өчен, Түбән Новгородта да Казандагы кебек үк верфь төзергә әмер бирә.

ИМПЕРАТОРНЫ ОЗАТУ

Ниһаять, Петрның Казаннан китәр вакыты да җитә. Патшаның туган көнен бәйрәм итә-итә хәлдән тайган кунаклар 6 июнь көнне йөзеп килгән стругларына утырып туп тавышлары, чиркәү чаңнары астында Казаннан кузгалып китә. Петр патшаның баштагы планнары буенча рус дәүләтенең төп диңгез судноларын төзү үзәге буларак уйланылган Казанга императорның килүе аның үзе өчен дә, җирле хакимият, халык өчен дә онытылмаслык вакыйга итеп хәтергә сеңеп кала. Соңрак әлеге чор тарихчылары да бу вакыйга турында легенда-уйдырмалар кушып, бик тәфсилләп язып калдырганнар. Мәсәлән, шул ук Михляевның Петр каршында баш орып, аны үзенә кунакка чакыруы, аңа алтын-көмеш акчалар, энҗеләр тулы ике поднос алып килеп бирүе, имеш, шул сәбәпле императорның күңеле йомшарып китеп, сәүдәгәргә сукно фабрикасын бүләк итүе турындагы хәбәрләр чыны-ялганы белән бергә тарихка кереп калган.

БОЛГАРДА ТУКТАЛЫШ

Петр I нең Казаннан соң истә калырлык тукталышы Болгар шәһәре хәрабәләре янында була. Әле 1712 елдан ук Успение монастыре төзелешенә дип, биредәге төзек ташларны, шул исәптән кабер ташларын кулланганнар. Петр I карагандa монда әле биналарның хәрабәләре шактый күп була. Ул иң беренче ак манарага күтәрелә, грек палатасы дип аталганына һәм башкаларына керә. Таштан төзелгән 50 ләп бина хәрабәләрен исәплиләр, шул исәптән 10 палатаны һәм 4 манараны, 2 мөселман зиратындагы 49 кабер ташын исәпкә алалар. Башлап күтәрелгән ак манараның нигезе какшаганын күреп, Петр I бераз соңрак Казан губернаторы Алексей Салтыковка аны ныгытырга дип әмер бирә. Күп тә үтми, ул әмер үтәлә. Болгар шәһәрлегендәге иске корылмаларның размерларын, исәбен язарга дип кешеләр җибәрелә, анысы да үтәлә.

1721 елда игълан ителгән Россия империясенең тынгы белмәс, һәрнәрсәгә шәхсән үзе өлгерергә тырышкан императоры Петр патша Казанда үзен дәүләт эшлеклесе буларак күрсәтә. Биредә ул дәүләт хезмәтендәгеләргә тәртипләрне өйрәтеп, аннан киткәч тә вазгыятьне үз кулында тотып, әмерләрен биреп, аларның үтәлешен тикшереп тора. Үзен дә, башкаларны да аямыйча йөргән тырышлыклары нәтиҗәсендә, Балтыйк диңгезендәге кебек үк, Каспий диңгезендә дә, вакытлычага гына булса да, Андрей әләмен җилфердәтүе, кая гына барса да, кемнәрдәдер – уңай, кемнәрдәдер тискәре тәэсир калдыруы белән танылган патшаның матур җәй башындагы сәяхәтенең Казан белән бәйләнешле, якты хатирәләргә бай булуы шәхсән безнең өчен кадерле.

«Болгар радиосы» премиясе: Татарстанның мөһим музыкаль вакыйгасы

2019 елның 14 декабрендә Казанның «Пирамида» мәдәни-күңел ачу комплексында «Болгар радиосы» VII Милли музыка премиясен тапшыру тантанасы узды (6+). Татар эстрадасы вәкилләренең оештыручылар фикеренчә иң лаеклылары «Алтын йолдыз» сыны белән бүләкләнде.

Премиянең үзенчәлеге нәрсәдә?

Тантана елның иң әһәмиятле мәдәни вакыйгаларының берсе булды: «Болгар радиосы»ннан «Милли музыкаль премия», гадәттәгечә, һәр чор өчен хит булу мөмкинлегенә ия җырларны ачыклый.

Милли музыкаль премия – башкаручылар һәм композиторлар өчен яхшы иҗади стимул. «Болгар радиосы» Милли музыкаль премиясен тапшыру тантанасы – нәтиҗәләр ясауның бер үзенчәлекле төре. «Болгар радиосы» тыңлаучыларының фикерләрен чагылдыруның бер юлы да. Премия һәр җырчы, һәр иҗатчы өчен стимулга әйләнә, чөнки әлеге бүләккә бары иң яхшылар гына лаек була.

Тамашачыларны нәрсә көтә иде?

Тамаша «Пирамида» концерт залының фойесында ук башланды. Инде күп еллар тамашачыларга «Болгар радиосы» Милли музыкаль премиясенең символы – йолдызчыклар өләшенә. Быелгы тантана да традицияне саклады.

Бу елның үзенчәлеге – теләге булган һәркемгә фотомагнитлар таратылды, тамашачылар аларны бу бәйрәм турындагы бер истәлек итеп кабул итеп алды. Ә фотозонада кунаклар йолдызлар белән бергә фотога төшү мөмкинлегенә ия булды.

Тамаша холлдан концерт залына күчте. Быелгы «Болгар радиосы» Милли музыкаль премиясенең алып баручылары – радионың баш мөхәррире Илфар Кәримов, Татарстанның атказанган артисты Рөстәм Гайзуллин һәм «Яңа Гасыр» телеканалының алып баручысы Эльвира Фазлыева булды.

Премияне кемнәргә бирәләр?

«Болгар радиосы» Милли музыка премиясе лауреатларының бер өлеше – «Кайнар хит» проектында тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җиңгән артистлар. Болар – Ришат Төхвәтуллин, Гүзәл Уразова, Раяз Фасыйхов, Марат Шайбәков, Гөлназ Асаева, Марат Фәйрушин, Илсаф, Рузилә Хәертдинова, Сиринә Зәйнетдинова, Рәзил Камалов һәм Рәфинә Ганиуллина һ.б. «Кайнар хит» проектында җиңүчеләрдән тыш, «Алтын йолдыз» сынын «Болгар радиосы» тыңлаучыларының йөрәген яулаган иң популяр җырларны башкаручыларга да тапшыралар.

Быел нинди номинацияләр булды?

«Болгар радиосы» Милли музыкаль премиясе быел 36 номинациядә бирелде. Болар – «Иң халыкчан җырчы», «Татар җыр сәнгатен дөньяга танытканы өчен», «Ел ачышы», «Иң лирик җыр», «Иң моңлы җырчы», «Елның гаилә дуэты», «Халык мәхәббәте», «Кабатланмас тавыш» һ.б. номинацияләр.

Бәйгедә яшь җырчылар да, тәҗрибәле өлкән буын башкаручылары да катнашты. Ел саен без «Татар эстрадасы легендасы» номинациясендә лауреат билгелибез. Узган елларда бу номинациядә күренекле җырчылар – Хәмдүнә Тимергалиева һәм Флера Сөләйманова җиңүче дип табылды. Быел бу номинациядә танылган җырчы Рафаэль Ильясов лауреат булды.

«Болгар радиосы» VII Милли музыка премиясе лауреатлары

1. **Раяз Фасыйхов.** «Кабатланмас тавыш» номинациясе
2. **Рузилә Хәертдинова.** «Яңа исем» номинациясе
3. **Сиринә Зәйнетдинова.** «Иң моңлы җырчы» номинациясе
4. **Резидә Шәрәфиева.** «Иң үзенчәлекле тавыш» номинациясе
5. **Илназ Баһ һәм Гүзәл Идрисова.** «Иң романтик дуэт» номинациясе
6. **Азалия Зиннәт.** «Иң тынгысыз җырчы» номинациясе
7. **Венера Ганиева.** «Халык мәхәббәте» номинациясе
8. **Илнар Миранов.** «Ел ачышы» номинациясе
9. **Марат Фәйрушин.** «Иң лирик җырчы» номинациясе
10. **Рәзил Камалов һәм Рәфинә Ганиуллина.** «Елның гаилә дуэты» номинациясе
11. **Алсу һәм Азат Фазлыевлар.** «Иң халыкчан дуэт» номинациясе
12. **Винарис Ильегет.** «Иң максатчан җырчы» номинациясе
13. **Айдар Рәкыйпов.** «Ел ташкыны» номинациясе
14. **Зәйнәп Фәрхетдинова.** «Йөрәкләргә үтеп кергән җыр» номинациясе
15. **Ришат Төхвәтуллин.** «Татар җыр сәнгатенең асылын саклап, дөньякүләм дәрәҗәдә иҗат иткәне өчен» номинациясе
16. **Илсөя Бәдретдинова.** «Елның иң иҗади төркеме» номинациясе
17. **Рифат Зарипов.** «Иң халыкчан җырчы» номинациясе
18. **Нәфкать Нигъмәтуллин.** «Үзенчәлекле моң» номинациясе
19. **Гөлназ Асаева.** «Иң зәвыклы җырчы» номинациясе
20. **Ришат Фазлыйәхмәтов.** «Тамашачы мәхәббәте» номинациясе
21. **Асаф Вәлиев.** «Үлмәс хит» номинациясе
22. **Виталий Агапов.** «Халык күңеленә кергән җырлар авторы» номинациясе
23. **Гүзәл Уразова.** «Ел җырчысы» номинациясе
24. **ИлСаф.** «Иң лирик җыр» номинациясе
25. **Айдар Галимов.** «Халык мәхәббәте» номинациясе
26. **Марат Шайбәков.** «Иң романтик җырчы» номинациясе
27. **Зөфәр Хәйретдинов.** «Татар җыр сәнгатенә керткән өлеше өчен» номинациясе
28. **Ильмира Нәгыймова.** «Иң популяр җыр» номинациясе
29. **Әнвәр Нургалиев.** «Иң популяр җыр» номинациясе
30. **Айдар һәм Алмаз Юнысовлар.** «Иң үзенчәлекле дуэт» номинациясе
31. **Булат Нигъмәтуллин.** «Заманча яңгыраш» номинациясе
32. **Рафаэль Ильясов.** «Татар эстрадасы легендасы» номинациясе
33. **Гөлдания Хәйруллина.** «Тамашачы мәхәббәте» номинациясе
34. **Рината Тей.** «Иң креатив җырчы» номинациясе
35. **Эльмир Низамов.** «Спектакльләргә музыка иҗат иткәне өчен» номинациясе
36. **Зәлилә.** «Өметле җырчы» номинациясе

Фото «Яңа гасыр» ТРК» ААҖ матбугат хезмәтеннән алынды

МАХСУС ПРОЕКТ

— 49нчы чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

Нурислам Хәбипов җитәкчелек иткән **Россия Авыл хуҗалыгы буенча федераль күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе** оешуының 15 еллыгын билгеләп үтә.

Алмаз Хисаметдинов,
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы

Тулы җаваплылык белән

– Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, Татарстан Республикасының Дәүләт ветеринария хезмәте һәм шәхсән үз исемемнән Россия Авыл хуҗалыгы буенча федераль күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсендә эшләүче барлык хезмәткәрләрне бәйрәм белән котлыйм.

Шушы еллар эчендә Сезнең тату коллективыгыз тарафыннан бик зур эшләр башкарылды. Республикада ветеринария, фитосанитар һәм җир турындагы законнарны саклау буенча күзәтчелек итү системасын камилләштерү юнәлешендә мөһим адымнар ясалды. Россия Авыл хуҗалыгы буенча федераль күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе ветеринария һәм эпизоотик иминлекне саклауга саллы өлешен кертте.

Безнең ведомстволар алдында гаять мөһим бурычлар тора. Республиканы ветеринария, азык-төлек һәм биологик куркынычсызлык белән тәэмин итүнең уңышы безнең үзара теләктәшлектә алып барылган эшчәнлеккә һәм һөнәри осталыгыбызга бәйле.

Сезгә һәм коллективыгызга озак еллар буена актив һәм нәтиҗәле хезмәт телим. Үзара хезмәттәшлек иткәндә аңлашып, эш алымнарын тагын да камилләштереп эшләргә язсын. Уңышлар Сезгә!

Рөстәм Нуриев,
Алабуга муниципаль районының башкарма комитеты җитәкчесе

Республиканың экологик һәм азык-төлек куркынычсызлыгы сагында

– Хөрмәтле Нурислам Нуриманович! Сезне ихлас күңелдән Россия Авыл хуҗалыгы буенча федераль күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе оешуның 15 еллыгы белән тәбрик итәм! Шушы еллар буена сезнең идарә республиканың экологик һәм азык-төлек куркынычсызлыгы сагында тора, безне биологик һәм антропоген факторларның зыянлы йогынтысыннан саклый. Россия Авыл хуҗалыгы буенча федераль күзәтчелек хезмәтенең Татарстан халкының имин яшәешен кайгыртуга керткән өлеше бәһаләп бетергесез. Сезнең кул астындагы хезмәткәрләр татарстанлылар файдасына эшләп, туган җиргә карата сак мөнәсәбәт тәрбияләүгә ярдәм итәләр. Һәркайсыгызның фидакарь хезмәте, югары һөнәри осталыгы, энергия һәм принциплардан читкә тайпылмавы аерым ихтирамга лаек. Сезгә һәм үзегез җитәкчелек иткән коллективка алга таба да программалар куйган бурычларны үтәүдә ныклы сәламәтлек, саекмас көч чыганагы һәм җаваплы эшчәнлегегездә яңа иҗади уңышлар телим!

Фото Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсеннән алынды

Фото Алабуга муниципаль районының башкарма комитетыннан алынды

Реклама

Максатларга ирешергә һәм ихтирам казанырга язсын!

Фото «Татнефтепром-Зүзәйнефть» АҖнән алынды

Шамил Яһүдин,
«Татнефтепром-Зүзәйнефть» АҖ генераль директоры

– Хөрмәтле Нурислам Нуриманович! Сезгә һәм Россия авыл хуҗалыгы буенча федераль күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең зур коллективына ихлас котлауларыбызны ирештерергә рөхсәт итегез. Идарә республика халкының сәламәтлеген һәм иминлеген контрольдә тоту буенча гаять мөһим вазыйфа башкара. Сез даими рәвештә зур һәм җаваплы эш башкарасыз – бөтен республика буенча авыл хуҗалыгы продукциясенең һәм азык-төлекнең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итәсез.

Сез һәрвакыт уяу һәм куркыныч янау ихтималын вакытында кисәтеп торасыз, бу исә җитештерүчеләрнең продукция сыйфатын яхшырту өчен гарантия булып тора. Сезгә һәм үз һөнәрләренең осталарыннан торган командагызга Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы тармагы үсешенә 15 ел дәвамында керткән өлешегез өчен зур рәхмәт белдерәсем килә. Россия авыл хуҗалыгы буенча федераль күзәтчелек хезмәтенең республика һәм тулаем илнең авыл хуҗалыгы үсешендәге ролен үстерү эшендә уңышлар телим. Һәр көнегез нәтиҗәле үтсен, һәр максатыгызга ирешергә язсын!

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН
TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

Реклама бүлеге:
тел: (843) 222-09-76,
8-9272-483-384
e-mail: 89272483384_pr@mail.ru

Реклама 16+

Рафаил Глянц, Түбән Кама шәһәренең тәүге төзүчеләреннән берсе, Россиянең һәм ТРның атказанган төзүчесе, Хезмәт Кызыл Байрагы һәм «Почёт Билгесе» орденнары кавалеры, декабрь аенда үзенең 85 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Фидакарь хезмәтегез алдында баш иям

Азат Бикмурзин,
«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ генераль директоры

– Хөрмәтле Рафаил Григорьевич! Сезне чын йөрәктән, зур ихтирам һәм рәхмәт хисләре белән гомер бәйрәмегез – 85 яшьлек юбилеегыз белән котлыйм. Үзенең бөтен гомерен Түбән Кама шәһәре төзелешенә багышлаган кеше белән таныш булуыма шатмын, бергә эшләвем белән горурланам. Сез Түбән Кама якларына ерак 1961 елда беренчеләрдән булып аяк баскансыз, ул вакытта нефтехимиклар шәһәре карталарда күренә генә башлап, киләчәккә зур адымнар ясый гына башлаган була әле. Шушы киләчәктә Сез киң урамнар, йортлар, мәктәпләр, балалар бакчалары, стадионнар күрә алгансыз… Һәм боларның барысы да чынга ашты! Безнең Түбән Кама – төбәкнең иң матур шәһәрләренең берсе. Сезнең иң югары дәрәҗәдәге һөнәри осталыгыгыз нәтиҗәсендә шәһәр халкы, шул исәптән нефтехимиклар, уңайлы фатирларда яши, ял итү, иҗат һәм спорт белән шөгыльләнү өчен менә дигән мөмкинлекләргә ия. Сезнең соклангыч дәрәҗәдәге эшкә сәләтлегегез, һөнәрегезгә тугрылыгыгыз, кыенлыклар алдында югалып калмавыгыз һәм максатларга ирешү юлында үз дигәнегездә нык тора белүегез «Түбән Кама Нефтехим» бүлекчәләренең күп җитәкчеләре өчен үрнәк булып тора. Сезнең компания һәм шәһәр иминлеге хакына фидакарь хезмәтегез алдында баш иям. Шушы тантаналы көндә Сезгә ныклы сәламәтлек, озын гомер һәм иминлек телибез. Һәрвакытта да оптимизм, күтәренке кәеф һәм көч-куәт юлдаш булсын, ә якыннарыгызның җылысын, игътибарын һәм кайгыртучанлыгын тоеп яшәгез!

Фото «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖнән алынды

Александр Лаврентьев җитәкчелегендәге **Татарстан Республикасы Предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе** төбәк бүлекчәсе оешуның 30 еллыгын билгеләп үтә.

Кызыклы бурычлар һәм алгарышлы адымнар

Роза Гатина,
«Химик продуктлар дәүләт ФТИ» федераль казна предприятиесе директоры, химия фәннәре докторы, профессор

– Хөрмәтле Александр Петрович, Алексей Михайлович һәм сез җитәкләгән коллектив, сезне «Химик продуктлар дәүләт ФТИ» федераль казна предприятиесе коллективы исеменнән оешуыгызның 30 еллыгы белән тәбрик итәм! Күпме еллар инде Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе Татарстан үсешенә саллы өлешен кертә. Оешмалар мәнфәгатьләрен кайгыртып, сез катлаулы халыкара мөнәсәбәтләр шартларында республика икътисадының алга таба үсешендә мөһим бурычны үтисез. Сез үз алдыгызга тагын да масштаблырак максатлар куясыз һәм, һичшиксез, аларга ирешәчәксез. Җитештерүчеләр, республика һәм ил җитәкчеләре арасында диалог булдырып, хезмәттәшлек оештырып, турыдан-туры Татарстанның һәм Россиянең тотрыклы үсешенә йогынты ясыйсыз. Практик проектлар һәм перспекивалы бурычлар өлкәсендә безнең үзара файдалы хезмәттәшлек алга таба да дәвам итәчәк һәм ныгыячак. Алга таба республикада сәнәгатьне үстерү өлкәсендә Ассоциациянең яңа җиңүләре көтеп торсын. Шушы истәлекле көндә сезнең коллективка һөнәри үрләр яулаганда энтузиазмның сүрелмәвен, эшегезгә шундый ук җаваплылык белән каравыгызны телибез. Сезгә һәм якыннарыгызга иминлек һәм тыныч тормыш!

Фото «Химик продуктлар дәүләт ФТИ» федераль казна предприятиесеннән алынды

Реклама

www.protatarstan.ru
Поиск...
РУС | ТАТ
ТАТАРСТАН
Иҗтимагый-сәяси басма
Подписка!
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
«Тәмле ашлар җырчысы»
Хрущевны Казанда тутырган тавык белән кем сыйлаган
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
20 декабря 2019
19 декабря 2019
ТУ-144 интерактив музее
Стратосферага күтәрелү. Тавыш тизлегеннән тизрәк Ту-144 очкычында ничек очарга
«Ул әле дә безне тәрбияли...»
Иске Татар бистәсе музее
«Дөрес» татарлар һәм «барабыз» чаналары
Реклама 16+

ЯҢА ШИМБӘР – БЕР ЙОДРЫК БУЛЫП ЯШӘҮ

Күз алдына китерегез: авылда бер урам һәм анда кеше яши торган унтугыз йорт бар. Мәктәп, мәчет, клуб, кибет – берсе дә юк. Әтнә районының Яңа Шимбәр авылы кешеләре әнә шулай гомер итә.

«КИБЕТ УРЫНЫНА – ҺӘЙКӘЛ»

Дөрес, кайчандыр биредә мәчет, мәктәп, клуб булган. Иң кызыгы һәм кызганычы – боларның барысын да бер бина үзенә сыендырган. Совет хакимияте килгәннән соң, мәчеттән башлангыч мәктәп ясаганнар. Берничә елдан соң, балаларны күрше авылга җибәреп, мәктәпне клуб иткәннәр. Тик әлеге тарихлы, борынгы бинаны күреп булмады – аны берничә ел элек сүткәннәр.

Яңа Шимбәрдә халык өчен мөһим урын булып райпо кибете эшләгән. Тик узган ел ул иске таш бинаны да сүткәннәр икән. Хәзер бу урында һәйкәл торгызып яталар.

– ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров тумышы белән Яңа Шимбәрдән, – дип сөйләде Түбән Көек авылы җирлеге башлыгы Фәргать Мөхәмметгалиев. – Бөек Ватан сугышында һәлак булган, катнашкан кешеләрнең исемен мәңгелештерү аның идеясе иде. ТР Президенты Аппараты җитәкчесе һәйкәл эшләүне тулысынча үзе күтәрә.

Моңа кадәр Яңа Шимбәрдә һәйкәл булмаган. Бары сугышта һәлак булганнарның исемен мемориаль тактага гына язып куйганнар. Һәйкәл янәшәсенә, элеккеге клуб урынына, зур булмаган корылма ясау планы да бар икән. Монысы да Әсгать Сәфәров идеясе.

– Авылда мәчет юк бит. Әбиләргә кереп дога уку өчен бер урын кирәк, әлбәттә, – диде Фәргать Мөхәмметгалиев.

Җирлек башлыгы белән әнә шулай авылның «үзәген» карап, фотога төшереп торган арада бер машина килеп туктады. Күчмә кибет икән. Кешеләрне махсус чакырып чыгардылар диярсең: капкадан бер-бер артлы апалар, әбиләр күренде. Санаулы минут эчендә сигезләп хатын-кыз җыелды. Мөлаем генә сатучы кыз, товарларны әрҗә белән яңа яуган карга тезеп куйды. Ипи, тоздан башлап, ман-

Фото: Алёна Кутыркина

Яңа Шимбәрдә райпо кибете эшләгән. Тик узган ел ул иске таш бинаны сүткәннәр. Хәзер бу урында һәйкәл торгызып яталар.

Автор:
Руфия Фазылова

Халык ризыкка аптырамый: райпо сәүдә челтәре машинасы да, шәхси кибет тә атнага икешәр тапкыр килә, ди. Авыл кешеләре соңгысын ныграк мактады: «Товар күбрәк», – диделәр.

дарин, виноград, балык, казылык кебек ризыкларга кадәр бар. Без, журналистларга, шул гына кирәк, эчкерсез, ачык апалар белән туйганчы сөйләштек.

Халык ризыкка аптырамый: райпо сәүдә челтәре машинасы да, шәхси кибет тә атнага икешәр тапкыр килә, ди. Авыл кешеләре соңгысын ныграк мактады: «Товар күбрәк», – диделәр. Яңа Шимбәрдә кибет тотуның файдасы юк – кеше саны аз булгач, утка, газга, кибетчегә түләнгән хезмәт хакы акланмый. Шуңа күрә иң яхшысы – менә шундый күчмә кибетләр. Халык көнен, сәгатен белеп, товар төягән машинаны кадерле кунак кебек көтеп тора.

Мәктәп, мәдәният учагы булмаса да, Яңа Шимбәрнең юллары яхшы. Дистә еллар элек үк авылга асфальт юл кергән. Һәр йортта газ, су бар. Ни кызганыч, яшәргә кешесе генә аз.

БИШ ЕЛГА – ДҮРТ БАЛА!

Яңа Шимбәрдә 60 кеше яши, 31 йорт бар. Әле аларның да унтугызында гына торалар. Бер мәктәп яшендәге, өч бакча баласы бар. Һәм алар барысы да – бер йорттан! Әлбәттә, без бу гаиләгә дә кердек. Габдрахмановлар берсеннән-берсе кечкенә дүрт бала үстерә икән. Каенана, ул-килен, оныклар – бер йортта тату гына яшәп яталар.

– Ирем Айнур белән бер сыйныфта укыдык, – дип сөйләде Алсу. – Унберне тәмамлаганнан соң, Әтнәдә һөнәр училищесында укыдык. Айнур эретеп ябыштыручы, мин пешекче һөнәрен үзләштердем. Аннан Айнур армиягә китте. Хатлар язышып, телефоннан сөйләшеп тордык. Булачак ирем хәрби хезмәтен тәмамлап кайткач, «Оргсинтез» заводына урнашты. Мин исә «Катык» ресторанында эшләдем. Тик, гаилә коргач, авылга кайтырга булдык. Әти-әниләр янында тормыш итүне җайлырак дип таптык.

Алдан күреп шундый нәтиҗәгә килгәннәр диярсең: Габдрахмановлар биш елга дүрт бала алып кайта! Яшь гаиләгә мондый чакта әти-әни ярдәме ничек кирәк икәнен аңлатып тору кирәк түгелдер...

– Балалар бөтен кешегә җитте, – ди ана кеше. – Каенанам, Иске Шимбәрдәге әти-әнием – барыбыз бергә карадык. Олы кызыбыз Лилиягә дүрт яшь тулганда икенчесен – улыбыз Ринатны алып кайттык. Аңа яшь ярым булганда игезәк улларыбыз – Рәдис белән Рәмис туды.

Лилия бүген Түбән Көек төп белем бирү мәктәбенең икенче сыйныфында укый. Мәктәп автобусы Яңа Шимбәргә фәкать аның өчен генә килә икән. Ә малайларны ана кеше үз машинасы белән көн саен Түбән Көек балалар бакчасына илтә. Үзе дә мәктәптә, техник персонал булып эшкә кергән. Ә менә гаилә башлыгы Айнур көн саен Казанга йөреп эшли.

– Ана капиталы акчасына Казаннан бүлмә дә алып куйдык, – ди Алсу. – Аны арендага бирдек, ирем исә көн саен безнең янга кайтып йөри. Казан безгә әллә ни ерак түгел бит – 60 чакрым тирәсе. Әлегә менә шулай көн итәбез.

– Ирең дә Казанда эшли, яшәргә бүлмәгез дә бар икән, Казанга китәсегез килмиме соң? – дим Алсуга.

– Юк, нинди китү, ди. Шәһәрне яраткан булсак, кайтмаган да булыр идек.

– Яңа Шимбәрдә бер генә социаль объект та юк бит. Ә сездә – балалар... – дим, үз сүземне бирмәскә тырышып.

Тик Алсу бирешми:

– Түбән Көек өч кенә чакрым безгә. Машиналарыбыз бар. Каенанам да кибеттә эшли. Барыбыз бергә иртән чыгып китәбез, кич кайтабыз. Шәһәрдә дә өч кенә чакрым эшеңә барасың инде. Аның каравы, авылда тыныч, саф һава... Яшәргә дә шәһәрдәге кебек күп акча китми.

Габдрахмановлар биш елга дүрт бала алып кайткан.

– Күп итеп акча керә башласын әле, кайтырлар. Үзеңә эшләү файдалырак бит ул...

– Андый уйлар да бар, – диде Фидаил абый. – Улым бу эшкә алынубызны бик хуплый. Документлар артыннан да үзе йөрде. Эшләп китик әле, күз күрер. Үзебез дә карт түгел бит әле, 55 яшь тә юк. Менә пенсия яшен дә арттырдылар. Шулай булгач, эшләргә дә эшләргә.

Авыл җирлеге башлыгы Фәргать Мөхәммәтгалиев әлеге гаилә турында: «Авыл өчен җан атып торучылар», – диде. Зират тирәләрен тоту, башка эшләр дисеңме, Мөхәммәтҗановлар гел беренче икән.

Авылга яңалык алып килүчеләр дә алар. Мисал өчен, ике ел элек «электропастух» алып куйганнар.

– Сыер башыннан 1800 сум җыелдык, – диде Фәргать абый. – Малай алып кайтып бирде, сыйфатлысын алдык. Беренче елны 2 чакрымга җитә торган чыбык белән мәйданны уратып алган идек. Быел баш саны арткач, көтүлек мәйданын арттырдык. «Электропастух» бик җайлы инде, иртән малларны озатып куясың, кичен барып аласың.

Шимбәрлеләргә мал асрау өчен бөтен мөмкинлек тә бар – чишмә, таулар йортларыннан өч йөз метрда гына. Көтүлек җирләре дә шунда гына. Шуның өчен дә авылда гомер-гомергә күпләп мал тотканнар.

ФЕРМЕР БУЛУ ҖИҢЕЛМЕ?

Авылда кеше яши торган унтугыз йорт булса да, савым сыерлары утыз баштан артык. Монда тагын бер нәрсәне искәртергә кирәк: унтугыз йортның күбесендә өлкәннәр яши, алар инде мал асрамый. Шулай булгач, нигездә, алты-җиде йортта сыер тоталар.

Фидаил һәм Люция Мөхәммәтҗановлар – авылның иң күп мал тотучылары. Алай гына да түгел, фермер булып теркәлгән бердәнбер гаилә.

– Быел сентябрьдә грант оттык, – диде гаилә башлыгы. – Барлыгы 2 миллион 970 мең сум булды. Ул акчага техника алдык, печән җыю өчен кирәк-яракларын да юнәттек. Калган акчага ун баш мөгезле эре терлек алачакбыз. Үзебезнең әлегә ун баш савым сыеры, берничә баш танабыз бар.

Мөхәммәтҗановларның мал асрау буенча тәҗрибәләре зур – гаилә башлыгы гомере буе колхозда эшләгән, ферма мөдире булып та торган, хуҗабикә исә бозаулар караган. Өйдә дә өчәр-дүртәр сыер асраганнар. Мөхәммәтҗановлар пай җирләрен үзләре эшкәртә, алар 14 гектарны тәшкил итә икән.

– Киләчәктә тагын берничә пай җире алу ниятебез бар, – ди хуҗа кеше. – Кыш чыгарлык печән, салам кирәк бит. Грантның тәртибе бар – баш санын 25 тән киметмәскә кирәк. Ә безнең пай җирендә аның кадәр мал өчен печән, иген үстереп булмый.

Яңа эш башлаган фермерларның планнары күп – зуррак ферма бинасы төзү, сөтне эшкәртеп сату... Ә бүген алар сөтне литрын 21 сумнан дәүләткә тапшыра.

– Декабрь, гыйнвар ае – сөткә бәянең иң кыйммәт вакыты, – диде Люция Мөхәммәтҗанова. – Язга 20 сумнан да кимрәк була. Менә мин шуңа аптырыйм: колхоз сөтен бүген 27 сумнан җыялар, ә хуҗалыкныкы нигә кимрәк бәядән йөри? Без дә бит бер дигән, югары сортлы сөт тапшырабыз!

Мөхәммәтҗановлар бер ул, бер кыз тәрбияләп үстергән. Алар инде зурлар, үзләре әти-әни булган, Казанда яшиләр.

– Балаларыгызны да бу эшкә тартасыгыз килмиме? Ни дисәң дә, сез олыгаю ягына барасыз, – дидем гаилә башлыгына.

Ире җавап биргәнче, хуҗабикә уенын-чынын бергә кушып әйтеп куйды:

Люция һәм Фидаил Мөхәммәтҗановлар – авылның иң күп мал тотучылары. Алай гына да түгел, фермер булып теркәлгән бердәнбер гаилә.

НӘСЕЛЛЕ ТЕГҮЧЕЛӘР

Авылның атаклы тегүчесе – Римхать Галимҗанов янына да кердек. Тормыш иптәше Флюра апа белән икәү яшиләр. Римхать абый күп еллар өйдә кия торган җылы аяк киемнәре теккән. Дөрес, соңгы бер-ике елда бу эшне ташлаган инде. Ни өчен дигәндә, беренчедән, сорау юк, икенчедән, олыгаю үзен сиздерә икән. Тик шулай булса да, «Зингер» тегү машинасы йортның түрендә тора. Күңеле төшеп киткәндә Римхать абый аның артына утырып, келтер-келтер иттереп, нәрсә булса да тегеп ала.

– Бу әтидән калган машина, – диде ул. – Әти авылның атаклы тегүчесе булган. Мин үземне белгәннән бирле – машина артында. Мактану түгел, дөресе шулай: иң авыр заманнарда да ялангач йөрмәдем. Күлмәк, бишмәт, аякка чүәк – әти мине гел матур киендерде. Авылдагы малайларга да киемнәр тегеп бирә иде.

– Бу машинага ничә ел, беләсезме? – дим.

– Юк, белмим. Йөз генә түгел инде. Аны инде миңа сорап та килделәр. Бер елны бит «Зингер» машиналарын җыеп йөрделәр. Бирмәдем. Әти истәлеге бит ул. Инде хәзер бик яхшы текми дә, шулай да йортның иң кадерле ядкаре ул. Балачагым истәлеге. Миннән соң балалар теләсә нишләтерләр. Ә мин исән чагында торсын.

Тик Флюра апаның әлеге тегү машинасына үз мөнәсәбәте икән. Сәбәбе менә нәрсәдә:

– И-и-и, бу машина аркасында күргәннәрем, – дип сөйләде хуҗабикә. – Римхать колхозда тракторда эшләп кайта да тегү машинасы каршына килеп утыра. Төне буе келтер-келтер килгән тавыш тынмый. Тавышы ярар инде, аннан чыккан пычрагы хикмәт! Ул иске-москы пальто, плащлардан күпме чүп, тузан чыкканын үзем генә беләм... Римхатьне әрли торган идем: «Юк, эшләмим, дип әйт!» Ә ул барыбер үзенекен эшләде.

Римхать абыйга чималны кешеләр үзләре алып килгән. Иске туннар, бишмәтләр – барысы да эшкә яраган. Остаының даны еракларга кадәр таралган булган – Арча, Әтнә, хәтта Казан кешеләренә дә аяк киемнәре тегеп биргән ул.

– Хәзер генә бит – кибет-базарларда җаның ни тели, шул бар, – диде тегү остасы. – Ул чагында юклык заманы...

– Алайса сезнең дәрәҗәгез зур булган? – дим.

– Зур, дип... (Көлә.) Сорап килгәч, кешегә: «Юк», – дип әйтергә кыен бит. Кемдер фермада, кемдер заводта эшли. Кешеләрне кызгана идем... Эшем өчен зур акча сорамадым, «кул җиле» дип бирәләр иде.

Галимҗановлар ике кыз тәрбияләп үстергән. Кызларының берсе дә бабалары, әтиләре һөнәрен дәвам итмәгән. «Алар тегүченең авыр хезмәт икәнен күреп үсте, шуңа андый теләкләре булмады», – диде ана кеше.

...Кызык сәфәр булды бу. Иң хикмәтлесе – авылның җитмеш процентка якын кешесе белән танышып, аралашып чыктык. Кечкенә авылларга хас бер сыйфат – бердәмлек. Бу сыйфат шимбәрләрләргә дә хас.



– Бу әтидән калган машина. Әти авылның атаклы тегүчесе иде. Мин үземне белгәннән бирле – машина артында, – диде Римхать Галимҗанов.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

– Туган авылым Яңа Шимбәрнең тарихын ныклап өйрәндем. Китап эшләү нияте дә бар. Кыскача шуны әйтә алам: Яңа Шимбәр XVII гасырда оеша. Җирле халыкның нәсел шәҗәрәсе нугайлыларга барып тоташа.

Казан ханлыгы чорында Мөхәммәт Әмин ханның крепостен безнең бабайлар саклаган. Казан ханлыгы тар-мар ителгәннән соң, гади халык хәзерге авыл территориясенә килеп урнаша. Якында гына Иске Шимбәр исемле авыл була, яңа барлыкка килгән авылга Яңа Шимбәр дип исем кушалар. Ике авыл арасында Шимбәр елгасы ага. Бүген инде аның суы корыды, алай да чыганагы бар әле.

1921 елгы ачлык заманында авылда 128 йорт булган. Шул елны көчле янгын чыгып, 100 йорт көлгә әйләнгән. Ләкин шуннан соң да авыл бетмәгән, яңадан торгызылган. Сәбәбе – безнең якларда халык эштән курыкмый, бик тырыш.

Тәминә Биктимерова, тарихчы.

ЯШӘРГӘ АШЫГЫГЫЗ, **ХЫЯЛЛАНЫРГА** АШЫГЫГЫЗ

«Татарстан»ның сентябрь санында без хыялларның ничек тормышка ашуы турында язган идек. Анжела Вавилова исемендәге фондның Казан хосписыннан Ләйсән Сәетназарова барлык хыяллары диярлек тормышка ашты: юлбарыс баласын сыйпап карау, Димаш белән очрашу һәм савыгу... Савыгу теләге барып чыкмады. 2019 елның декабрендә Ләйсән безне ташлап китте. Хәтердә аның тормышка ашкан һәм ашарга өлгермәгән хыяллары гына калды...

– Хыялларыңның тормышка ашуын сизгәндә, бәхетең ташый һәм син моннан ары да яшәргә тиешлегеңне аңлыйсың. Шуның хакына алга таба да хыялланырга ярый. Һәм башкаларга да хыялланырга ярдәм итәргә...

– Юлбарыс баласы белән танышуны мин чынлап та беркайчан онытмам. Бу чып-чын сюрприз булды, мин мондый эш булырга мөмкин дип уйламаган да идем. Лилуны палатага алып кергәч, минем бөтен хисләрем бергә буталды: гаҗәпләнү дә, сөенү дә, бәхет тә... Мин юлбарыс балалары шундый зур була ала дип уйламаган идем, аңа нибары яшь ярым, ә үзе инде шактый зур. Лилу уйнады, иркәләнде, ә мин сөйләп бетергесез шатлык кичердем!

– Бу җәйдә минем бер генә түгел, ә берьюлы берничә хыялым тормышка ашты. Мин бик яхшы кешеләр белән, юлбарыс баласы белән таныштым, аннары үземнең кумирым – Димаш белән очраша алдым... Ул килеп кергәч, йөрәгем дулкынланудан тетрәнеп китте. Күңелемнән генә үз-үземә: «Ләйсән, тынычлан, барысы да яхшы, кычкырма, сула», – дип кабатладым. Минем аңа бармакларым белән кагыласым һәм: «Чыннан да ул!» – диясем килде. Юләр сыман күренмәс өчен, үз-үземне җиңдем. Мин аннан космик башкару осталыгына ничек ирешүе турында сорадым. Ул 5 яшеннән бирле җырлавы, әти-әнисенең һәм дусларының иҗади кешеләр булуы һәм аңа һәрьяклап ярдәм итүләре турында сөйләде... Аның ничек җырлавы, хисләрен чагылдыра алуы, тавышының нәрсәгә сәләтле булуы – болар барысы минем җаныма тынычлык бүләк итә.

– Минем төп хыялым – сәламәтләнү, бу шактый авыр һәм катлаулы юл. Әмма мин моның мөмкин булуына ышанам. Хыялың тормышка ашканда, син бәхетеңнән җир өстендә очып йөргән кебек буласың. Һәм минем нәрсә турында булса да хыялланучы кешеләргә шуны әйтәсем килә: хәтта тормышка ашмас кебек тоелса да, хыяллануыгызны дәвам итегез, аңа омтылыгыз һәм бу турыда башка кешеләргә әйтегез, чөнки ярдәм итә алырдай кешеләр һәрвакыт табыла.

Фото: Виктор Ежов

ТАССР 100 лет / ел

Яңа ел белән!

«РОССИЯ ХАЛЫКЛАРЫ – ТАТАРЛАР» ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕННӘН



«Татарстан»лы Яңа ел белән!

Реклама 16+